**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Галиуллин К.Р.* Борынгы һәм иске төрки телләрнең лексик корпуслары һәм Turco-Rossica . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Гайнуллина Г.Ф., Гыйниятуллина Л.М.* М. Галинең «Кешеләр сөйләргә ничек өйрәнгәннәр?» хезмәтендә телнең барлыкка килүе турындагы теорияләр . . . . . . . . . . . 13
*Сәгъдиева Ф.К.* Татар паремияләрендә рухи кыйммәтләрнең чагылышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
*Гаттарова И.И.* Татар авылы микротопонимиясен өйрәнү тәҗрибәсеннән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
*Бәдртдинова А.Ә.* Татар теленең урта диалекты вокализм системасына күзәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Гомәров И.Г.* Фатих Әмирханның тормышы һәм иҗатына кагылышлы архив материаллары: кулъязма мирасын, шәхси әйберләрен исәпкә алган акт кәгазе . . . . . . . . . . . . 35
*Шәрипов Ә.М.* Горур башым түбән иелмәс... *(шагыйрь Сириннең тормыш һәм иҗат юлы)* . . . . . . . . . . 43
*Миңнуллина Ф.Х.* Н. Исәнбәт драматургиясендә шәхес иреге . . . 62
*Сафина А.М.* Әдәби күренеш буларак милли характер . . . . . 68

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Сөнгатов Г.М., Җәүһәрова Ф.Х., Батталова А.Д.* Татар халык иҗаты әсәрләрендә (теләкләр, әзер җаваплар, сынамышлар һәм ышанулар) йорт хайваннары һәм кошлар белән бәйле күзаллауларны гәүдәләндерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
*Мөхәммәтҗанова Л.Х., Хөсәенова Г.Р.* Татар эпосында романик төр дастаннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Хәбибуллина З.Р.* Сәяхәтләр антропологиясе объекты буларак Урал мөселманнарының хаҗ сәфәре . . . . . . . . . . . . . . . . 86
*Бигиев М.* Мөселман руханиларының 1905 елгы Уфа корылтаенда каралган кайбер проектлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Максимов Н.В.* Сөйләм калыбы: хәрәкәтне белдерүче сүзләр . . 121
*Вәлиева З.Ф.* Мәктәптә милли тәрбия бирүнең нәзари һәм гамәли нигезләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
*Нургалиева З.К., Яруллина Э.Р.* Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларда толерантлык хисләре тәрбияләү . . . 136

**ИҖТИМАГЫЙ ФӘННӘР**

*Дәүләтшина Я.М., Мөхәммәтҗанова Л.К., Хизбуллина Р.Р.* Сәләтле яшьләр һәм миграция (эмпирик тикшеренү нәтиҗәләре) . 140

**ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР**

*Гали Рәхим.* Көрәш җырлары . . . . . . . . . . . . . . . . . 147

**СӘНГАТЬ**

*Лобашёва И.Ф.* Казандагы академик сәнгать югары уку йортын ябу турында: *тарихи һәм бүгенге заман параллельләре нигезендә аналитик күзәтү* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152

*Фәрдиева Д.Р.* XIII халыкара мөселман киносы фестиваленә күзәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

*Касенова К.Б.* Казак келәмнәре орнаментының тарихи үсешендә гарәп-мөселман мәдәнияте роле . . . . . . . . . . . . 170

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Галиуллин К.Р.* Лексические корпусы древних и старых тюркских языков и Turco-Rossica . . . 7

*Гайнуллина Г.Ф., Гиниатуллина Л.М.* Теории о происхождении языка в труде М. Гали «Кешеләр сөйләргә ничек өйрәнгәннәр?» («Как люди научились говорить») . . . 13

*Сагдеева Ф.К.* Отражение духовных ценностей в татарских паремиях . . . 19

*Гаттарова И.И.* Из опыта изучения микротопонимиии татарской деревни . . . 23

*Бадртдинова А.А.* Обзор системы вокализма среднего диалекта татарского языка . . . 28


## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ


*Гумеров И.Г.* Архивные материалы по жизни и творчеству Фатиха Амирхана: опись рукописного наследия и личных вещей писателя . . . 35

*Шарипов А.М.* Не склонится моя гордая голова... *(жизнь и творчество поэта Сирина)* . . . 43

*Миңнуллина Ф.Х.* Свобода личности в драматургии Н. Исанбета . . . 62

*Сафина А.М.* Национальный характер как литературное явление . 68


## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Сунгатов Г.М., Завгарова Ф.Х., Батталова А.Д.* Представления, связанные с домашним скотом и птицей, в произведениях татарского народного творчества . . . 72

*Мухаметзянова Л.Х., Хусаинова Г.Р.* Романические дастаны в татарском эпосе . . . 79


## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ


*Хабибуллина З.Р.* Хадж уральских мусульман в объекте антропологии путешествий . . . 86

*Бигиев М.* Некоторые проекты, рассмотренные на курултае мусульманского духовенства в 1905 г. в Уфе . . . 96


## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ


*Максимов Н.В.* Шаблон речи: слова, обозначающие движение . . 121

*Валиева З.Ф.* Теоретические и практические основы национального воспитания в школе . . . 130

*Нургалиева З.К., Яруллина Э.Р.* Воспитание толерантности на уроках татарского языка и литературы . . . 136

## СОЦИАЛЬНЫЕ НАУКИ

*Давлетшина Я.М., Мухаметзянова Л.К., Хизбуллина Р.Р.* Талантливая молодежь и миграция (результаты эмпирического исследования) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Гали Рахим.* Песни о борьбе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147

## ИСКУССТВО

*Лобашёва И.Ф.* О ликвидации академического художественного вуза в Казани: *аналитический обзор на основе исторических и современных параллелей* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152

*Фардеева Д.Р.* Обзор XIII международного фестиваля мусульманского кино . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

*Касенова К.Б.* Роль арабо-мусульманской культуры в историческом развитии орнамента казахского ковра . . . . . . 170

УДК 811.512.1'374

*К.Р. Галиуллин*

# БОРЫНГЫ ҺӘМ ИСКЕ ТӨРКИ ТЕЛЛӘРНЕҢ ЛЕКСИК КОРПУСЛАРЫ ҺӘМ TURCO-ROSSICA

Одним из основных путей решения задачи комплексной информатизации лингвистики является создание различных корпусов языковых материалов. В тюркологии к числу наиболее востребованных относятся своды древне- и старотюркской лексики, которые важны для решения широкого круга задач, относящихся к истории формирования и развития тюркских языков, их взаимодействию, а также контактированию с другими языками. Статья посвящена вопросам применения древне- и старотюркских лексических данных в исследованиях по тюркско-русской контактологии (Turco-Rossica). Использование данных материалов при изучении и характеристике тюркизмов позволяет повысить научный уровень историко-этимологических изысканий: дополнить, уточнить, пересмотреть имеющиеся этимологии, прояснить происхождение некоторых «темных» слов.

**Ключевые слова:** тюркско-русские языковые контакты, тюркизмы, лексический корпус, древнетюркские и старотюркские письменные источники.

Хәзерге вакытта, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр зур темплар белән үскән заманда, тел белеме өлкәсендәге фәнни тикшеренүләрне дә алар нигезендә тормышка ашыру мөһим һәм актуаль мәсьәләләрнең берсен тәшкил итә. Әлеге бурычны хәл итүнең төп юлларыннан берсе – тел материаллары корпусларын (тупланмасын, фондларын) төзү.

Тюркологиядә аеруча борынгы һәм иске татар язма текстларының сүз байлыгын колачлаган корпусларга ихтыяҗ зур. Бүгенге көндә тел галимнәре карамагында борынгы төрки телләрнең лексик үзенчәлекләрен чагылдырган күпсанлы чыганаклар бар. Аларның бер өлешендә аерым әсәрләр генә [мәсәлән, Урта Азия тәфсире (XII–XIII гг.), Нәсиминең «Диван»ы (XIV г.), Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е (XIV г.) һ.б.], ә кайберләрендә бер авторга яисә регионга караган [мәсәлән, Орхон-Енисей ташъязмалары (VIII г.), Урта Азиядә иҗат иткән шагыйрьләрнең (XIV г.), Нәвоинең әсәрләре (XV г.) һ.б.] берничә текст урын ала. Моннан тыш, борынгы филологик хезмәтләр һәм сүзлекләр дә нәшер ителде. Алар арасында, әлбәттә, беренче урында Мәхмүт Кашгарыйның «Диване лөгатет төрк» сүзлеге (XI г.) тора. Биредә үрнәк итеп тагын XIII гасырда төзелгән төрки-гарәп (1245 ел) сүзлеген, Codex Cumanicus (XIV г.) әсәрен, Ибне Мөханна (XIV г.), Әбу-Хәййан (XIV г.) хезмәтләрен китерергә мөмкин. Төрки телләрнең сүзлек составындагы гомумтөрки лексикага караган борынгы һәм иске төрки чыганаклардагы тәңгәллекләр

билгеле бер дәрәҗәдә «Төрки телләрнең этимологик сүзлеге»ндә чагылыш таба. Гаять күләмле материал VII–XIII гасырларга караган төрки чыганаклар сүзлегендә («Древнетюркский словарь») тупланган.

Бүгенге көндә төрле нигездәге (тел үзенчәлекләре, региональ, хронологик һ.б.) корпуслар һәм шулай ук җыелма мегакорпус төзү актуаль. Әлеге юнәлештә Россия һәм чит ил галимнәреннән торган берничә коллектив эш алып бара. Татарстанда лексик корпуслар Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән Казан (Идел буе) федераль университеты белгечләре тарафыннан төзелә. Фәнни тикшеренүләр барышында күп сандагы язма чыганаклар эшкәртелә һәм тасвирлана.

Лексик корпусларны төзү төрки телләрнең формалашу һәм үсү тарихына, аларның үзара һәм башка телләр белән бәйләнешенә караган күп санлы мәсьәләләргә ачыклык кертү ягыннан зур әһәмияткә ия. Алга таба аларны төрки һәм рус контактологиясе өлкәсенә (Turco-Rossica) караган тикшеренүләрдә куллануның кайбер аспектларына тукталып үтәчәкбез.

Мәгълүм булганча, алынмаларны өйрәнгән вакытта чыганак теленең материалларына игътибар итү сорала. Этимологик сүзлекләрне анализлаудан күренгәнчә, чыганак телдә кулланыла торган реаль сүзләрдән формасы, семантикасы һәм башка характеристикалары белән аерылып торган яисә бөтенләй теркәлмәгән прототиплар белән чагыштырганда, алардагы материалларның, еш кына, бүгенге көндә тел белеменә куелган таләпләргә җавап бирмәгәнлеге ачыклана. Күп очракта аларны алыштыру, тулыландыру яки төзәтү сорала. Алынмаларны тарихи-этимологик планда тикшерүнең төп нигезен чыганак телгә караган хронологик мәгълүмат, аерым алганда, бу телнең борынгы чыганакларыннан алынган материал тәшкил итәргә тиеш. Н.К. Дмитриев төрки асыллы лексик берәмлекләрне тарихи перспективада тикшеренүнең әһәмияте турында яза [Дмитриев 1962, с. 519]. Бу мәсьәләне рус телендәге төрки алынмаларны өйрәнү барышында хәл итү өчен, иң беренче чиратта, төрки телләрнең язма чыганаклары җәлеп ителергә тиеш.

Чыганак яисә арадашчы телнең тарихи материалларын файдалану этимологик тикшеренүләргә карата XX гасыр башында И.И. Огиенконың «алынманың чыганагын билгеләгәндә, чагыштыру өчен аның хәзерге формасы түгел, ә иң борынгы үрнәге алынырга һәм ул шулай ук чит асыллы сүзнең иң борынгы формасы белән чагыштырылырга тиеш» [Огиенко, 1915, с. 24] дигән таләбен тормышка ашыруда беренче адым булып тора.

Мондый материалларны җәлеп итү тарихи-этимологик тикшеренүләрнең дәрәҗәсен күтәрергә, аерым алганда, кайбер сүзләрнең этимологиясен тулыландырырга, яңабаштан карарга, аларның килеп чыгышына ачыклык кертергә мөмкин-

лек бирәчәк. Төрки телләрнең язма чыганакларында, еш кына, этимологик хезмәтләрдә күрсәтелгән төрки прототипларга караганда, рус сүзләренә күпкә якынрак булган формалар һәм мәгънәләр табыла. Биредә кайбер үрнәкләр китерү сорала: «**алмаз** <…> В качестве посредника могут выступать и тюрк. языки, ср. тур. elmas» [Этимологический словарь ..., 2010, т. 1, с. 23] – чагыштырыгыз: *алмас* ‘алмаз’ (XIV г.) [Фазылов, 1966, т. 1, с. 45]; «**базар** <…> Тюркское посредство маловероятно, ср. татар., тур., ногайск. *pazar*» [Этимологический словарь ..., 2010, т. 1, с. 41–42] – чагыштырыгыз: *базар* ‘базар, рынок’ (1245 ел) [Курышжанов, 1970, с. 90]; «**буланый** <…> Из тюрк. диал. *bulan* ‘олень’ или ‘потемневший от пота’» [Этимологический словарь ..., 2010, т. 1, с. 86] – чагыштырыгыз: *булан* ‘красный’ (XIV г.) [Изысканный дар ..., 1978, с. 286, 188]; «**кирка** <…> возможно, заимствовано из тур. *küräk* ‘лопата’» [Фасмер, т. 2, с. 238] – чагыштырыгыз: *kerki* ‘кирка’ (Мәхмүт Кашгарый сүзлегеннән) [Древнетюркский словарь, 1969, с. 301]; «**топчан** <…> Заимств. из тюрк. и, по-видимому, метафорически переосмыслено; ср. чагат. *topčak* ‘красивая лошадь’, уйг. *tobyčak* ‘большая лошадь’» [Толковый словарь ..., 2011, с. 990] – чагыштырыгыз: *tapčan, tapčaŋ* ‘подставка-треножник’ (XI г.) [Древнетюркский словарь, 1969, с. 301, 534, 675] һ.б.

Аерым очракларда төрки телләрнең язма чыганакларындагы этимологик тикшеренүләрдә гипотетик, яңадан торгызылган дип бирелүче формалар да чагылыш таба. Сүзлекләрдә алар кагыйдә буларак йолдызчык тамгасы белән биреләләр: «**богатырь** <…> Заимств. из др.-тюрк. **bayatur* [Фасмер, т. 1, с. 183] – чагыштырыгыз: *bayatur* (титул) [Древнетюркский словарь, 1969, с. 77], *бахадур/бахадир/бахатур* ‘отважный, храбрый, смелый, герой, богатырь’ (XIV г.) [Фазылов, 1966, т. 1, с. 206]; **болван** <…> из тюрк. **balbal* ‘надгробный памятник, вертикальный камень, каменная баба (половецкая)’ – чагыштырыгыз: *balbal* ‘балбал, ритуальный камень, символизирующий человека’ (VII, VIII гасырлар) [Древнетюркский словарь, 1969, с. 80]; **терпуг** <…> Из тюрк. **törpüy*, **türpüy* ‘напильник, рашпиль’ [Фасмер, т. 4, с. 49] – чагыштырыгыз: *törpiq, törpiqü* ‘напильник’ (XI г.) [Древнетюркскийсловарь, 1969, с. 581].

Сүзнең төрки телләрнең язма чыганакларында урын алуын күрсәтү прототип сүзгә вакыт ягыннан характеристика бирүнең бер элементы булып тора (теркәлү хронологиясе). Бу – сүзнең телдә әсәр иҗат ителгән чорда ук кулланылганлыгын дәлилли (биредә сүз төп нөсхә турында бара). Әлеге мәгълүмат төрки сүзнең борынгылыгы яисә прототипсүзнең анализлана торган лексема рус теленә кергән чорда ук төрки телләрдә кулланылганлыгы шик астына алынган очракларда кирәк. Мәсәлән, М. Фасмер төрки асыллы *buraụ* сүзенең борынгылыгында шикләнгән: «тат. *buraụ* не является вполне

надежной формой; некоторые ученые склонны видеть в нем заимств. из русск. (Рясянен)» [Фасмер, т. 1, с. 243]. Ләкин XIV гасыр башы чыганагында теркәлгән *burav* ‘борау’ лексемасы [Grønbech 1942, с. 69], бу сүзнең төрки телләрдә борынгы чорларда ук кулланылганлыгы турында сөйли. Аерым алганда, Э.В. Севортян билгеләгәнчә, *бурав* формасының бер-берсеннән еракта урнашкан биш төрки телдә урын алуы татар сүзенең рус асыллы булу мөмкинлеген кире кага [Севортян, т. 2, с. 267] һәм аның рус теленнән алынган булуы турындагы фаразның урынсыз икәнлеген күрсәтә.

Чыганак тел белән бәйле тарихи-хронологик мәгълүмат мөмкин булган кадәр фәнни этимологик сүзлекнең алынмаларга багышланган һәр мәкаләсендә урын алырга тиеш. Әмма әлегә кадәр андый мәгълүмат алынмаларның төрле төркемнәрендә бер төрле дәрәҗәдә чагылыш тапмый. Чыганак тел буенча хронологик мәгълүмат күп очракта Көнбатыш Европа телләреннән кергән алынмалар белән бәйле мәкаләләрдә бирелә. Монда үрнәк итеп рус теленең 1963–2014 елларда дөнья күргән этимологик сүзлегендәге *абсентеизм, автомобилизм, автомобилист, автомобиль, агностицизм, адреналин, адью, ажиотаж, азот, акварелист, акварель, акробатика, алло, альбом, альпинизм, альпинист* һәм М. Фасмер хезмәтендәге *фабрикант, фаза, фактор, фактура, факультет, фалбала, фанатик, фара, фарш, фаршировать, фаянс, фиалка, физик, физиономия* мәкаләләрен китерергә мөмкин.

Мондый мәгълүматның төрки телләрдән кергән алынмалар турындагы мәкаләләрдә урын алуы сирәк күренеш. Шулай да биредә төрки лексемаларның борынгы чорларда теркәлгәнлеге турында информациянең берникадәр дәрәҗәдә Turco-Rossica буенча хезмәтләрдә чагылыш табуын әйтеп үтәргә кирәк. Кайбер галимнәр төрки телләрнең язма чыганаклары материалларын киң файдаланалар (И.Г. Добродомов, К.Г. Менгес хезмәтләрен карагыз). Мәсәлән, В.А. Богородицкий «Codex Cumanicus» сүзлегеннән рус телендә параллельләре булган 20 дән артык сүзне бирә [Богородицкий, 1935, с. 353]. Н.К. Дмитриев хезмәтендә рус теленең Д.Н. Ушаков редакциясендәге аңлатмалы сүзлегеннән алынган бер төркем төрки алынмаларга Мәхмүт Кашгарый, Ибне Мөханна, «Codex Cumanicus» сүзлекләреннән параллельләр китерелә [Дмитриев, 1962]. Ләкин борынгы һәм иске төрки телләр белән бәйле күп кенә материал Turco-Rossica өлкәсендә һаман да фәнни әйләнешкә кертелмичә кала бирә. Мәсәлән, рус теленең югарыда телдә алынган этимологик сүзлеген төзүчеләр беренче басмада бары тик *айва* мәкаләсендә генә Н.К. Дмитриев хезмәтеннән материаллар бирәләр. Соңгысында исә төрки язма чыганакларыннан башка сүзләр турында да мәгълүмат китерелә (мәсәлән: *алмаз*, *алтын, алый, арба, арык* мәкаләләрендә).

Борынгы һәм иске төрки телләрнең лексикасын үз эченә

алган корпусларда Turco-Rossica өлкәсендәге тикшеренүләр өчен дә күпсанлы кыйммәтле үрнәкләр урын ала. Мәсәлән, төзелә торган корпус материалларының анализы барышында Е.Н. Шипованың төрки алынмалар сүзлегендә [Шипова, 1976] күрсәтелгән башлангыч А хәрефле йөзгә якын сүзнең яртысыннан күбрәгенең борынгы истәлекләрдә кулланылганлыгы ачыкланды.

Алда әйтеп үткәнчә, төрки-рус контактологиясе өлкәсендә төрки язма чыганаклар материалларын фәнни әйләнешкә кертү тарихи-этимологик тикшеренүләрнең дәрәҗәсен күтәрәчәк. Сүз уңаеннан биредә борынгы төрки формаларны хәзерге вакытта төзелә торган рус телендәге төрки алынмалар сүзлегенә кертүнең күз уңында тотылуын әйтеп үтәргә кирәк. Әлеге төр мәгълүматның хронологиясе сүзнең телдә барлыкка килү вакытына түгел, ә теркәлү чорына караса да, бу аларның әһәмиятен һич тә киметми. Чөнки күп кенә очракларда сүз төрки телләрнең истәлекләрендә рус теленә кергәнгә һәм рус язма документларында теркәлгәнгә кадәр күпкә иртәрәк кулланылган була.

Йомгаклап әйткәндә, төрки-рус контактологиясенең хәзерге үсеш этабында төрки асыллы лексик берәмлекләрне тарихи-этимологик (тарихи-лексикологик) планда өйрәнү борынгы язма чыганакларның материалларын да җәлеп итеп алып барылырга тиеш. Биредә борынгы һәм иске төрки телләренең лексик корпусларын файдалану эшне күпкә җиңеләйтәчәк.

## Әдәбият

*Богородицкий В.А.* Общий курс русской грамматики: (из университетских чтений). 5-е изд., перераб. М. Л.: Соцэкгиз, 1935. 354 с.

*Бодуэн де Куртенэ И.А.* Избранные труды по общему языкознанию: в 2 т. М.: Изд-во Акад. наук СССР, 1963.

*Дмитриев Н.К.* О тюркских элементах русского словаря // Дмитриев Н.К. Строй тюркских языков. М.: Изд-во вост. лит., 1962. С. 503–569.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

Изысканный дар тюркскому языку (граммат. трактат XIV в. на араб. яз.) / введ. лексико-граммат. очерк, пер., глоссарий, граммат. указ. Э.И. Фазылова и М.Т. Зияевой. Ташкент: Фан, 1978. 451 с.

*Курышжанов А.К.* Исследование по лексике старокыпчакского письменного памятника XIII в. – «Тюркско-арабского словаря». Алма-Ата: [Наука], 1970. 234 с.

*Огиенко И.И.* Иноземные элементы в русском языке. История проникновения русских слов в русский язык. Киев, 1915. 136 с.

*Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков: общетюркские и межтюркские лексические основы. Т. 1–4. М.: Наука, 1974–1980.

Толковый словарь русского языка с включением сведений о происхождении слов / отв. ред. Н.Ю. Шведова. М.: Азбуковник, 2011. 1175 с.

*Фасмер М.* Этимологический словарь русского языка: в 4 т. / пер. с нем. и доп. О.Н. Трубачева. 4-е изд., стер. М.: АСТ: Астрель, 2009.

*Фазылов Э.И.* Староузбекский язык. Хорезмийские памятники XIV в.: в 2 т. Ташкент: Фан, 1966–1971.

*Шипова Е.Н.* Словарь тюркизмов в русском языке. Алма-Ата: Наука, 1976. 444 с.

Этимологический словарь русского языка: вып. 1–11 (А-Н). М.: Изд-во Моск. ун-та, 1963–2014.

Этимологический словарь современного русского языка: в 2 т. / сост. А.К.Шапошников. М.: Флинта : Наука, 2010.

*Grønbech K.* Komanisches Wörterbuch. Türkischer Wortindex zu Codex Cumanicus. Kopenhagen: Munksgaard, 1942. 314 S.

***Галиуллин Камил Рәхим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының Л. Толстой исемендәге*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры*

УДК 81'0

***Г.Ф. Гайнуллина,***
***Л.М. Гыйниятуллина***

# М. ГАЛИНЕҢ «КЕШЕЛӘР СӨЙЛӘРГӘ НИЧЕК ӨЙРӘНГӘННӘР?» ХЕЗМӘТЕНДӘ ТЕЛНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ТУРЫНДАГЫ ТЕОРИЯЛӘР

В данной статье авторами предпринята попытка анализа научных взглядов известного татарского ученого, писателя М. Гали (1893–1952) относительно теорий о происхождении языка как средства общения. В частности, исследуется раздел его книги «Как люди научились говорить?» («Кешеләр сөйләргә ничек өйрәнгәннәр?»), изданной в 1927 году на арабской графике.

**Ключевые слова:** язык, происхождение языка, теория языка.

Мөхәммәт Галинең «Кешеләр сөйләргә ничек өйрәнгәннәр? (Үткәндәге, хәзерге һәм киләчәктәге телләр турында)» хезмәте 1927 елда гарәп графикасында басылып чыга. Автор хезмәтенең әһәмиятен ачык билгели: «Кешеләрнең сөйләшү телләренең тарихлары белән таныштыру – һәркем өчен кирәкле һәм кызыклы нәрсә. Шулай да хәзергә кадәр безнең татарча телдә бу турыда кулга алып күрсәтерлек күпчелек өчен язылган аерым бер әсәр юк дип әйтерлек иде әле» [Гали, б. 3]. Галим әлеге хезмәтне халыкка аңлаешлы телдә язуны максат итеп куя һәм аның фәнни-популяр хезмәт булуына басым ясый.

Шул рәвешле, «Кешеләр сөйләргә ничек өйрәнгәннәр?» китабы, күләме ягыннан артык зур булмыйча, күпчелеккә аңлаешлы һәм кирәкле булган мәгълүматны гомумиләштереп бирүне күздә тота. Биредә М. Гали телнең барлыкка килүе, төрле халыкларда телләрнең үсеше, үз чорында әлеге өлкәдәге фәнни тенденцияләрне укучы аңларлык итеп тапшырырга омтыла. Әйтергә кирәк, галим үзенең максатына ирешкән: хезмәт фәнни яктан шактый төгәл, эчтәлеге белән җитәрлек дәрәҗәдә аңлаешлы һәм әһәмиятле.

М. Гали бу китабында үз чорында яшәп килгән тел турындагы барлык теорияләргә кыскача күзәтү ясый. Ул Н. Рубакинның «Как и когда разные народы научились говорить каждый на своем языке» [Рубакин, 1909] һәм «Из тьмы времен в светлое будущее» [Рубакин, 1910] дигән хезмәтләренә, русча энциклопедияләргә, татар теле һәм әдәбияты тарихына караган тикшеренүләргә нигезләнеп эшләнгән. Автор күпсанлы чыганакларга мөрәҗәгать иткән, бу исә аңа тел турындагы теорияләрне төрле халыклар мисалында ачып бирергә мөмкинлек тудырган.

«Адәмнәрнең аралашу кораллары» дип исемләнгән бүлектә автор телнең аралашу чарасы

булуына басым ясый, ягъни телнең иҗтимагый функциясенә игътибар бирә: «Дөньядагы бөтен халыклар һәрберсе дә үзләренә аерым бер телдә сөйләшәләр. Авыру һәм хәлсезләрдән башка һәрберсе дә тел ярдәме белән үзенең фикерен, үзенең теләген һәм үзенең тойгысын башкаларга белдерә ала. Аның аерым-аерым әйткән һәрбер сүзләре бер нәрсә аңлата һәм шуңар карап икенчесе аның аңлатырга теләгән нәрсәсен бик яхшы аңлый. Югыйсә, болай өстән караганда, сүз гади бер тавыштан, коры мыгырдаудан гыйбарәт кебек. <...> Әмма шул ук кешеләр гаҗәеп осталык белән аралашалар. <...> Тавышны бераз гына үзгәрткәләп, мыгырданып тору аркасында, бер-берсенә бөтенләй чит булган ике кеше үзләренең фикерләрен, теләкләрен, эчке тойгыларын, үзләре сизеп белгән шикелле бер-берсенә аңлата алалар» [Гали, б. 4].

Галимнең телнең функциясе турындагы бу фикере бүгенге көндә дә гомуми тел белемендә киң таралган [Даниленко, 2016]. Мәсәлән, В.И. Кодухов хезмәтендә ул ачык билгеләнә: «Тел – кешеләрнең аралашуында иң әһәмиятле чара, һәм аралашу вакытында кешеләр фикер алышалар, фикер әйтешәләр. <...> Чынбарлык турында мәгълүматның бер өлеше кешегә турыдан-туры үз тәҗрибәсе аша килә. Ләкин белемнең күпчелек өлешен кеше тел ярдәмендә башка кешеләрдән ала. Белем сөйләм формасында буыннан-буынга тапшырыла килә. Тупланган белемнәрне чагылдыру һәм туплау функциясен гносеологик, аккумулятив функция дип атыйлар» [Кодухов, б. 92].

М. Гали тел теориясе мәсьәләләрен билгеле бер дәрәҗәдә биологик күренеш буларак та карый. Аныңча, һәрбер тере җан иясе төрле авазлар, тавышлар, хәрәкәтләр ярдәмендә үзара аңлаша, аралаша: «Төрле хайваннар, ерткычлар һәм кошлар да үзара бер-берсен бик яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә аларның да телләре юк дип әйтеп булмый. Алар да барыбер безнең шикелле үк тавыш чыгаралар, үзләренә күрә мыгырданалар, безнең сөйләшкәндәге шикелле бер-берсенә карашалар. Хәтта бик күп хайваннар беркадәр үзләренең кыяфәтләрен үзгәртү белән дә бер-берсен бик яхшы аңлыйлар» [Гали, б. 4]. Хайваннарның шул рәвешле аралашуын М. Гали, шартлы рәвештә тел белән аңлашу дип атарга мөмкин, дип нәтиҗә ясый. Димәк, аның карашынча, тел бары тик аралашу функциясенә хезмәт иткәндә генә тел була ала, шул ук вакытта тел бик шартлы күренеш булып та тора.

Хайваннар дөньясы белән кешелек җәмгыяте арасында параллель үткәреп, М. Гали кешеләрнең аралашуы өчен телнең аерым очракларда мөһим булмавын да билгели. Ул сөйләшү-аралашуда ымнар, хәрәкәтләр һәм тавыш-интонация мөмкинлекләренең роле турында уйлана. Галим билгеләвенчә, кешеләр, хайваннар шикелле үк, сүзсез генә аралашудан читтә кала алмыйлар: кайвакыт жестлар, хәрәкәтләр, мимика белән үз фикерләрен

җиткерергә омтылалар. Әлбәттә, галим телдә мондый экстралингвистик чараларның әһәмиятен күрсәтсә дә, ул аларның телгә ияртүче компонент кына булуын ассызыклый. Ымнар, ишаръләр белән генә сөйләшүнең аерым кыргый кабиләләрдә сакланып калуы аның бик борынгы аралашу формасы булуы хакында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бүгенге гомуми тел белемендә аралашуда ишарә, ым, хәрәкәт, мимика кебек чараларның катнашуы турындагы хезмәтләр шулай ук байтак. Сөйләмне тәэмин итеп килгән факторларның тел гыйлемендә өйрәнүнең кирәклеге һәм аралашу чаралары төшенчәсенең фәндә киңәюе хакында Прага лингвистик түгәрәгенең тезисларында да әйтелә. Бу турыда Г.В. Колшанский: «...Сөйләмне тәэмин итеп килгән ишарәләрне систематик рәвештә өйрәнергә кирәк», – дип яза [Колшанский, б. 91].

Узган гасыр башында тел галиме Е.Д. Поливанов сөйләмнең көйлелеге (мелодизация), ишарәләре кебек аспектларын өйрәнә, аларны сөйләм процессының мөһим ягы итеп билгели һәм тел белеме тарафыннан тикшерелүенең әһәмияте хакында сүз йөртә. Ул, шулай ук, әлеге факторларның киләчәктә тел гыйлеменең яңа тармагы барлыкка килүенә сәбәп булачагын әйтә. Һәм шундый тел дисциплинасын, Г.В. Колшанский фикеренчә, паралингвистика тәшки итә.

1970–1980 елларда фәндә паралингвистика мәсьәләләренә игътибар артты. Бу нисбәттән Г.В. Колшанский хезмәтләрен телгә алу урынлы. «Паралингвистика» исемле монографиясендә (1974) галим сөйләм коммуникациясендә вербаль булмаган чараларның кулланылу мәсьәләсен яктырта, хәзерге телдә парател (параязык) проблемасын тикшерә.

В.И. Аданакова исә үзенең «Лингвостилистическое функционирование слов, означающих паралингвистические явления в художественном тексте» (1987) исемле мәкаләсендә кинесика проблемасына туктала, аның әдәби әсәрдәге ролен ачыклый. Тел гыйлеме һәм паралингвистика, аларның бәйләнеше мәсьәләсе В.П. Даниленко (2015), Т.М. Николаева (1990) һәм Б.А. Успенский хезмәтләрендә (1966) дә чагылыш таба.

Фәнни хезмәтләрдә ишарәләрнең нинди мәгълүмат бирү мөмкинлеге, ишарәләрнең саны турында фикер төрлелеге күзәтелә. Һәр халыкта да ишарәләр ешлыгы һәм нормалары дигән төшенчәләр бар. Галим М. Аргайл үзенең тикшеренүләрендә төрле халыкларда ымнарның көче һәм аларның ешлыгы мәсьәләсен анализлый һәм шундый нәтиҗәгә килә: ишарәләр саны французларда – 20, итальяннарда – 80, ә мексикалыларда 180 гә җитә [Низамов, б.176].

М. Гали паралингвистик чараларның аралашуда әһәмиятен ачык билгеләү белән бергә, аларның үзләренең генә тел буларак формалашу мөмкинлеген шик астына ала: «Ләкин бер тән хәрәкәте белән генә сүз белән әйтә торган бөтен нәрсәне әйтеп бетереп булмый. Бигрәк тә тән

хәрәкәте белән үзеңнең төп фикереңне аңлатуы уңайсыз. <...> Мәсәлән, нинди дә булса бер төрле тән хәрәкәте белән «яхшы», «начар», «уйлый», «сөйли» дигән сүзләрне ничек аңлатырга кирәк [Гали, б. 8]. Дөрестән дә, тел – фикерләүдән башка, фикерләү телдән башка була алмый. Кешенең фикерләре музыкада, рәсем сәнгатендә, формулаларда, аның эшләрендә белдерелсә дә, фикерләүнең универсаль чарасы бары тел генә була ала [Сафиуллина, б. 8]. Фикер баш миендә туа. Сәбәп, ягъни этәргеч көч – кагыйдә буларак, сөйләм иясенең (субъектның) эшчәнлегенә бәйле берәр вакыйга. Максат – шул вакыйга турында хәбәр итү [Низамов, б. 18]. Бу фикерне үз чорында М. Гали дә әйткән була. Димәк, М. Гали фикеренчә, бары тик ымнар теле белән генә сөйләшү кешеләрнең фикерләрен башкаларга җиткерү максатына хезмәт итә алмас иде. Шулай булгач, телләрнең ымнардан барлыкка килүе хакындагы теория билгеле бер дәрәҗәдә шик астына алына, дип әйтә алабыз.

М. Гали гомуми тел белемендә киң таралган аваз ияртемнәре һәм ымлыклар теориясен дә киң яктырта. Ул аерым кыргый кабиләләрдә төрле ымлыклар ярдәмендә сөйләшүнең сакланып калганлыгын күрсәтә. «Шул ук вакытта хис-тойгыларны белдергәндә, без үзебез дә төрле ымлыкларга мөрәҗәгать итәбез: Андый „ай“, „вай“ шикелле ымлыкларны берәр шатлык яки кайгы кебек тойгыны аңлатканда, без үзебез дә әйткәлибез. Мәдәни халыкларның телләрендә дә андый хайваннар тавышына охшаган байтак кына ымлыклар, хәтта төрле калыпларга салынып әйтелә торган аерым сүзләр табарга була. Менә болар һәммәсе дә адәмнәрнең хайванлык дәвереннән калган бер мираслары» [Гали, б. 12].

Аваз ияртемнәре теориясенә килгәндә, М. Гали аны яңа сүзләр барлыкка килү процессы белән тыгыз бәйләнештә карый. Тикшерүче фикеренчә, без берәр әйберне күргәндә, аңа, нигездә, ул чыгарган тавышка ияреп, исем кушабыз. Бу исемнәрнең күбесе телдә урнашып китеп, алга таба киң таралыш ала һәм аерым телләрдә кулланыла башлый. М. Гали башта сүзне аерым ыру яки кабиләгә караган кешенең уйлап чыгаруын билгели. Бу сүз башта кабиләнең үз эчендә кулланыла башлый, аннан соң башка кабиләләргә тарала һәм шул рәвешле халык теленә ныклап кереп урнаша. Димәк, М. Гали гомуми тел белемендә каралган аваз ияртемнәре теориясен кире какмый.

Галим балалар теле теориясен дә киң яктырта. Аның фикеренчә, бишектәге балалар, авыз-иреннәрен үзләре теләгәнчә хәрәкәтләндереп, төрле-төрле авазлар чыгаралар: «бә», «мә», «әт», «мәм» кебекләрне әйтә башлыйлар. Бик күп телләрдә балалар башлап әйткән бу сүзләр ата-ана, әби-баба, туганлык терминнары, ашау-эчү белән бәйле төшенчәләрне аңлаталар. «Кыскасы, бу сүзләр кешеләр арасында һәммәсе дә балаларның бер дә аңламый, уйламый гына әйтүләреннән кереп кит-

кәннәр. Балалар аларны үзләренең иреннәренең төзелешләренә карап әйткәннәр» [Гали, б. 13]. Шул рәвешле, төрле телләрдә «папа», «апа», «мама», «баба» кебек сүзләр кулланыла. Әмма аларның мәгънәләре һәр халыкта үзенчә. Мәсәлән, рус телендәге «мама» сүзе грузиннарда әти кешене белдерә; «апа» сүзе Көньяк Америкада яшәүче кайбер кабиләләрдә әнине аңлаткан, ә татар телендә ул үзеңнән зур хатын-кызга мөрәҗәгать сүзе буларак кулланыла һ.б. Шул ук вакытта М. Гали бу сүзләрнең кешеләр арасында балаларның бер дә аңламый, уйламый гына әйтүләреннән килеп киткән берәмлекләр булуын ассызыклый.

Автор фикеренчә, балалар теле теориясе күп телләр өчен уртак булган «папа», «мама», «апа» кебек сүзләрнең килеп чыгышын аңлатырга мөмкинлек бирә. Бу процессның өзлексез баруын күрсәтеп, М. Гали балаларның үсә-үсә төрле җанварларга (мияу, ау-ау, кү-кү, бә-ә), җансыз предметларга (тук-тук, бух) исем бирүләрен билгели. Әмма болар барысы да уйлап чыгарылган исемнәр булмыйча, бары тик билгеле бер охшашлык нәтиҗәсендә туган берәмлекләр генә булып саналалар.

Димәк, М. Галинең «Кешеләр сөйләргә ничек өйрәнгәннәр?» хезмәтендә телнең килеп чыгышы теорияләренең киң таралганнары урын ала. Автор шул чорда гомуми тел гыйлемендә актив өйрәнелгән аваз ияртемнәре һәм ымлыклар теориясен киң яктырта, балалар теле теориясенә дә шактый зур урын бирә. Ул, телнең биологик һәм иҗтимагый үзенчәлекләрен өйрәнеп, аның нәкъ менә аралашу чарасы буларак кулланылышына басым ясый.

## Әдәбият

*Аданакова В.И.* Лингвостилистическое функционирование слов, означающих паралингвистические явления (жест, мимику) в художественном тексте // Художественный текст: структура и семантика: межвуз. сб. науч. тр. Красноярск, 1987. С. 92–98.

*Гали М.* Кешеләр сөйләргә ничек өйрәнгәннәр? (Үткәндәге, хәзерге һәм киләчәктәге телләр турында). Казан: Яңа китап, 1927. 35 б.

*Даниленко В.П.* Общее языкознание и история языкознания: курс лекций. М.: Флинта, 2015. 272 с.

*Кодухов В.И.* Введение в языкознание. М.: Просвещение, 1979. 288 с.

*Колшанский Г.В.* Паралингвистика. М.: Наука, 1974. 81 с.

*Низамов И.М.* Уем – тел очымда (сөйләм һәм массакүләм аралашу). Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 287 б.

*Николаева Т.М.* Паралингвистика // Лингвистический энциклопедический словарь / под ред. В.Н. Ярцевой. М.: Советская энциклопедия, 1990. С. 122–123.

*Николаева Т. М., Успенский Б. А.* Языкознание и паралингвистика // Лингвистические исследования по общей и славянской типологии, М., 1966. С. 99.

*Рубакин Н.А.* Как и когда разные народы научились говорить каждый на своем языке? СПб.: Прометей, 1909. 62 с.

*Рубакин Н.А.* Из тьмы времен в светлое будущее: рассказы из истории человеческой культуры. СПб.: Провинция, 1910. 115 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Тел гыйлеменә кереш. Югары уку йортларының филология факультеты студентлары өчен дәреслек. (Төзәтелгән, тулыландырылган икенче басма). Казан: Хәтер, 2001. 383 б.

***Гайнуллина Гөлназ Фоат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре;*

***Гиниятуллина Лилия Миңнулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 811.512.145:398.9

***Ф.К. Сәгъдиева***

# ТАТАР ПАРЕМИЯЛӘРЕНДӘ РУХИ КЫЙММӘТЛӘРНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

Статья посвящена вопросам изучения паремиологического фонда татарского языка в лингвокультурологическом и лингвоаксиологическом аспектах. Как известно, в пословицах и поговорках, фразеологических единицах находят отражение духовные ценности, определяющие основы мировоззрения и миропонимания народа. В качестве материала исследования были выбраны паремии, которые представляют собой своего рода аксиологические суждения о категории «труд».

**Ключевые слова:** духовные ценности, паремии, стереотипное представление, языковое сознание, квазисимвол.

Теге яисә бу халыкның рухи кыйммәтләр системасы концептларны белдерә торган сүзләр мәгънәләренең билгеле бер күренешкә карата булган бәяләмәсен чагылдыручы компонентларында чагылыш таба. Тел белгечләре, семантик категория буларак бәяләмә бирү күп кенә үзенчәлекләргә ия, дип саный. Ул үзендә объектив чынбарлык белән аның идеаллаштырылган моделе арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыра. Нәтиҗәдә анда билгеле бер дәрәҗәдә субъектив башлангыч та урын ала. Бәя биргән вакытта субъект объектка билгеле бер күзлектән чыгып якын килә. Ул практик яктан файда алу, этик күзаллаулар, эстетик идеаллар һ.б. булырга мөмкин. Галимнәр фикеренчә, рухи кыйммәтләр белән бәя бирү арасындагы аерманы күп очракта күреп тә бетереп булмый. Шул сәбәпле телдә рухи кыйммәтләрнең чагылышын тулысынча күз алдына китерү өчен мәсъәләнең аксиологик ягына игътибар итү зарур.

К. Ситарама һәм Р. Когделла тарафыннан көнбатыш, көнчыгыш, мөселман мәдәниятләре нигезендә төзелгән «Төрле мәдәниятләрдә рухи кыйммәтләрнең структурасы» таблицасында *хезмәт* рухи кыйммәт буларак каралмый [Ситарама, 1992]. *Хезмәт* компонентлы рус паремияләрен тикшергән Л.Б. Савенкова аларның 615 берәмлек тәшкил иткәнлеген һәм үзләренең саны буенча рухи кыйммәтләр системасында 15 нче урында торганлыгын әйтә. Беренче урыннарны *акча* (1813 берәмлек), *гаилә* (1437 берәмлек), *файда* (1328) һ.б. компонентлы паремияләр алып тора [Савенкова, 2002].

Татар паремияләре фондында *хезмәт* мөһим компонентларның берсе санала. Н. Исәнбәт тарафыннан «Татар халык мәкальләре» җыентыгында [Исәнбәт, 1959] аның белән бәйле 1446 берәмлек теркәлгән (чагыштыру өчен: *акча* компонентлы паремияләр 717 берәмлек тәшкил итә).

Семиотик төшенчәләр рәтендә (мәгънә, референция һ.б.) *хезмәт* төп категорияләрнең берсе булып тора. Күп кенә башка универсаль мәдәни концептлар кебек вербаль яссылыкта ул төрле лексик берәмлекләр ярдәмендә белдерелә һәм семантик планда *хезмәт – эш* парында чагылыш таба. Әлеге сүзләр матди һәм мәдәни кыйммәтләрне булдыруга юнәлтелгән эшчәнлек, максатчанлык кебек уртак үзенчәлекләргә ия. Шул рәвешле татар телендә *хезмәт* һәм *эш* сүзләре синонимик рәт тәшкил итәләр. Аерма кайчандыр кешеләр тарафыннан аларның эчтәлегенә салынган беренчел семалар белән билгеләнә. Бу яктан *хезмәт* лексемасы билгеле бер өлкәдә көч кую, ә *эш* сүзе нәрсә дә булса җитештерү, ясау, эшкәртүгә юнәлтелгән эшчәнлек төшенчәләре белән бәйләнгән.

Хезмәткә бәя бирү социаль шартларга бәйле. Гомуми планда ул уңай һәм тискәре мөнәсәбәт кебек сыйфатлар белән билгеләнә. Шунысы кызык, татар халкының рухи кыйммәтләр системасы нигездә ислам дине йогынтысында формалашкан. Аның буенча эшкә сәләтле һәр кеше хезмәт итәргә тиеш. Ислам хезмәтне әһәмияте ягыннан Аллага табыну белән бер яссылыкка куя, ягъни ул үзенә күрә дога кылу буларак күзаллана. Вакытны эшсезлектә үткәрүгә караганда, кешенең хезмәт куюы күпкә мөһимрәк. Бу очракта кеше үзенең хезмәте өчен гадел түләү һәм яхшы эш шартлары таләп итү хокукына ия. Шуның белән бергә ислам караклык, ялган, ришвәт, исерткеч эчемлекләр җитештерү һәм сату, комар һ.б. түбән ысуллар белән бәйле һәртөрле эшчәнлекне тыя. Тормыш өчен акча гадел юл белән табылырга тиеш һәм бу татар телендә *хәләл* лексемасы белән белдерелә. Башка кешеләргә зарар китергән ысуллар гомуми планда *хәрәм* дип атала.

*Хезмәт* белән бәйле мәкальәйтемнәрнең, фразеологик берәмлекләрнең күплеге аның татар халкы аңында беренче урында торганлыгын дәлилли. Әлеге паремияләрдә ике категорияне аерып чыгарырга мөмкин. Беренчесен гомуми бәяләмә характерындагы аксиологик хөкемнәрне чагылдырган мәкальләр тәшкил итә. Икенчесенә үз эченә хезмәтнең кыйммәтен билгеләүче хосусый бәяләмәләрне алган мәкальләр керә. Әлеге күренеш кешенең хезмәтне билгеле бер күләмдә тырышлык һәм көч куюны таләп итүче универсаль эшчәнлек һәм шул ук вакытта көндәлек ихтыяҗларны тәэмин итә торган чыганак ролен үтәүче процесс буларак күзаллавына бәйле.

Паремиологик фондның анализы хезмәтнең татар халкында уңай бәяләнүе турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Мәсәлән: *Хезмәт төбе – хәзинә; Ир куанычы – хезмәт; Өйрәнмичә хезмәт юк, хезмәт итми хөрмәт юк* һ.б.

Татар паремияләреннән күренгәнчә, эш процессында төп урынны *ният* һәм *тәвәкәллек* алып тора: *Эшнең башы – ният; Ниятсез эш – бөятсез камыт; Билгесез эштә тәвәккәл котkара; Ният тәвәккәл белән* (соңгы мәкальнең мәгънәсе: уйланылган

эшне ахырына җиткерергә кирәк).

Хезмәткә уңай мөнәсәбәт татар мәкаль һәм әйтемнәрендә аны *уенга* каршы куюда да чагылыш таба: *Эш беткәч, уйнарга ярый; Эшкә – вакыт, уенга – сәгать.*

Шуның белән бергә хезмәтнең кирәклеге һәм аңа дөрес мөнәсәбәт эш, уен һәм ялны чиратлаштыруны күз уңында тота: *Уйнавын уйна, эшеңне дә уйла; Эшне эшсезлек белән куш, үткәрерсең гомереңне хуш.*

Хезмәткә карата уңай бәяләмәне чагылдырган татар мәкальләрендә аның практик әһәмияте дә аерыла. Ул авыр булырга мөмкин, шуңа да карамастан, аның нәтиҗәсе куелган барлык тырышлыкларны каплый: *Хезмәт итеп ашаган икмәк тәмлерәк була; Эшенә күрә ашы, хезмәтенә күрә күмәче.* Бу мәкальләрнең гомуми мәгънәсе: хезмәт кешене тукландыра.

Мәкальләрдә башка мәгънә дә чагылыш таба: *Эшләп кем баеган.* Ягъни кеше билгеле бер эшне башкара һәм шуның өчен тиешле түләү өмет итә. Ләкин түләнгән акча аның ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерми.

Хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт капма-каршы мәгънәләр ярдәмендә дә белдерелергә мөмкин. Мәсәлән, акыл хезмәте гаять зур тырышлык һәм көч таләп итә торган даими эшчәнлек буларак күзалланса да *(Белем алу – энә белән кое казу)*, аның нәтиҗәсендә алынган белем уңай бәяләнә *(Кытайга булса да барып белем ал).*

Хезмәт алга таба утилитар ихтыяҗдан рухи кыйммәткә әверелә: *Хезмәтенә күрә хөрмәте.* Моның белән алдагы мәгънә бәйләнгән: кем тырышып эшли, шул күп нәрсәгә сәләтле. Мәсәлән: *Тырышкан табар, ташка кадак кагар.* Һәм киресенчә, ялкаулык, эшсезлек кешене боза, аны тормыш итәргә яраксыз итә, эшләгән кешеләр хисабына яшәргә гадәтләндерә. Ялкау кеше җәмгыятьтә хөрмәт ителми, аның гамәлләре гаеп санала һәм ул бернәрсәгә дә лаек түгел: *Әрәм тамакка ипи катысы да хәрәм.*

Образлы яктан *хезмәт* фразеологик берәмлекләрдә, мәкальләрдә һәм әйтемнәрдә соматик һәм зоонимик лексемаларда чагылыш таба. Мәсәлән, аның белән бәйле күпсанлы стереотипик күзаллаулар «кул» квазисимволы ярдәмендә ачыла: *Күз – куркак, кул – батыр.* Биредә эшкә батыр кеше күз алдында тотыла.

Кулның бер өлешен белдергән *бармак* сүзе аркылы эшләргә теләмәү, хезмәткә карата игътибарсызлык белдерелә: *бармакка бармак сукмау.* «Бармакка бармак та сукмаган» кеше гаеп ителә.

*Беләк* сүзе ярдәмендә тырышып эшләү мәгънәсе белдерелә. Әлеге образ телдә башка лексемалар ярдәмендә тасвирлама рәвештә чагылыш таба: *җиң сызганып.*

*Кул* образында хезмәт эшчәнлегенең сыйфаты белән бәйле уңай стереотип та чагылыш таба: *кулы кулга йокмый; кулы килә; кулында ут уйната* һ.б. Тискәре коннотацияләр түбәндәге берәмлекләр ярдәмендә белдерелә: *кулында эш күгәрә; кулыннан берни килми* һ.б.

Шул рәвешле *кул* лексемасы кергән берәмлекләрнең

квазиденотатив эчтәлеге хезмәт һәм кешенең кыйммәтен, осталык дәрәҗәсен һ.б.ны билгели.

Татарларның аңында теге яисә бу эшнең башкарылуы белән бәйле стереотип күзаллауларны чагылдыра торган «аяк» квазисимволы да мөһим урын алып тора. Аның эчке формасы хезмәткә карата начар мөнәсәбәтне белдерә, шул сәбәпле «аяк» квазистереотипын, нигездә, тискәре коннотацияләр тәшкил итә: *аяк өстеннән генә эшләү; аягы белән эшләгән. Аяк* образы эшләп арыган кешене дә белдерә: *аяксыз калу; аяктан егылганчы эшләү* һ.б.

«Аяк», «теш» һәм «авыз» квазисимволлары ярдәмендә эш һәм аның нәтиҗәсе арасындасгы мөнәсәбәт турындагы күзаллаулар вербальләшә: *Аягың ләпелдәп торса, авызың чәпелдәп торыр; Эшең каты булса, тешеңә йомшак булыр.* Ягъни «кем эшләми, шул ашамый».

Хезмәт вакытында чиктән тыш көч куюның стереотипы «тир» квазисимволында чагылыш таба. Ул үзенә күрә эшне бәяләү берәмлеге буларак күзаллана: *Тиргә батып эшләгәч, тәмле итеп ашарсың.*

Шундый ук мәгънә *бит* һәм *чәч* лексемаларына да салынган: *бит белән җир себерү; чәч белән идән юу.*

Акыл хезмәте турындагы күзаллаулар «баш» квазисимволы белән белдерелә: *баш белән эшләгәнче, кул белән эшләү җиңелрәк.* Башның образ буларак сайлануы турыдан-туры аның әлеге эшчәнлекне башкаручы орган булуы белән бәйле.

Хезмәткә уңай һәм тискәре мөнәсәбәт белдерелгән вакытта мәкальләрдә *бүре, эт, ат, сыер* һ.б. зоонимнар да кулланыла: *Бүренең көче тешендә, кешенең көче эшендә; Эт кебек эшли, ат кебек ашый; Авыр йөкне ат тарта, авыр эшне ир тарта.*

Мисаллардан күренгәнчә, мәкальләрдә соматизмнар һәм зоонимнар, хезмәткә, тырыш һәм ялкау кешегә карата билгеле бер мөнәсәбәтне белдереп, көчерелмә мәгънәдә кулланылалар.

Йомгаклап әйткәндә, *хезмәт* халык аңында, уңай күренеш буларак, рухи һәм матди кыйммәтләрне билгеләүче нигез ролен үти. Шул сәбәпле ялкаулык һәм эшсезлек җәмгыятьтә тискәре бәяләмә ала.

**Әдәбият**

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда / җыючы, төзүче, кереш сүз авторы Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Т. 1. 916 б.

*Савенкова Л.Б.* Русская паремиология: семантический и лингвокультурологический аспекты. Ростов н/Д: Изд-во Рост. ун-та, 2002. 239 с.

*Ситарама К., Когделл Г.* Основы межкультурной коммуникации // Человек. 1992. №2. С. 51–64.

***Сәгъдиева Фәүзия Кәбир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145'373.21

***И.И. Гаттарова***

# ТАТАР АВЫЛЫ МИКРОТОПОНИМИЯСЕН ӨЙРӘНҮ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

В статье рассматриваются структурные и лексико-семантичекие особенности микротопонимии татарской деревни. Исследование проведено на основе материала, собранного в деревне Бугады Актанышского района Республики Татарстан. Автором также уделяется внимание этимологии географических названий, зафиксированных в данной местности.

**Ключевые слова:** топонимика, топоним, гидроним, этимология, топонимическая легенда.

Географик атамаларның барлыкка килү, үсеш һәм яшәеш закончалыкларын тикшерүче топонимика фәнендә [Суперанская, с. 175] микротопнимнарны өйрәнү мәсьәләләре аерым урын алып тора. Әлеге мәкалә татар авылы микротопонимиясенең структур һәм лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышлана. Фәнни тикшеренү Татарстан Республикасы Актаныш районы Богады авылында тупланган материал нигезендә башкарылды. Эш барышында микротопонимнарның этимологиясенә дә игътибар ителде.

Богады авылына XVII гасырда нигез салына. Бу хакта җирле риваятьтә түбәндәгечә хикәяләнә: «Богады авылы Башкортстандагы Каңгы Богады дигән авылдан килеп чыккан. Бу авылда ике бертуган ир бала яши. Бервакыт боларның әниләре кайдандыр бик кыйммәтле әйбер табып алып кайта. Әниләре кечесен ярата төшә, шуңа күрә әйберне дә кече улына бирә. Мөмешмөхәммәт исемле олы улы үпкәләп, «Каңгы Богады»сыннан чыгып китә. Ул агач кисеп сал ясый да, Караидел буйлап Агыйделгә төшә. Аннан Бурсык авылына килеп туктый. Шәбез елгасы буйлап җәяүләп китә. Такталачык авылын да үтә. Елгадан йомычка агып килүен күрә дә, монда кеше яшидер, дигән уй белән, су буйлап Гәрәй авылына күтәрелә һәм шунда яши башлый. Вакытлар узгач, бу егет Гәрәй байның кызына өйләнә. Гәрәй бай хәзерге Яңа Богады, Иске Богады урнашкан җирләрне биләгән була һәм ул аларны киявенә бүләк итә. Мөмешмөхәммәт хәзерге Иске Богады җиренә гаиләсе белән килеп урнаша һәм үз авылының «Каңгы» исемен төшереп калдырып, аны Богады дип кенә атый» [Хәлиуллин, б. 171].

Риваятьнең башка варианты да бар: «XIII гасыр башларында Башкортстанның Бүздәк якларыннан хәзерге Яңа Кадермәт авылы тирәсенә, Терпеле авылыннан ерак булмаган урынга бер төркем кешеләр килеп урнашкан. Әлеге урын Кара кура дип аталган. Даими су чыганагы булмау сәбәпле, алар Кара курада

төпләнеп калмаганнар. Эзләнә торгач, Бигҗады елгасының уң як ярына килеп утырганнар. Мари авылы Терпеле тәэсирендәме – яңа урыннарын Чирмешләр урамы дип йөрткәннәр. Ә авылга Яңа Богады дип кушканнар. Алар килгәндә Иске Богады авылы инде булган. Шулай итеп, бер-берсенә бәйсез рәвештә Бигҗады елгасы буенда Яңа Богады һәм Иске Богады авыллары барлыкка килгән» [Информант – Вәлиева Рәйхана].

Чирмеш урамы кешеләренең бер өлеше XVII гасырда Бигҗады елгасы башланган җиргә күченә. Бу авылга Каратал исеме бирәләр (Хәзер Яңа Җияш исеме белән йөри. Иске Җияш авылыннан килеп төпләнүчеләр дә булу сәбәпледер мөгаен). Әлеге авыл 1733 елдан билгеле [Хуҗин, Моратов, б. 258]. 1925 елларда берничә гаилә Яңа Богадыдан көнбатышка китеп, урман эчендә Югары Богады авылына нигез сала. 1977 елда Яңа Богады исеме бетерелеп, халкы Иске Богадыга беркетелә.

Бүгенге көндә Иске Богады авыл җирлегенә Иске Богады (административ үзәк), Иске Солтангол, Югары Богады, Каенлык, Яңа Җияш авыллары карый [Административно-территориальное деление ..., с. 53].

*Богады* – этнотопоним. Ул Иске Богады, Яңа Богады, Югары Богады авыллары исемендә һәм Башкортстанның Бүздәк районында очрый. *Богадының* этимологиясенә кагылышлы фикерләр төрле. Г.Ф. Саттаров фикере буенча, бу этнотопоним «үгез» сүзенә *-ды* топоформантын кушып ясалган: *Богады – бога* «үгез» + *-ды~ҙы, -лы,* ягъни «үгезле». «Республикабызның татар теленең урта диалектына карый торган минзәлә сөйләше таралган регион топонимиясендә әйбернең, билгенең, сыйфатның булуын, табылуын, белдерүче *-лы* кушымчасы урынына, башкорт теле тәэсирендә булса кирәк, *-ды, -ты* кушымчалары килү характерлы күренеш» [Саттаров, б. 101]. Э.Ф. Ишбердин параллель топонимнарны тикшерә һәм Тәтешледәге Богады гидронимын, шулай ук Башкортстанның Бүздәк районындагы Богады ойконимын Башкортстандагы еней кабиләсенең Богады этнонимыннан килеп чыккан дип уйлый. В.Ф. Генинг фикеренчә, Богады этнонимының нигезендә *бог-* форманты ята. В.И. Васильев һәм С.Н. Шитова да шул ук фикерне әйтәләр. М. Кастрен һәм П. Хайдунов фикеренә нигезләнеп, В.Ф. Генинг бу этнонимны, Урал халыкларының үз атамаларыннан килеп чыккан, ул «кеше» дигән төшенчәне белдерә, ди. Илгиз Сафиуллин исә Г.Ф. Саттаров фикерен куәтләп: «Богады халкы Җәнәй ыруыннан чыккан. «Богады», искечәдән тәрҗемә иткәндә, «бога», «үгез», «богалы», «үгезле» дигәнне аңлата. Богады дип телгә җайлаштырганнар. Элек үгезгә табынганнар. Авылның исеме дә шуннан килеп чыккан булырга тиеш», – дип яза [Хәлиуллин, б. 172].

Богады авылы районның зур авылларыннан берсе санала. Авыл топонимнарын барлап чыкканнан соң, аларны түбәндәге типларга бүләргә мөмкин:

1. Гидронимик терминологиягә нигезләнгән топонимнар:

*Бижҗады елгасы* (потамоним) – Сөннең сул кушылдыгы. Елга башы Югары Богады авылыннан 2,5 км көньяк-көнбатыштарак, тамагы Аеш авылыннан 2 км көнчыгыштарак. Гидроним антропонимик чыгышка ия: Бижҗад (ы) + «елга» аппелятивы.

*Аккош күле* (лимноним) – Меңнәр авылына барган вакытта Яңа Богадыда калучы сазлавык. Ф.Г. Гарипова әлеге гидронимны хайваннар дөньясын чагылдыручы атамалар рәтенә кертә. Мондый гидронимнар әлеге елга ярларының нинди җәнлекләргә һәм кошларга, нинди йорт хайваннарына, балыкларга бай булуын күрсәтеп тора [Гарипова, 1991, с. 64].

*Каенсаз(ы)* (гелоним) – Каенлык авылында урнашкан. Сазлыкның исемен авыл исеме белән тиңлиләр. Атама «каен» һәм «саз» сүзләре кушылып ясалган. Татар телендә «*саз*» төшенчәсе саз сүзе белән белдерелә (чагыштырыгыз: казак, каракалпак, нугай – *саз*, башкорт – *һаҙ*, алтай, хакас, себер татарлары – *сас* «саз»). Без биредә угыр, болгар һәм татар телләре материалында *р* ~ *з* авазлары тәңгәллеге (ротацизм) күренеше белән очрашабыз; *сар* ~ *саз* = «саз». Чагыштырыгыз: *Сарбаш, Сарзас, Сарсак* (Татарстандагы елгалар) [Гарипова, 1984, б. 102]. Мөслим районында Каенсаз исемен йөртүче татар авылы бар [Саттаров, б. 58]. Ф.Г. Гарипова хезмәтенә таянып (1991), *Каенсаз* атамасын үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы күренешләренә нигезләнгән топоним дип әйтә алабыз. Галимә фикеренчә, болгар чорында мондый топонимнар киң таралыш алган булган: *Җүкәтау, Тубылгытау, Каенлык, Имәнлебаш, Каенсаз* [Гарипова, 1991, с. 135].

*Тарлау җире* (гелоним) – Сәфәр белән Иске Богады арасында калучы сазлык җир. Әлеге җир элек Яңа Богады җирләренә караган, колхозлаштыру чорыннан соң Иске Богады җиренә күчкән. Сазлык тар гына өчпочмаклы җирне тәшкил итә [Информант – Хамматуллина Дифинә]. *Тарлау* сүзенең килеп чыгышын да «тар», «кысан» мәгънәсендә аңларга кирәктер. Г.Ф. Саттаров хезмәтендә исә (1998) *тарлау* сүзе көтүлекне белдерүче җирле географик терминнар исемлегенә кертелгән. Автор фикеренчә, минзәлә сөйләшендә әлеге сүзне мал-туар йөри торган көтүлекне белдерү өчен кулланганнар [Саттаров, б. 105–106].

2. Җирле оронимик терминологиягә нигезләнеп ясалган топонимнар:

*Дегет / Нефтянниклар чокыры* – бу чокыр урынында нефть чыгарганнар дигән фикер бар (*Дегет базы* дип тә йөрткәннәр).

*Тегермән чокыры* – әлеге чокыр урнашкан җирдә Йосыф исемле байның җил тегермәне булган.

*Әпәт чокыры* – Әпәт исемле кешенең йорты янында урнашкан чокыр. Антропонимик чыгышлы ороним.

*Хазна чокыры* – бу чокырның тарихы аеруча кызыклы: бер бай зират белән юл арасына чокыр чокып хәзинә күмдем

дигән хәбәр тараткан. Бөтен авыл халкы хәзинә, байлык табам дип, ул чокырны бик озак вакыт чокып азапланып беткән. Хәтта тимерләр белән эзләгәннәр, тик таба алмаганнар. Шушы хәлләрдән соң чокырны *Хазна чокыры* («хәзинә» сүзеннән) дип атый башлаганнар [Информант – Хөснимәрданова Баян].

Төрки телләрдә *чокыр* термины еш кулланылышта йөри. Мәсәлән, якут телендә *ункюр* – «текә ярлы тирән күл, текә яр»; казак телендә *чукур, чункур* – «чокыр»; үрәнхәй телендә *ӱң-гӱр* – «оя, аю оясы». Алар барысы да казып ясалган урыннарны белдерә. Моннан тыш халха-монгол телендә – *хунхур* «түбәнлек, чокыр, түбән урын», бурят-монголларда *хунхэр* «чокыр» сүзләре бар [Гарипова, 2010, б. 146].

3. Микротопонимнар:

*Әхмәт чишмәсе* Биҗады елгасына коя. Авыл халкы чишмәне Әхмәт исемле кеше хөрмәтенә шулай дип атый. Антропонимик чыгышлы микротопоним.

*Пар чишмә* – яшь йөрәкләрне парлаштыручы, кавыштыручы чишмә. Әгәр кәләш белән кияү шул чишмәдән су эчә икән, аларның мәхәббәте *Пар чишмә* суыдай саф, чиста булыр [Информант – Хамматуллина Дифинә]. Микротопоним *парлы* һәм *чишмә* сүзләреннән килеп чыккан. *Чишмә* аппелятивы фарсы, кара-кыргыз һәм башка төрки телләрдә дә «чишмә, чыганак» мәгънәсен, елга, инешләрнең башланган урынын белдерә [Гарипова, 2010, б. 141].

*Олы Бүләк аланы* – Яңа Җияш һәм Каратал авыллары арасында урнашкан алан. *Кече Бүләк әрәмәсе* – Сәфәр һәм Богады авыллары арасындагы ялан. Татарча *алан* географик термины борынгы төрки *алаң* «яссы, тигез» сүзеннән [Садыкова, с. 8].

4. Урбанонимик терминологиягә нигезләнеп ясалган топонимнар:

а) годонимнар:

*Югары оч урамы* (Җәбрәйләр урамы дип тә йөрткәннәр) – Яңа Богады авылының Иске Богады ягындагы урамы.

*Арт урам* (Югары очка соңрак өстәлә). Беренче булып Сәлихҗан дигән кеше йорт җиткергәнгә, бу урам *Сәлихҗан урамы* буларак та билгеле.

*Су буе урамы* – Биҗадының сул як ярында урнашкан урам.

*Аръяк урамы* – Пар чишмәнең икенче ягында, ягъни Биҗадының сул ярында Иске Солтанголга таба сузылган урам.

*Үзәк урам.* Яңа Богады авылын Иске Богады авылы белән тоташтыра.

*Түбән оч урамы* – түбәнлектә урнашкан урам. Иске Әлем авылына таба сузылганга, бу урам *Иске Әлем урамы* дип тә йөртелә.

*Чатлыкай юлы* – Меңнәр һәм Михайловка авылларына китүче юл. Одоним чатлардан («развилка») гыйбарәт булганга шулай аталгандыр дигән фикер бар.

*Әхмәт күпере* – Әхмәт исемле кеше төзегән. Аның астыннан Әхмәт чишмәсе ага.

*Бурлар күпере* – Сәфәр авылына чыгып китә торган якта урнашкан күпер. Ул Югары Богады янындагы рус авылы Афанасьевка (юкка чыккан авыл

[Хәлиуллин, б. 171]) исеме белән аталган күлдән агып чыгучы инеш аша салынган. Бу тирәдә, имеш, кеше ашаучылар яшәгән (әлеге факт 1920–1921 ачлык елларына бәйләп искә алына) [Информант – Вәлиева Рәйхана].

ә) геонимнар: *Югары оч Мәчет тыкрыгы, Түбән оч Мәчет тыкрыгы.* Болар авыл тыкрыкларының элеккеге атамалары. Бүгенге көндә исә авыл тыкрыкларын кемнең йорты янында урнашкан – шуның исеме белән атыйлар. Мәсәлән, *Фая тыкрыгы, Сәйдекәй тыкрыгы, Хәмит тыкрыгы* һ.б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, авыл җирлегендәге микротопонимнар конкрет функция башкаралар. Аерым алганда, алар объектның төгәл урынын билгеләргә ярдәм итәләр. Шуның белән бергә, әлеге атамаларда билгеле бер дәрәҗәдә авыллар тарихы, авыл халкының көнкүреше белән бәйле үзенчәлекләр дә чагылыш таба.

**Әдәбият**

Административно-территориальное деление Республики Татарстан (справочник) / под ред. Премьер-министра РТ Р.Н. Миннеханова. Казань: Центр инновационных технологий, 2005. 456 с.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан гидронимнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 224 б.

*Гарипова Ф.Г.* Исследования по гидронимии Татарстана. М.: Наука, 1991. 294 с.

*Гарипова Ф.Г.* Аккошлар иле – Актанышка сәяхәт. Казан: ТӘһСИ, 2010. 167 б.

*Саттаров Г.Ф.* Татар топонимиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1998. 198 б.

*Суперанская А.В.* Что такое топонимика? М.: Наука, 1985. 182 с.

*Хуҗин Й.А., Моратов Ф.М.* Актаныш – туган җирем. Казан: Идел-Пресс, 2010. 500 б.

*Хәлиуллин И.* Актанышым – ак илем. Казан: Идел-Пресс, 2010. 544 б.

***Гаттарова Инзилә Илнур кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының лексикология*
*һәм диалектология бүлеге аспиранты*

УДК 811.512.145'282

*А.Ә. Бәдртдинова*

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ УРТА ДИАЛЕКТЫ ВОКАЛИЗМ СИСТЕМАСЫНА КҮЗӘТҮ

Статья отражает систему вокализма говоров среднего диалекта татарского языка, а именно особенности употребления некоторых гласных фонем. Также есть краткий исторический обзор изучения фонетики среднего диалекта татарского языка.

**Ключевые слова:** диалект, вокализм, фонема, гласные, огубленные, неогубленные, длинные, краткие.

Татар диалектологиясенең фән буларак барлыкка килүе А.Г. Бессонов, Н.Ф. Катанов кебек танылган галимнәрнең XIX гасыр азагында алып барган эшчәнлеге белән бәйле. Ләкин XX гасырның 40 нчы елларына кадәр диалектларны өйрәнү кайбер ачыклаулар, аерым эзләнүләр, азсанлы экспедицияләр яки урыннарга анкета җибәреп тутырту рәвешендә генә бара.

А.Г. Бессоновның 1881 елда «О говорах Казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам» хезмәте басылып чыга. Шулай ук В.В. Радловның «Образцы народной литературы тюркских племен» (1872), «Опыт словаря тюркских наречий» (1872) һ.б. хезмәтләрендә дә татар теле сөйләшләренең үрнәкләре, диалектизмнар бирелгән.

Урта диалект сөйләшләре буенча иң беренче саллы хезмәт итеп күренекле галим Җ. Вәлидинең 1927 елда басылган «Татар теленең Казан диалекты турында» исемле хезмәтен атарга була. Җ. Вәлидинең үзе тарафыннан тупланган бай фактик материал нигезендә язылган хезмәтләре һәм «Татар диалектологиясе буенча сораулыклар»ы, уку программалары югары уку йортларында укучы студентларга лекцияләр төзү өчен нигезле чыганак булып тора.

Татар диалектологиясен тудыруда СССР Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы, профессор В.А. Богородицкийның роле зур. Ул җанлы сөйләм телен җентекләп өйрәнә һәм беренче тапкыр татар теле диалектларына гыйльми характеристика бирә. В.А. Богородицкий, рус диалектологиясе белгече буларак, татар диалектологиясендә дә теоретик мәсьәләләрне күтәрә. «Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками» (1934) һәм «Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию» (1933) дигән хезмәтләрендә ул татар диалектологиясе мәсьәләләрен барлык төрки телләрне чагыштырма тарихи аспектта өйрәнү күзлегеннән чыгып тикшерә. Шулай ук татар сөйләшләренең авазлар составын һәм сингармонизм законын кардәш телләр белән чагыштыра.

XX гасырның 30 нчы елларыннан башлап, төрле төбәкләрдә яшәүче татарларның җирле сөйләшен экспедицияләр ярдәмендә өйрәнү нәтиҗәсендә материал җыю буенча сораулыклар, укыту программалары төзелә, 1947 елда Л. Җәләй авторлыгында татар диалектологиясеннән беренче дәреслек дөнья күрә.

Л.Т. Мәхмүтова хезмәтләрен дә әйтеп үтәргә кирәк. 1974 елда «Татар диалектологиясе буенча материаллар» җыентыгында аның «Татар теленең бастан сөйләше» дигән мәкаләсе басыла.

1960–1970 елларда диалектология өлкәсендә Ф.Й. Йосыпов тарафыннан гаять зур эш башкарыла. Аның сөйләшләрне өйрәнүгә багышланган күп кенә хезмәтләре дөнья күрә. 1967 елда «Татар теле һәм әдәбияты» җыентыгында галимнең «Эчкен сөйләшенең кайбер фонетик үзенчәлекләре» исемле мәкаләсе басыла. Биредә Ф.Й. Йосыпов күп кенә тел күренешләренә анализ бирә.

Ф.Й. Йосыпов сафакүл сөйләшен дә тикшерә. Әлеге сөйләшкә багышланган хезмәте 1969 елда «Татар теле һәм әдәбияты» җыентыгының 4 нче китабында «Сафакүл сөйләменең кайбер фонетик үзенчәлекләре» исеме астында дөнья күрә.

1974 елда «Татар теле диалектологиясе буенча материаллар» җыентыгында Ф.Й. Йосыповның «Урта диалектның нагайбәк сөйләше» дигән мәкаләсе басыла.

Ф.Й. Йосыповның 1979 елда «Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре» исемле китабы басыла. Ул Чиләбе һәм Курган өлкәләрендәге татар сөйләшләренең фонетик һәм грамматик үзенчәлекләрен тикшереп анализлый.

1969 елда «Татар теле һәм әдәбияты» җыентыгында Д.Б. Рамазанованың «Әгерҗе татарлары сөйләшенең фонетик үзенчәлекләре» дигән мәкаләсе басыла.

1970 елларда Ф.С. Баязитованың монографияләре, фәнни җыентыкларда һәм журналларда күпсанлы мәкаләләре басылып чыга. 1971 елда чыккан «Яшь галимнәрнең конференция тезислары» җыентыгында Ф.С. Баязитованың «Түбән Кама районындагы татарлар сөйләшенең фонетик үзенчәлекләре» исемле хезмәте дөнья күрә. Биредә галим сөйләшкә кыскача фонетик күзәтү ясый. 1974 елда Д.Б. Рамазанова, Пермь татарлары сөйләшен тикшереп, «Татар диалектологиясе буенча материаллар» җыентыгында «Пермь татарлары сөйләшенең фонетик үзенчәлекләре» исемле хезмәтен бастыра. Тагын 1974 елда Ф.С. Баязитова «Татар диалектологиясе буенча материаллар» җыентыгының 3 нче чыгарылышында «Түбән Кама тирәсендәге керәшен татарлары сөйләшенең фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре» исемле мәкаләсен бастыра. Шул ук елда басылган китапта тел галиме Ф.С. Баязитованың тагын бер хезмәте укучыларга барып ирешә. Ул мәкалә «Базгыя һәм Сәвәләй авыллары сөйләшенең кайбер фонетик үзенчәлекләренә карата» дип атала. Галим Татарстанның Әлмәт районы Сәвәләй, БАССРның Бакалы районы Базгыя авыллары сөйләшенең фонетик үзенчәлекләрен тикшерә.

Г.К. Якупованың камышлы сөйләшенең фонетик үзенчәлекләрен яктырткан мәкаләсе 1974 елда «Тагар диалектологиясе буенча материаллар» җыентыгында урын ала. Тел галиме бу хезмәтендә күп кенә авазларга характеристика бирә.

70–80 елларда Л.Ш. Арсланов Әстерхан һәм Волгоград өлкәләрендә, Ставрополь ягында таралган татар сөйләшләрен өйрәнә, аларның атласын төзи, хезмәтләр яза, докторлык диссертациясен яклый. Шул хезмәтләрнең берсе 1974 елда «Татар диалектологиясе буенча материаллар» җыентыгында «Башкортстан АССР Бакалы районы Нарат-Чукур авылындагы татар телле мариларда тел арты *к, г,* тартыкларының килеп чыгышы» исеме белән бирелә.

Н.Б. Борһанова Казан арты сөйләшләрен тикшерә һәм авазлар өлкәсендә күп кенә күзәтүләр алып бара. Аның бу өлкәдәге тикшеренүләре 1978 елда басылган «Төрки телләр тарихы һәм килеп чыгышы» исемле китапта дөнья күрә.

1980 елда Т.Х. Хәйретдинова Алма-Атада кандидатлык диссертациясе яклый. Ул Златоуст татарларына хас сыйфатларны, башка диалектлар белән уртак якларны ача һәм төп үзенчәлекләрне авторефератында күрсәтә.

З.Р. Садыйкова Оренбург татарлары сөйләшен өйрәнә, күзәтүләрен үткәрә, әлеге сөйләшнең каян һәм ничек килеп чыгуына да үз нигезләмәсен бирә. Автор өч мөстәкыйль сөйләшне аерып чыгара. Хезмәт исә Казанда 1985 елда «Оренбург татарлары сөйләше» исеме астында басыла.

XX гасырда татар теленең җирле сөйләшләреннән бай фонетик материал җыйналган. Шуны ассызыклап үтәргә кирәк: диалектологлар сөйләшләрдә генә табыла торган уникаль материалны туплап кала алганнар. Югыйсә иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләрнең кызу алгарышы, шәһәрләшү, әдәби телнең җирле сөйләшләргә көчле тәэсире, диалектларның, сөйләшләрнең яки башка телләрнең үзара йогынтысы нәтиҗәсендә бу үзенчәлекләр, борынгы күренешләр төссезләнә, башкача әйтсәк, онытыла, юкка чыга бара.

XX гасырның икенче яртысында күпьеллык фәнни эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, «Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья» дигән исем астында татар теленең 2 томлык диалектологик атласы дөнья күрә. I томны Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова, ә II томны Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдиновалар төзиләр. Атласка барлыгы 214 карта кергән, шуларның 69 ы фонетикага карый. Сузыклар үзенчәлекләре 22 карта тәшкил итә, калганнары – тартыкларга караган карталар.

Биредә аваз төсмерләренең, тәңгәллекләрнең торак пунктларда таралышы күрсәтелгән, теге яки бу үзенчәлек шартлы билгеләр белән бирелгән. Бу карталар нигезендә фонетик күренешләрнең изоглоссасын (таралыш чиген) билгеләү бик уңайлы.

Шулай ук «Татар халык сөйләшләре» җыентыгы да аерым

игътибарга лаек. Бер төркем авторлар – диалектологлар һәм телчеләр коллективы (Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова,Т.Х. Хәйретдинова һ.б.) төзегән бу хезмәттә ике томда татар теленең барлык диалектлары һәм сөйләшләренең үзенчәлекләре, сөйләү үрнәкләре, таралу ареалы бирелгән. Китаплар 2008 елда «Мәгариф» нәшриятында чыга.

Яшь галимнәр арасында ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәре М.Р. Булатова уңышлы гына эш алып бара. Аның татар теле сөйләшләренә багышланган күп кенә хезмәтләре басыла. Мәсәлән: «Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана» (Казань, 2013. 240 с.), Булатова М.Р. Курмантауский говор среднего диалекта татарского языка в этнолингвистическом аспекте» (Казань: Магариф – Вакыт, 2016.384 с.) һ.б.

Татар теленең урта диалекты әдәби телгә якын тора. Бары тик кайбер авазларның әйтелешләрендә генә аермалар бар.

***А авазы.*** Татар теле сөйләшләрендә [а] авазының берничә варианты барлыгы билгеле. *А* авазының татар телендә кулланылышы буенча филология фәннәре кандидаты М.Р. Хәбибуллинаның «Характеристика изоглосс вариантов фонемы [а] в татарском лингвистическом пространстве» исемле диссертациясе игътибарга лаек. Ул [а] фонемасының түбәндәге вариантларын бүлеп чыгарган:

1. [о$^{а}$] – көчле иренләшкән: балтач сөйләше;

2. [а$^{о}$] – уртача иренләшкән: мамадыш, нагайбәк, каргалы, богрыслан, лаеш, норлат, кама тамагы, златоуст, тепекәй, учалы, татар-каракалпаклар, тархан сөйләшләре;

3. [а] – ачык, татар теленең көнбатыш диалектлары өчен характерлы: дөбъяз, пермь, нократ, богырыслан, каргалы, камышлы, нагайбәк, әстерхан сөйләшләре;

4. [а$^{\wedge}$] – бик ачык булган, казан арты-дөбъяз сөйләше өчен хас (нугай тибы); пермь сөйләше;

5. [а*] – уртача ачык.

*А* авазының төрлечә әйтелеше хәтта татар телендә диалектларны бер-берсеннән аера торган төп билгеләрдән санала. Мәсәлән, татар диалектологиясендә урта диалект өчен иренләшкән, көнбатыш (мишәр) диалекты өчен иренләшмәгән (ачык) [а] авазы хас дигән фикер яшәп килә. Әлбәттә, моның күп кенә искәрмәләре дә бар. Беренчедән, [а] авазының иренләшү дәрәҗәсе ягыннан гына да урта диалект сөйләшләре берберсеннән шактый аерылып торалар. Икенчедән, шул ук диалектның кайбер сөйләшләрендә бу аваз рус телендәгечә иренләшмичә, чиста әйтелә. Аның ясалыш чыганагы да, әдәби телгә карaганда, шактый алдарак була. Киресенчә, көнбатыш диалектның кайбер сөйләшләрендә (мәсәлән, Пенза, Волгоград өлкәләрендә) [а] авазы ирен төсмере белән әйтелә.

Иренләшү һәм иренләшмәү үзенчәлегеннән чыгып, урта диалектны, нигездә, ике төркемгә бүлеп булыр иде: 1) иренләштерүче сөйләшләр; 2) [а] авазын

рус телендәге [а] кебек ачык итеп, иренләштерми торган сөйләшләр. Мәсәлән, нагайбәк сөйләше [а] авазын рус телендәге [а] кебек ачык итеп, иренләштерми сөйли торган сөйләшләргә керә. Ләкин, шул ук вакытта «Татар халык сөйләшләре атласы»н («Атлас татарских народных говоров») карасак, [а] авазы изоглоссалары картасында («Лабиализованный и нелабиализованный варианты гласного [а] в односложных корневых словах») а//а° ([а] авазының иренләшкән һәм иренләшмәгән вариантларын параллель куллану) изоглоссы урта диалект сөйләшләренә дә кагыла. Һәм бу сөйләшләр шактый күп, болар дөбъяз, мамадыш, бәрәңге, балтач (шулай ук көчле иренләшкән өченче төре бар), минзәлә, пермь (ачык һәм бик ачык варинаталры да бар), бөре, богырыслан, камышлы, красноуфим (аерым урыннарда [а] авазы ачык әйтелә), эчкен, касыйм, әстерхан, каргалы ([а] авазы – 2 вариантта: иренләшкән [а°] һәм тирән тел арты тартыклары: *к, г, х* янында ачык [а] авазы), түбән кама, нагайбәк, казан арты керәшеннәре (ирен сузыкларыннан соң килгәндә, [а] һәм [ә] авазлары иренләштеру гармониясенә тартыла) сөйләшләре.

Иренләшү дәрәҗәсе белән мамадыш һәм балтач сөйләшләре аерылып тора. Бу сөйләшләрдә [а] авазы көчле иренләшкән аваз булып әйтелә һәм әдәби телдәгедән дә интенсиврак рәвештә яңгырый: *қа°ла°, җа°ма°нсы, ка°қ* һ.б.

[А] авазының әйтелеше аның нинди фонетик позициядә булуына да карый. Мәсәлән, нагайбәкләрдә [а] авазы әйтелеше беренче иҗектәге ирен-ирен [о] авазы йогынтысында ирен төсмере белән әйтелә. Шулай да иренләшү дәрәҗәсе әдәби телдәгегә караганда кимрәк. [А] авазын ачык әйту ягыннан ул урта диалектның касыйм, кистем, казан арты-дөбъяз һәм кайбер керәшен, шулай ук пермь татарлары сөйләшләренә якын тора. Ә инде нократ сөйләшендә, киресенчә, [а] авазы барлык позицияләрдә дә казан арты дөбъяз, нагайбәк, касыйм, пермь татарлары сөйләшендәге кебек ирен төсмереннән башка әйтелә ([а] – ачык, иренләшмәгән).

***Ә авазы.*** [Ә] авазының шулай ук параллель кулланылышы очрый: киң һәм тар [ә] авазлары эчкен, камышлы, нократ, әстерхан, керәшен татарлары, нагайбәк сөйләшләрендә: а) алгы рәт түбән күтәрелештә (киң) (татар әдәби телендәгечә) яңгырый: энә, бәлеш, тәрәзә; ә) нократкистем һәм мордва-каратай сөйләшләрендәге кебек, әдәби әйтелешкә караганда таррак вариантта, күзәтүләргә караганда, ул тар [и], [э]*(е)* сузыклары булган иҗекләрдән соң килгәндә әйтелә: *җиргә, киңәш* (Баязитова, 2006). [Ә] авазының әдәби телдән бераз таррак варианты әстерхан сөйләшендә бар.

Әдәби телдәгечә [ә] авазы барлык сөйләшләрдә диярлек кулланыла: дөбъяз, мамадыш, бәрәңге, балтач, норлат, кама тамагы, нократ, тархан, богырыслан, каргалы, бөре, турбаслы, тепекәй, учалы, златоуст, красноуфим, әстерхан сөйләшләрен-

дә (кайбер очракларда (алдагы иҗектә [и] авазы булса) [ә] авазы чагыштырмача таррак әйтелә); татар-каракалпаклар, нагайбәк, түбән кама керәшеннәре, казан арты керәшеннәре сөйләшләрендә ([ә] авазы шулай ук параллель кулланыла: киң һәм тар (ябык) (күбрәк тар сузыклардан соң) әйтелешле). Пермь, бастан, минзәлә сөйләшләрендә [ә] авазы бераз алдарак әйтелә. Лаеш сөйләшендә [ә] ике вариантта кулланыла: әдәби телдәгечә һәм әдәби телдәгедән бераз алдарак.

Красноуфим сөйләшендә киң [а], [ә] сузыкларын тарайтып әйтү аерым сүзләрдә очрый: соркотыу – саркыту, белеки – бәләкәй; [ә], [е] (э), [ы], [ө] сузыкларын тарайтып сөйләү очраклары бар: чеприк – чүпрәк [Йосыпов, 2004, б. 34–41]. Касыйм сөйләшендә [ә] авазы әдәби телдәгедән бераз алдарак әйтелә.

***О авазы.*** Кулланылышы ягыннан шулай ук иренләштереп һәм иренсезләштереп әйтелә торган вариантлары бар. Иренләшмәгән [о] авазы – дөбъяз, камышлы, әстерхан, богырыслан сөйләшләрендә. Богырыслан, әстерхан сәйләшләрендә параллель вариантлары кулланыла – *о°//о* (әстерхан сөйләшендә иренсезләштереп, *ы* авазына якынайтып һәм кыска итеп әйтелә; киң әйтелешле варианты (күбрәк өлкән яшьтәге кешеләр телендә) яши).

Нократ сөйләшендә нык иренләшкән [о] авазы тирән тел арты яки тел арты [к], [къ] авазларыннан соң кыска [ы] сузыгын алмаштырып килә: кор – кыр, корок – кырык; [у] сузыгы ике төрле вариантта кулланыла; [ү] сузыгы да шулай ук [о] авазы нократ урынчылыгында гына иренләшә, хәтта [о] авазы [ы] сузыгын да иренләштерергә мөмкин; сирәк кенә [у], [ү]авазларын иренсезләштерү очраклары бар: ылым – улым, тегел // дегел – түгел [Йосыпов, 2003, б. 125–129].

Калган сөйләшләрдә әдәби телдәгечә.

***Ө авазы.*** Иренләшмәгән [ө] авазы дөбъяз, камышлы, әстерхан (әдәби телдә [ө] авазы иренсезләштереп, [е] авазына охшатып әйтелә), иренләшкән [ө] авазы: башка сөйләшләрдә.

***У-ү авазлары.*** Бераз арттарак, кыпчак тибы изоглоссасы (атлас буенча): дөбъяз, мамадыш, бәрәңге, балтач, лаеш, норлат, кама тамагы, тархан, бөре, минзәлә, пермь, нагайбәк, камышлы, каргалы, богырыслан, бастан, златоуст, тепекәй, учалы, красноуфим, татар-каракалпаклар, касыйм, әстерхан, казан арты керәшеннәре сөйләшләрендә. Алдарак, огуз тибы изоглоссасы: камышлы, әстерхан сөйләшләрендә. Каргалы сөйләшендә [ү] авазының әдәби телдәгедән алдарак әйтелү очраклары бар. Әстерхан сөйләшендә нык иренләшкән, киң әйтелешле [ө] авазына якын варинаты бар. [Ү] авазын алда кулланган очраклар камышлы сөйләшендә генә бар. Красноуфим сөйләшендә [о], [ө], [у], [ү] авазларын тарайтып, ирен гармониясен бозып сөйләү аерым сүзләрдә күзәтелә: шоморт // шымырт, төтөн // тетен. Эчкен, нократ сөйләшләрендә [у]-[ү] авазлары параллель, арттарак һәм алдарак (кыпчак һәм огуз

типлары) кулланыла. Минзәлә, нократ сөйләшләрендә [ү] авазын алдарак әйтү очраклары бар.

Түбән Кама керәшеннәре: [ү] авазының алда әйтелүе Лениногорск районы Федотовка, Әлмәт районы Васильевка авылларында гына очрый [Атлас...].

***И авазы.*** 2 вариантта нократ сөйләшендә: озынрак әйтелә торган һәм кыскарак әйтелә торган.

***Е (э) авазы.*** Красноуфим сөйләшендә [е] *(э)* – [ү] белән алмаштырыла: түгендә – тегендә. Нократ сөйләше: [е] *(э)* сузыгы артык кыска, әйтелми. Нигездә [и] сузыгын алмаштырып килә: семез – симез, кэл – кил; [э] *(е)* – 2 вариантта: тар һәм киң.

***Ы авазы*** урта диалект сөйләшләрендә әдәби телдәгечә кулланыла. Турбаслы, сафакүл сөйләшләрендә дә әдәби телдәге кебек.

Иң киң таралган аерымлыклар саналып киткән авазларга хас. Калган вариантлар бары тик аваз тәңгәллекләренә генә кайтып кала.

Шулай итеп, татар теленең урта диалектында [а], [ә], [о], [ө], [у], [ү] авазлары параллель кулланыла (иренләшкән һәм иренләшмәгән вариантлары, кыска һәм озын, алдарак һәм арттарак әйтелү вариантлары). Шулай да, өстә язылганнардан чыгып, төп билгеләр итеп түбәндәгеләрне атарга була:

1. *А//а*$^{о}$ (параллель куллану) – 60% сөйләштә күзәтелә, күбрәк ачык [а] авазы кулланылган сөйләшләр – 27%, күбрәк иренләшкән [а$^{о}$] – 41%.

2. Иренләшмәгән [о], [ө] авазлары 10% сөйләштә, калган сөйләшләрдә – әдәби телдәгечә.

3. [У] авазының бераз арттарак әйтелеше 80% сөйләштә; алдарак өйтү – 10% сөйләштә. Башка сэйләшләрдә әдәби телдәгечә.

**Әдәбият**

Атлас татарских народных говоров. http://newipi.antat.ru/.

*Баязитова Ф.С.* Нократ сөйләше. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор. Казан: Дом печати, 2006. 240 б.

Татар халык сөйләшләре: ике китапта. Беренче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ. б. Казан: Мәгариф, 2008. 463 б.

*Йосыпов Ф.Й.* Красноуфим татарлары: тарих, тел, фольклор. Казан: Школа, 2004. 376 б.

*Йосыпов Ф.Й.* Татар теленен диалектлары. Урал сөйләшләре. Казан: Мәгариф, 2003. 351 б.

***Бәдртдинова Алсу Әнис кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының лексикология*
*һәм диалектология бүлеге кече фәнни хезмәткәре*

УДК 801.83=512.145

*И.Г. Гомәров*

# ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫНА КАГЫЛЫШЛЫ АРХИВ МАТЕРИАЛЛАРЫ:

## кулъязма мирасын, шәхси әйберләрен исәпкә алган акт кәгазе

Язучының тормыш һәм иҗат сәхифәләре турында бернинди ялганнарга һәм субъектив бәяләргә, басымнарга бирешми сөйли торган төп чыганаклар, әлбәттә, аның кулъязмалары, шәхси язулары. Бу фикер XX гасыр башы татар әдипләре, аерым алганда, Фатих Әмирхан иҗаты хакында сөйләгәндә дә актуаль яңгырый. Мәгълүм булганча, Фатих Әмирханның әдәби мирасын чагылдырган кулъязма чыганаклар, бер генә урында тупланмыйча, берничә архив һәм музей фондларына сибелгән. Бүген бу төр язмалар Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Татарстан Милли музее фондларында, шәхси архивларда саклана.

«Фәнни Татарстан» журналының әлеге санында укучылар игътибарына Фатих Әмирханның тормыш юлын, иҗатын, үзеннән соң калдырган әдәби мирасын тулырак күзалларга мөмкинлек бирә торган бер тарихи чыганак тәкъдим ителә. Бу ядкәр – гакыднамә, ягъни әдипнең вафатыннан соң аның фатирында калган кулъязма мирасын һәм шәхси әйберләрен исәпкә алган акт кәгазе. Бу документ язучының, вафатына кадәр, үзе билгеләп калдырган әдәби васыйлары (*васыятен үтәүчеләре*) – Галимҗан Шәрәф, Ибраһим Бикколов һәм энесе Ибраһим Әмирханнар тарафыннан 1926 елның 17 октябрендә төзелгән һәм имзаланган. Әлеге тарихи чыганак бүген Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана[1].

Чыннан да, Фатих Әмирхан үлгәннән соң, дуслары әдипнең фатирында булган барлык язмаларының, шәхси әйберләренең беренчел тасвирламасын төзиләр: «1926 нчы ел июль аенда мәрхүм әдип Фатих Әмирханның әсәрләренең әдәби васыйлары – без – Галимҗан Шәрәф, Ибраһим Бикколов мәрхүмнең фатирында табылган бөтен кулъязмаларын, хатларын, мәрхүмнең тәрҗемәи хәленә һәм исемен мәңгеләштерүгә бәйләнешле булган сәнәдләрне, китапларны, рәсемнәрне, кием вә бүтән материалларны барлап, һәммәсен язып алдык» диелә әлеге акт кәгазендә. Биредә материаллар

[1] Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 16 нчы фонд, 1 нче тасвирлама, 48 нче саклану берәмлеге.

3 төркемгә бүлеп теркәлгән. «Беренчесе – язучының кульязмалары. Барлыгы 47 пункттан гыйбарәт. Икенчесе – кеше кульязмалары, 11 берәмлек. Өченчесе – мәрхүмнең биографиясе өчен кирәкле материаллар: төрле шәхси язулар теркәлгән куен дәфтәрләре, көндәлекләр, хатлар һ.б., барлыгы 17 берәмлек. Дүртенчесе – Фатихның төсе итеп сакланырга тиеш булган һәм тиеш булулары ихтимал тотылган, Фатихның шәхси хәятенә гаид булган нәрсәләр: үзе утырып йөргән тәгәрмәчле урындык, кыш урамда утырыб йөри торган чана, киемнәре, өй җиһазлары һ.б. Барлыгы 40 берәмлек».

Васыйларның килешүе буенча бу әйберләрнең бер өлеше Дәүләт музеена тапшырылырга, ә күпчелеге беркайда да тапшырылмыйча, энесе Ибраһим Әмирхан кулында сакланырга тиеш була. Беренче карашка васыйлар тарафыннан килешенгән бу карар гайре табигыйрәк күренсә дә, аның асыл мәгънәсен ачык төшенергә мөмкин. Мәгълүм булганча, узган гасырның 20 нче еллары үткәндәге рухи мираска карата, шул исәптән, Фатих Әмирхан иҗатына мөнәсәбәттә дә, карашларның шактый катлаулы һәм каршылыклы чоры. Әдипнең васыятен үтәүчеләр дә моны ачык аңлаганнар һәм бу бәһасез мирасны вакытлар уңай якка үзгәргәнчегә кадәр шәхси кулда җыеп сакларга карар кылганнар. Әмма ни кызганыч, утызынчы елларның шәхес культы шаукымы аларның үзләрен дә аямый (Ибраһим Әмирхан, Ибраһим Бикколов атып үтереләләр, Галимҗан Шәрәф сөргенгә җибәрелә). Шул сәбәпле бу тасвирламадагы тәфсилләп саналган язмаларның, шәхси әйберләрнең күбесенең язмышы бүгенгә кадәр билгесез булып кала. Дөрес, кайберләре төрле елларда Татарстан Милли музеена, Институтка тапшырылганнар һәм безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәр. Әмма күпчелеге билгесезлеккә дучар ителгән, югалган булып санала.

Бу өлкәдә махсус эзләнүләр уздыру билгеле бер нәтиҗәләр дә бирергә мөмкин дип уйлыйбыз. Әйтик, әлеге акт кәгазендә дә теркәлгән, һәм татар укучысын озак еллар үзенең билгесезлеге белән ымсындырып килгән «Хәят» повестеның икенче кисәге табылу әлеге фикерне тагын бер кат раслый. Шунысы игътибарга лаек: максатчан рәвештә үткәрелгән эзләнүләрдән соң, әлеге дәфтәрләрнең Татарстан Республикасы Милли музее фондларында саклануы ачыкланды. Алар 2000 еллар башында Галимҗан Шәрәфнең улы Арыслан Шәрәф тарафыннан, Милли музей хезмәткәрләре Рәмзия Абзалина һәм Лилия Байбулатовалар аша, музейга тапшырылганнар. Повестьның беренче өлеше, нәкъ акт кәгазендә искәртелгәнчә, ундүрт дәфтәрдән, 136 биттән гыйбарәт. Ә икенче өлеше исә алты дәфтәргә теркәлгән, тәмамланмаган. Димәк, акт-чыганакта билгеләнгән ун дәфтәрдән алтысының язмышы инде бүген ачыкланды дияргә мөмкин. Гакыйднамәдә исәпкә алынган башка язмалар һәм шәхси әйберләрнең дә киләчәктә табылуына өмет бар.

## Гакыднамә

1926 нчы елның июль аенда мәрхүм әдиб Фатих Әмирханның әсәрләренең әдәби васыйлары без – Галимҗан Шәрәф, Ибраһим Биккулов мәрхүмнең фатирында табылган бөтен кульъязмаларын, хатларын, мәрхүмнең тәрҗемәи хәленә һәм исемен мәңгеләшдерүгә бәйләнеше булган сәнәдләрне, китабларны, рәсемләрне, кием һәм җиһазларны вә бөтен материалларны барлаб һәммәсен языб алдык. Ул кулъязмалар, материаллар һәм әйберләр түбәндә язылганлардан гыйбарәт.

### *I. Кулъязмалары.*

1. «Танец кичәсе». Ике дәфтәр. Бер якка язылган уналты бит. Беренче бите буш.

2. «Салихҗан кари». Ике дәфтәр. Бер якка язылган ундүрт бит. Беренче бите буш. Дүртенче битендә астдан бишенче һәм алтынчы юллар арасында, бишенче битендә өстдән унөч, унҗиде, унсигез, унтугыз юлларда Салихҗан кариның сүзләре язылмыйча буш калган. Алтынчы битдә өстдән дүртенче, унөченче, унҗиденче юлларда берәр сүзлек ачык урынлар бар. Тугызынчы битдә өч урында, унынчы битдә өч урында, унберенче битдә дүрт урында, уникенче битдә биш урында, унөченче битдә ике урында, ундүртенче битдә ике урында ачык калган урынлар бар.

3. «Хәзрәт үгетләргә килде». Ике дәфтәр. Унөч ярым бит. «Хәзрәт үгетләргә килде»нең «Аң» журналында басылган басма нөсхәсе.

4. «Сәмигулла абзый». Ике дәфтәр. Бер якка язылган унбиш бит. Актык бите тулмаган.

5. «Яшьләр». Беренче һәм өченче пәрдәләре, сигез дәфтәрдә. Үз кулы белән язылган янә бер дәфтәрдә икенче пәрдәсе.

6. «Корбан». Бер дәфтәр. Тугыз бит. Шуның ук «Аң»да басылган басма нөсхәсе.

7. «Кадерле минутлар». Алты дәфтәр. Илле алты бит. Кайбер җирләрдә язылмый калган урынлар бар.

8. «Татар кызы». Икешәр дәфтәрдә ике нөсхә. Бер нөсхәсе уналты бит, берсе – унҗиде бит.

9. «Тигезсезләр». Унбиш дәфтәр. Бер йөз кырык дүрт бит. /

10. «Чәчәкләр китерегез миңа». Өч дәфтәрдә өч нөсхә. Берсе үз кулы белән язылган.

11. «Шәфигулла агай». Өч дәфтәр. Утыз өч бит.

12. «Шәфигулла агай». Бер дәфтәр. Бу дәфтәрнең «Шәфигулла агай» хикәясе белән мөнәсәбәте булмаска кирәк. Монда Шәфигулла агай – сәүдәгәр. Бу дәфтәр үз кулы белән язылган.

13. «Хәят». Хәятнең беренче җөзьэ. Ундүрт дәфтәр. Бер йөз утыз алты бит.

14. «Хәят». Хәятнең икенче җөзьэ. Үз кулы белән язылган. Барысы ун дәфтәр. Ләкин дәфтәрләрнең барысы да номерлы түгел һәм кайбер дәфтәрләр тулы түгел. Шулай ук кайберләрендә бер үк текстның тәкрарлары бар.

15. «Ислам шәркы кашында гыйшык». Кәгазьгә язылган дүрт бит язу.

16. «Яз исереклегендә». Тугыз бит. Басылган «Аң» битләре.

17. Исемсез бер пьеса. Каһарманлары: Ногман, Рабига, Саҗидә, Сәлах, Исхак, Нәгыймә, Суфия. Бу әсәр тулы булмаган өч дәфтәрдә. Үз язуы.

18. Хыялый бер пьеса. Каһарманлары: өченче, дүртенче ... унынчы бабай һәм әбиләр. Бер дәфтәр. Үз кулъязмасы.

19. «Коточкыч (очыргыч) бер төш». Бер дәфтәрдә. Биш бит. Язуы тәмам түгел. Үз кулъязмасы.

20. «Гыйшык хәле» яки бүтәнчә исемдә – «Хуҗа Насретдин кызы». Бер дәфтәр. Сигез бит. Тәмам түгел. Үз кулъязмасы.

21. Дача турында исемсез алты битле үз кулъязмасы. Дәфтәрдә. Әсәр тәмам түгел.

22. Балалар өчен пьеса. Каһарманлары: Айсылу әби, Чыңгыз, Сөембикә һәм балалар. Бер дәфтәр. Җиде бит. Дәфтәре тәмам түгел. Үз язуы.

23. «Аны күб кешеләр яратмыйлар» диб башланыб киткән, тәмам булмаган бер дәфтәрдә биш битлек үз кулъязмасы.

24. Исемсез бер хикәянең бер кисәге. Каһарманы – Зөләйха. Бер дәфтәр. Ун бит. Үз кулъязмасы.

25. Каһарманы Гөлчәһрә булган башсыз һәм ахырсыз, бер дәфтәргә язылган сигез бит үз кулъязмасы. Хикәя.

26. Салих мөәззин углы Гали турында языла башланган дүрт битлек (бер дәфтәрдә) үз кулъязмасы.

27. Бай баласы, асрау, байның кызы турындагы бер хикәянең башы. Бер дәфтәрдә. Ике бит. Үз язуы. Шул ук дәфтәрнең икенче ягында учительский школа шәкерде Габденнасир турында бер хикәянең башы. Үз язуы.

28. Салих студент турында һәм Тимрасу (?) хәзрәт турында ике дәфтәрдә егерме бер бит язылган бер хикәя. Үз кулъязмасы.

29. Студент Шакир турында 6нчы бабдан башланыб киткән сигез бит кулъязма. Үз язуы. Бер дәфтәрдә.

30. Шәриф исемле каһарман турында революциядә үзендәге тормышдан алыб язылган бер хикәянең кисәге. Бер дәфтәрдә, дүрт бит.

31. Икенче интернационал тормышында ике дәвер. Ике дәфтәр. Барысы уналты бит.

32. Каһарманнары Чыңгыз, Зөләйха булган, Шәрык клубындагы бер кичәдәге бер вакыйга турында язылган дүрт битле кулъязма. Бер дәфтәрдә. Үз язуы.

33. Почта кәгазендә язылган өч битлек, мәдрәсә хәятендән кулъязма. Каһарманнары: Шәйхи Дауд, Исмәгыйль. Шунда ук Идел-Урал хәяте (?) рәисе Шәрәфкә милли идарә һәм милләт мәҗелесе рәисләрендән язылган мөрәҗәгатьнең тәрҗемәсе яки күчермәсе.

34. Яңа бистә җөмһүрияте турында басылган көлке бер хикәя. Дүрт кәгазьдә. Кәгазьләре мәкалә яза торган кәгазьләр. Үз язуы.

35. Футурист һәм имажинистларга ияреб язылган дүрт кәгазьдә пародия. Шигырьләр.

36. «Тегеләр тагын килеб керделәр» диб башланыб киткән ииюханәдәге (?) бер вакыйга турында языла башланган өч кәгазьдәге кулъязма. Үз кулы белән язылган.

37. «Бер хәрабәдә». «Аң» журналында басылган басма кәгазьләр.

38. Кайсы әсәрләренеке икәнлеге мәгълүм булмаган берәр битле вак биш данә-данә кулъязмалар. Үз кулы.

39. «Беренче сөю». Бер дәфтәр. Яза гына башлаган.

40. Имза турында бер изах. Ике кисәк кәгазьдә.

41. Мөхетдин Корбангали юбилеена язылган хат.

42. Өч көнлек исдәлек язылган кара клеенка тышлы көнлек дәфтәр.

43. «Хәят»нең цензура тарафыннан төшерелеб калдырылган урыны.

44. «Гарәфә кич төшемдә» һәм «Кадерле минутлар» басылган китаблар.

45. Хокукый истиляхлар. Бер дәфтәрдә.

46. Җинаи кодекс тәрҗемәсе. Биш дәфтәрдә. Шул ук янә ике дәфтәрдә.

47. Театр юбилеена язылган ике хат (ике нөсхә).

Кулъязмаларны хәзергә музейгә табшырмый, Фатихның сандыгында сакларга.

## *II. Кеше кулъязмалары[1].*

1. «Янгура». Афзал Таһиров. Сары кәгазьдә. Җитмеш алты бит.

2. Мәхмүд Әмирханның «Бер оялчанның көнлек дәфтәре» исемле кулъязмасы.

3. Әбрар Сәгыйдинең «Борынгылар» исемле пьесасы.

4. Хәсән Исхаковның «Яңа мәдрәсәдә» исемле кулъязмасы.

5. Сәмавинең «Әлфирак» исемле шигырь мәҗмугасы.

6. Ченәкәйнең «Мәхәббәт чәчәкләре» исемле шигырь мәҗмугасы.

7. Кадир Гобәйдуллинның ике дәфтәр җинаи кодексы.

8. Ибраһим Әмирханның «Ачык фикер хәзерлә» исемле ике кәгазьдәге мәкаләсе.

9. «Кояш» гәзитәсенә Ишми ишан турында язылган бер мәкалә.

10. «Дарел-мөгаллимәт» турында соралган анкетага Ләбибә Хөсәиния җавабы.

11. «Хан мәсҗеде». Вәлинеке. (Вәли Апанай булырга кирәк).

## *III. Мәрхүмнең биографиясе өчен кирәкле материаллар.*

1. Китаб исемләре язылган яки языла башлаган өч дәфтәр һәм бер кәгазь. Бер данә преферанс уйналган дәфтәр.

2. Исмәгыйль Аитовка язылган сигез данә хат.

3. Фамилия турында Фәтхигә язылган ике хат.

4. Русча ике данә таныкнамә.

5. «Фәтхулла хәзрәт» китабын китабчыларга өләшүне яза башлаган бер дәфтәр.

6. Клеенка тышлы бер куен дәфтәре.

7. Брезен(т) тышлы бер куен дәфтәре.

8. Бер блокнот.

[1] Искәрмә. Кеше кулъязмаларыннан: Хәсән Исхаковның, Әбрар Сәгыйдинең, Ченәкәй, Сәмави, Афзал Таһировның 1, 3, 4, 5, 6 нчы номерлар астында күрсәтелгән нәрсәләре ияләренә табшыру өчен Галимҗан Шәрәфкә табшырылды. Ибраһим Әмирханның кулъязмасы үзенә бирелде. Мәхмүд Әмирханның кулъязмасы Ибраһим Әмирханга табшырылды. Башкалары Фатихның мәктүбләре янына куелды.

9. Катыргы тышлы бер куен дәфтәре. Аның эчендә бер данә үз паспорты.

10. Утыз ике данә үзе генә, гаиләсе белән һәм бүтән һәртөрле кешеләр белән бергә төшкән рәсемләре. Рәсемләр һәммәсе номерланган. Шул рәсемләрдән икәве Ленинградка җибәрелде. Берсе өйдә юк. Юклары: 22, 25, 26 номерлылар.

11. Карандаш белән бер кыздан язылган хат (өйләнү турында).

12. Зариф хәзрәтнең тәрҗемәи хәле. Алты бит. Кечкенә кәгазьдә бер хат.

13. Мәскәүдә мөселман иттифакы җыелышы.

14. Канунлар кодексы турында русча язылган бер мәкалә.

15. Фатихның үзенә һәм әткәсенә язылган бер йөз ун данә хат. Бу хатлар конвертларындан чыгарыб номерланганлар.

16. Төрле адәмләрдән Фатихка язылган бер йөз кырык бер данә хат. Хатларның үзләре дә һәм конвертлары да номерланган.

17. 21 нче елның 7 нче октябрендән башлаб 4 нче ноябрьгә кадәр язылган барысы утыз өч бит кулъязмалы яшел клеенка тышлы көндәлек дәфтәр. Дәфтәрнең эчендә Талиб Гайнуллинның, Фәтхи Бурнашның хатлары, Насих Мөхетдиновның хаты һәм русча телдә Фатихка имза итәргә диб сораб язылган белешмәсе бар[1].

### *IV. Фатихның төсе итеб саклanырга тиеш булган һәм тиеш булулары ихтимал тотылган, Фатихның шәхси хәятына гаид нәрсәләр.*

1. Өйдә утырыб йөри торган тәгәрмәчле урындык (кресло).

2. Урамда үзе әйләндереб йөри торган арба (урындык).

3. Кыш урамда утырыб йөртү өчен ясалган урындык – чана.

4. Үзе яткан ябык аркалы кровать.

5. Кроватьнең ятак җиһазлары: одеял, мендәр, җәймә...[2]

6. Язу әсбаблары: каләмләре, кара савытлары, кибдергечләре, карандашлары.

7. Таҗ (өйдә бәвел итәр өчен эмальле калай савыт).

8. Бәрхет җәймәсе белән бер кечкенә өстәл.

9. Китаблары белән китаблар шкафы[3].

10. Гарәб тормышындан булган рәсемләр белән бизәлгән дивар җәймәсе[4].

11. Аякга кия торган киемләре: итек, кәлүш, сандали, сары ботинка, ак ботинкалар, сары төсдә чүәкләр[5].

12. Киемләре: соры бүрек, панама, галстуклар, ак якалар, манжетлар, кара сиртук, фуражка, камодның бер ящигында төрле керләр (һәрвакыт кия торган чигүле күлмәкләре), ике данә Бохара һәм кара кәләпүшләре, бер комплект ак костюм (пиджак һәм жилет), сиртук кигәндә

---

[1] Бу битдә 17 номер астында язылган бөтен материаллар Фатихның башка нәрсәләре белән хәзергә музейга табшырмый сакларга. Фатихның сандыгында кала.

[2] Вакытлыча буларак калдырыла.

[3] Кала.

[4] Ибраһимга калдырылды.

[5] Сары һәм ак ботинкалары калдырылды Ибраһим карамагына.

күкрәккә киертелә торган әйбер, бер сүҗәнҗә (?) күлмәк, буй-буй бер ак пиджак, бер кара пиджак, сары соры чалбар, бер соры пәлтә, буй-буй кара чалбар, 5 данә төрле төсдәге жилетлар, бер ком төсендә пиджак, тагын бер кара пиджак, кәмәр (?) һәм билбаулары[1].

13. Карточкалары белән дүрт данә альбом[2].

14. Рәсемле кардон дивар пакеты.

15. Күз мәнзәрәсен тәрсим иткән зур табигый картина[3].

16. Сакал кыргычлар: кынлары белән куркынычсыз бритвалар һәм кырыну әсбаблары. Болары камод ящигында.

17. Бер колода карта (иске)[4].

18. Күзлек (пенсне).

19. Юына торган комганы һәм тазы.

20. Камод ящигында төрле язу (записной) дәфтәрләр, журналлар, гәзитләр, китаблар[5].

21. Тәмәке төпчеге савыты (фарфор һәм капкачлы).

22. Бер алта-атар[6].

23. Кыны белән тимер тарак[7].

24. Арбасына утырганда аягына киертеб куя торган капчык. (Арбасының тәгәрмәч шинларын өрдереб тутыра торган насос һәм арбаның бүтән әсбаблары)[8].

25. Картина (кызлар)[9].

26. Портмане һәм бумажнигы.

27. Урындыкка утырганда астына куеб утыра торган резин бөят.

28. Рамлы кечерәк (квадрат) бер картина[10].

29. Рәсемләр: «Тигезсезләр» сәхнәсендән өч данә рәсем. Чита мәктәбе, Ачинский мәктәбе, Аитова мәктәбе шәкердләре рәсемләре. Вакыт – Шура һәйәт тәхририясе рәсеме. Татар-башкорд җөмһүрияте харитасы[11].

30. Кечкенә сандыкда: бер комплект юл әсбаблары, кыны белән чәч алу машинасы, бер бритва, күн савытта бөтен әсбаблары белән куркынычсыз бритва, кайрагыч, ун төргәк (альбом) открыткалар, өч альбом: Берлин, ... Рума манзаралары[12].

31. Зур кара портфель эчендә төрле документлар һәм ата-анасының биографиясенә гаид материаллар[5]13

32. Гарәбстан күренешләрендән бер альбом[14].

---

[1] Кала.

[2] Фатихка килгән рәсемләр белән бер альбом Фатихның сандыгында кала. Калганлары Ибраһимгә кала.

[3] Кала.

[4] Кала.

[5] Сандыгында кала.

[6] Ибраһимныкы.

[7] Кала.

[8] Кала.

[9] Кала.

[10] Кала.

[11] Сандыгында кала.

[12] Ибраһимга кала.

[13] Сандыгында кала.

[14] Ибраһимга кала.

33. Бер бөктәр буш конвертлар. Бу конвертларның хатлары чыгарылган иде[1].

34. Кәгазь кисә торган сөяк пычак, губка (кызыл), тамчылык.

35. Шкатулка эчендә: эчендәге кәгазьләре белән бер бумажник, куркынычсыз бритва, Роза исеме язылган бер көмеш партсигар, партсигар эчендә Галимҗан Ибраһимовның бер хаты, махорка кисәге, алтын кул сәгате, ручка, запонкалар.

36. Фил сөягеннән таяк. (Ибраһимныкы).

37. Китаблар: Хөсәен хәзрәтнең Әл-баб әл-әхбар... китабының тәрҗемәсе, янә алты төрле китаблар[2].

38. Бер кулъязма (вакаигънамә). Алты данә Фатих әсәрләре һәм үз әсәрләре булган мәҗмугалар[3].

39. Төрле вак картиналар (өч данә). Сөенбикә рәсеме.

40. Зур сандыкта: бер төргәк биографиясе өчен кирәкле материаллар һәм 28 данә (егерме сигез) данә рәсемләре, бер төргәк янә рәсемләр һәм хатирә дәфтәре, бер төргәк кулъязмалар, бер төргәк хатлар (141 хат), бер төргәк кеше кулъязмалары, бер төргәк һәртөрле документлар, фотография карточкалары, төрле кирәкле-кирәксез язулар, бер төргәк Зариф хәзрәткә язылган һәм бүтән әйберләр, бер төргәк китаблар (20 нче номерда әйтелгәнләр), бер төргәк буш конвертлар.

Бу саналган әйберләрнең күбесе зур сандыкда булыб, бер кадәресе камод ящикларында, бер кадәресе дә шкаф ящигында.

Бу гакыднамәдә саналган кулъязмалар, материаллар, кием-тукымалар һәм бүтән һәртөрле җиһазлар Фатихнең шәхесенә, аның тәрҗемәи хәле һәм исемен мәнгеләштерүгә бәйләнешле булыб, тарихи әһәмиятле нәрсәләр булганлыкларыннан, ул әйберләрнең һич беркем тарафыннан, шулай ук варислары һәм якыннары тарафыннан да васыйлардан башка мәрхүмнең фатирыннан чыгарылмаулары һәм бөтен килеш саклanулары тиеш. Бу әйберләр һәммәсе вакытлыча мәрхүмнең якынларыннан Разия Әмирханова карамагына табшырылдылар.

Ибраһим Биккул,
Галимҗан Шәрәф
24 июль, 1926 сәнә.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Гомәров Илһам Госман улы**,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире*

[1] Сандыгында кала.
[2] Сандыгында кала.
[3] Сандыгында кала.

УДК 821.512.145

***Ә.М. Шәрипов***

# ГОРУР БАШЫМ ТҮБӘН ИЕЛМӘС...
## *(шагыйрь Сириннең тормыш һәм иҗат юлы)*

В статье освещается жизнь и творчество поэта Сирина (Батыршин Сайрин Ханифович, 1896–1969), внесшего весомый вклад в развитие татарской поэзии. В частности, рассматриваются вопросы тематического диапозона и поэтики его произведений.

**Ключевые слова:** Сирин, татарская литература, творчество, лирика, тематика, поэтика.

Сирин – Батыршин Сәйрин Хәниф улының (1896–1969) псевдонимы. Үзенең беренче шигырьләреннән үк ул шушы псевдоним белән иҗат иткән һәм әдәбият тарихына да Сирин исеме белән кереп калган.

Бүгенге укучы Сирин иҗатын бөтенләй белми диярлек. Чөнки Сирин 1935 елда репрессияләнә, «халык дошманы» дип игълан ителеп, сөргенгә җибәрелә; шуннан соң аның әсәрләрен генә түгел, хәтта исемен дә телгә алу тыела. 1957 елда реабилитацияләнгәч кенә, Татарстан китап нәшриятында аның «Шигырьләр» (1959) китабы басылып чыга.

Сирин Батыршин 1896 елның 14 декабрендә Татарстанның Ютазы районы Кәрәкәшле авылында туа. Башлангыч белемне туган авылында алгач, 1910–1915 елларда атаклы Бәйрәкә мәдрәсәсендә укый. Инкыйлаптан соң, 1918 елда Бөгелмәдәге өчьеллык укытучылар әзерләү курсларына укырга керә. Монда ул җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Аның гражданнар сугышы вакыйгаларында катнашуы турында Мәгъсүм Латыйфуллин болай дип яза: «1920 елның январь – март айларында акгвардияче Колчак бандасы калдыклары коткысы белән Чистай, Минзәлә, Бөгелмә өязләрендә кулаклар баш күтәрделәр. Халык теленә „Сәнәкчеләр“ дип кергән бу фетнәчеләр яшь совет республикасы өчен куркыныч тудыралар иде. Партия һәм комсомол өяз комитетлары аларны бастыру өчен ашыгыч чаралар күрергә мәҗбүр булды. Комсомол отрядлары төзеп, фетнәчеләрне бастыру өчен Акташ ягына җибәрделәр. Шундый ук отряд Коммунистик яшьләр союзы өяз комитеты каршында да төзелә. Бу отряд күбесенчә Бөгелмә татар тәгълим-тәрбия курсларында укучы комсомоллардан тора иде. Комсомолларның Кожух җитәкчелегендәге корыч сафларында кулына мылтык тоткан Сирин дә бар.

Алдан киткән комсомол отрядларына ярдәмгә Кожух командасы кузгала. Кирәкле корал, патрон алып, атларга төяләләр һәм буранлы төндә кар ерып баралар. Кодаш авылына җиткәч,

аларны фетнәчеләр урый. Атыш китә. Кожух утырган ат урам буйлап чапканда, фетнәчеләр чанага ябышып өстерәлеп барган кешене күрәләр һәм: „Балта белән! Чалгы белән! Кулына чап!“ – дип куалар. Бу Сирин була. Кожух аны күтәреп чанага сала, фетнәчеләр кулына бирми» (*М. Латыйфуллинның бу истәлеге Сирин архивында саклана*).

Шулай итеп, 24 яшьлек Сирин «сәнәкчеләргә» каршы хәрәкәттә дә катнашкан. Шул ук вакытта ул, көче-куәте ташып торган яшь егет, кулына каләм алып, шигырьләр яза башлый: әдәбиятка да ул Бөгелмәдә язган әсәрләре, яшьлек ялкыны, көчле инкыйлаби пафос белән өретелгән шигырьләрен алып керә. Башка шагыйрьләр кебек үк, ул да иң элек Октябрь инкыйлабын шатланып каршы ала, социализм идеяләренең җиңәчәгенә, золым-газаплар белән тулы тормышның яхшыруына өметләнә. Бу яктан Сирин Г. Камалга охшаш: Г. Камал инкыйлабны таң ату белән чагыштырган булса («Таң» шигыре, 1918), Сирин исә аны кояш чыгуга тиңли. «Октябрь нурлары» (1920) шигырендә Сирин совет хакимиятен ярлы кешеләрне ашатучы-эчертүче, киендерүче, аңа чын хокук бирүче итеп сурәтли. Үзенең шатлыгын ул:

Укытты да, өйрәтте дә,
Атам кебек бу кояш!
Еласам, күз яшем сөртте,
Анам кебек бу кояш! –

дип тасвирлый. Яңа җәмгыятьтә гаделлек кенә тантана итәр дип ышана.

1919–1920 елларда Сирин гражданнар сугышы темасына багышланган шигырьләрен бер-бер артлы төрле газеталарда бастыра. Мәсәлән, «Кызылармеец хаты» әсәрендә (бу шигырь 1919 елда Самараның «Яңа көч» газетасында «Әнкәмә хат» исеме белән басылган) ул, әнисенә мөрәҗәгать итеп, үзенең балачактан алып, бары «тормышның бар михнәтен, ачлык, хәсрәт, сугыш җәфасын» гына күреп үскәнлеген һәм шул «богауларны өзеп» яшәр өчен хәзер сугышып йөрүен әйтә. «Октябрь кояшы» («Якты юл» газетасы (Бөгелмә), 1920 ел, 7 ноябрь, № 35), «Сәлам сезгә, кызыл бөркетләр» («Якты юл» газетасы, 1920 ел, 16 ноябрь, № 37), «Булмаса» («Якты юл» газетасы, 1920 ел, 28 ноябрь, № 41) шигырьләрендә шул чорның кайнар сулышы чагыла. «Кызыл гаскәргә» (1922), «Сикерт атың! (Кавалерия маршы)» (1925), «Атлы шлемнар» (1927), «Кызылармеец атлар» (1928) әсәрләре дә киләчәк тормышка тирән ышаныч, революцион пафос белән сугарылган.

1921 елгы коточкыч ачлыкны да үз башыннан кичерергә туры килә Сирингә. Ачлык башлангач, 1921 елның көзендә Бөгелмә семинариясендәге укулар туктатыла. Бу ачлык турында Сирин истәлек тә (бу турыда кара: «Казан утлары», 2016, № 12. 159–160 битләр), шигырьләр дә яза. Мәсәлән, «Ачлар тавышы» шигырендә ачлыкның үзәк өзгеч картинасын тасвирлый:

Ярлы илгә ярлылар баш; алтын,
көмеш җирдә таш,

Төрле чүп-чар, алабута безнең илдә
булды аш.
Юк әле, түзми күңел, җан тартыша,
сызыла йөрәк,
Бер телем икмәк сорап тетри
бәгырь, өзелә йөрәк
(«Кызыл яшьләр» газетасы,
1921 ел, 3 ноябрь, № 24).

1922 елда халыкның бөтен өмете кырга чәчелгән игеннәрдә була. Бу тема поэзиядә дә чагылыш таба. Нур Баян («Кырлар симфониясе», «Клеверлы кырлар», «Яңгырлы төн»), Сәйфи Кудаш (Сәйфи Кудаш 1930 елга кадәр татар телендә иҗат иткән) «Иген сукканда», «Ленин десятинәләре», «Утауда», «Сабан җырлары») белән беррәттән Сирин дә бу темага «Яз – игенчегә» (1922), «Сарутлык җир» (икенче вариант, 1924) кебек әсәрләрен яза. «Яз – игенчегә» шигырендә ул авыл кешесен тизрәк кырга эшкә чыгарга чакыра: «Ашык тиздән – үлем биргән бу ачлык китсен бездән», – ди. «Сарутлык җир» шигыренең икенче вариантында ул җир эшкәртүне фәнни нигезгә куюны, марксизмны да файдалану кирәклеген алга сөрә.

Башлангыч иҗатында ук Сирин, Тукайдан үрнәк алып, Шәрыкның классик шигырь жанрларын үзләштерә һәм шул жанр-формалар белән (газәл, касыйдә, мәснәви) иҗат итә башлый (мәсәлән, «Октябрь кояшы» (1920 ел, 7 ноябрь) шигыре үк мәснәви формасында язылган, әмма «Якты юл» газетасында ул дүртюллыклар белән бирелгән). Сириннең 1920–1930 еллардагы әсәрләре белән Тукай әсәрләре арасында типологик параллельләр үткәрергә мөмкин. Шунысы кызык: хәтта Тукайның «Эштән чыгарылган татар кызына» (1909) белән Сириннең «Авыл кызына» (1920) («Кызыл Шәрыкъ» газетасы (Томск), 1920 ел, 6 август, № 40) әсәре арасында да охшашлыклар бар: ике әсәр дә яшь татар кызының елавына багышланган; икесендә дә «мәэюс», «залим», «күңел» кебек сүзләр кулланыла. Әмма Тукайда «залим» булып татар бае саналса, Сириндә «залим» дип иске тормыш күз алдында тотыла. Тукайда татар кызының чарасызлыгы сурәтләнә, ә Сирин исә гражданнар сугышына киткән егетен сагынып күз яшьләрен түгүче кызны: «Күп тә үтмәс, менә кайтып җитәр / Җан сөеклең көләч йөз белән», «Менә, киләчәгең нинди матур / Рәхәтләнеп гомер итәрсең», – дип юата.

Тукайның «Даһигә» (1913) әсәре белән Сириннең «Диңгезгә» (1920) («Якты юл» газетасы, 1920 ел, 25 ноябрь, № 40) шигыре арасында да шактый гына уртаклыклар (охшаш рифмалар, мотивлар) бар: алар икесе дә мәснәви формасында язылган. Тукай үз әсәрендә милли-азатлык хәрәкәте турында уйлана һәм газиз халкын колониаль изүдән коткару, аны иҗтимагый-мәдәни яңарышка алып чыгу юлларын эзләгән Даһи образын иҗат итә. Сириннең «Диңгезгә» әсәре үзәгенә авторның үзенең буйсынмас, көчле, ашкын, бунтарь образы калкып чыга. Диңгезгә эндәшеп, шагыйрь болай ди:

Ниндәй дулкыннарга атсаң да,
барыбер батмамын!
Һәм үлеп, суың төбендә дә череп
ятмамын!

Миндә көч, гайрәт вә дәрт бар,
күкрәгемдә ут яна,
Мин күрәмен алда – анда
ялтыраган ут әнә!
Ул шулай күзгә күренә, ут түгел,
юк, нур бит ул!
Пакь вә саф, ап-ак күңелле бер
фәрештә, нур бит ул!
Тарта яшь, дәртле күңелне үз янына
алга ул,
Киң колачлап мин йөзәм шунда,
минемчөн Алла ул!

Тукайның «Булмаса» газәле (1908) белән Сириннең «Булмаса» шигыре (1920) икесе дә 15–15 үлчәме белән иҗат ителгән (Сириннең «Булмаса»сы касыйдә белән мәснәви формаларын файдаланып язылган). Әмма Тукай биредә шагыйрь күңелен дәртләндереп торучы былбылга (гүзәл зат, гүзәллек шаһына) мәдхия җырласа, Сирин үзен коммунист дип санаган кешенең ярлы халык мәнфәгатен кайгыртып хезмәт итәргә тиешлеген күтәрә: «Булмаса күңелдә халыкка мәхәббәт хисләре / Булма коммунист, якын килмә бүтән уйлар белән», – дип белдерә.

Тукайның үлеменә ун ел тулу уңае белән Сирин «Безнең яшьләр» дигән шигырен иҗат итә. Бу әсәрне ул, Тукай кебек үк, касыйдә жанрында язган. Монда да Тукай белән Сирин шигырьләренең идея юнәлеше төрлечә: Тукай шигыре 1905 елгы инкыйлаптан соңгы кара реакция елларында язылган һәм Тукайның төшенкелек, киләчәккә өметсезлек мотивлары белән сугарылган булса, Сирин шигыре инде, киресенчә, революцион романтика, авторның яңа тормышка ныклы ышанычы белән өретелгән (бу турыда кара: [Шәрипов, 2016, б. 57–62]).

1923 елның көзендә Сирин Казанда Татар рабфагына укырга керә. Иҗади яшьләр белән таныша (Афзал Шамовның кызы Әлфия Шамова хәбәр иткәнчә, Сирин рабфакта Муса Җәлил белән бергә, бер төркемдә укыган), әдәби иҗатка җитдирәк карый башлый. Биредә уку чорында (1923–1925) Сириннең иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-эстетик карашлары билгеле бер дәрәҗәдә эволюция кичерә.

Шул чор идеологиясе шаукымына бирелеп, Сирин иҗатында атеизм темасы да күтәрелә. «Еласыннар... Мин еламыйм!» (1923) шигырендә ул кискен рәвештә үзенең дини ышануларга каршы булуын белдерә: «Яуса да таш алларымда, һич исем китми аңар / «Раббем, Аллам!..» дип еламыйм, «Ярдәмең бир!» дип аңар», – ди. Дин әһелләрен тәнкыйтьләү темасы соңга таба аның «Бер шәехнең идеалистик логикасы» (1925), «Тынычлык кошлары» (1926), «Шөһрәт» (1929) әсәрләрендә чагылыш таба; «Кикрикүк!» (1929) шигырендә багучылык күренеше тәнкыйть утына тотыла.

1926 елда рабфакны тәмамлагач, Сирин бер ел Бөгелмәдә «Сабанчы» газетасында эшләп ала. Әмма аның күңеле Казанга тартыла, һәм ул 1927 елның көзендә тагын Казанга килеп, Көнчыгыш дәүләт педагогия институтына укырга керә. Монда ул үзе теләгән иҗади атмосферага эләгә: Һ. Такташ, Г. Кутуй, Х. Туфан, Ә. Исхак һ.б.лар белән таныша, бөтен барлыгы белән

белем алуга, иҗат эшенә бирелә. Студент елларын (1926–1930) Сириннең тормышында да, иҗатында да яңа бер этап итеп карарга, аның тормышта да, поэзиядә дә үз-үзен эзләве, эзләнү чоры дип атарга кирәк.

Студент буларак, Сирин бик тырышып укый. Үзенең истәлекләрендә ул: «Мин, утырган тавык кебек, һәр кичне дәресләр өстендә утырам. Атнага бер мәртәбә әдәбият түгәрәге була, анда катнашам. Анда Такташ, Кутуй, Нур Баян, Демьян Фәтхи һәрвакыт булалар иде...Язарга бер дә вакыт булмаса да, ара-тирә мин дә язгалап куя идем», – дип искә ала (кара: «Казан утлары». 2016. № 12. Б. 150).

Билгеле булганча, 1920 елларда Казанда иҗади яшьләрнең төрле әдәби күмәк һәм оешмалары барлыкка килә. «Егерменче елларның беренче яртысында әдәби түгәрәкләр активлашып китә... Болар арасында бигрәк тә «Октябрь» күмәгенең роле зур булды... «Октябрь» күмәге татар совет язучыларын бер оешмага туплауда шактый эш башкара... 1924 елда «Октябрь» күмәге членнарының бер өлеше Г. Кутуй һәм Г. Толымбай җитәкчелегендә «Сулф» («Сул фронт») исемле яңа күмәк төзиләр һәм «Октябрь»дән аерылып чыгалар» [Татар әдәбияты…, б. 95–96].

Сирин дә «Сулф» күмәгенә керә. Шагыйрь Әхмәт Исхак үзенең истәлегендә [Әхмәт Исхак…] Сирин белән үзенең 1923 елда ук танышканлыгын әйтә. «Торабара дуслашып киттек, – дип яза ул. – Бер-беребезгә шигырьләребезне укыштык. Киңәшләштек, бәхәсләштек, театр-киноларга бергә йөрдек. Ул вакытларда иҗат яшьләре арасында киң таралган яңалык эзләү җилләренә бирелеп, „футуризм“ дигән чирне йоктырып, „Сулф“ („Сул фронт“) дигән төркемгә иярдек».

Бу елларда барлык татар шагыйрьләре, шул исәптән Сирин аралашып яшәгән Һ. Такташ, Х. Туфан, Г. Кутуй, К. Нәҗми һ.б.лар да поэзиядә үз урыннарын табарга омтылып, төрле экспериментлар үткәрәләр. Мәсәлән, Һ. Такташ «Тилеләр», «Янар таулар», Г. Кутуй «Көн – кадак», «Карт пычкычы», К. Нәҗминең «Еллар гына юып бетермәс», «Кабыргасы белән тора» һ.б. әсәрләр иҗат итәләр. 1926–1928 елларда Сирин дә шигырьләренең формасы белән мавыгып ала. «Беренче май» (1926), «Көнлиләр» (1927), «Безнең кайгылар» (1928) шигырьләрендә ул катлаулы образлар, сүзләрнең охшаш яңгырашы белән мавыгып, аларны тезеп төшә һәм әсәрнең эчтәлеген күздән ычкындыра. Аның бу әсәрләре матбугатта шул ук елларда тәнкыйть ителделәр. Ярый әле шагыйрьнең мондый мавыгулары озакка бармый. «Октябрь» һәм «Сулф» күмәкләре озын гомерле булмаган кебек, бер-ике елдан Сирин дә үзенең бу экспериментларыннан арына. Ләкин Маяковскийга ияреүен ташламый, аның кебек трибун шагыйрь булырга омтылган иҗатын дәвам иттерә.

Шулай иҗат итеп килгәндә, кинәт көтелмәгән бер хәл була – Сиринне (студент чагы, шагыйрьнең истәлекләрендә елы әйтелмәсә дә, 1927 ел булып

аңлашыла) кулга алалар. Бу вакыйганы ул үзенең истәлекләрендә болай сурәтли: «Кичке ут алынган иде, ишектән дүрт кеше килеп керде. «Батыршин арестован» диделәр дә, мине милиция янына куйдылар. Хуҗа хатыны, күрше хатыннарыннан комиссия төзеп, өстәлдә булган китапларны, кәгазьләрне җыеп алып бәйләделәр. Әйберемне һәм үземне «Кара карга» дигән машинага утыртып алып киттеләр... Машинадан төшкәч аңладым: мине Черек күл каршындагы Эчке эшләр Халык Комиссариаты (НКВД) төрмәсенә китереп япканнар икән».

Аны ялгыз камерага кертеп ябалар, янына бер шымчы куялар. Камерада икәү генә булгач, әлеге шымчы Сирингә милли мәсьәлә буенча сораулар бирә, аны сыный. 3–4 көннән соң, ул шымчыны алып, Сиринне ялгызын калдыралар. «Кулга алынуга 30 көн тула дигәндә, – дип дәвам итә Сирин, – начальник мине чакырып алып: „Казаннан башка беркая барырга да рөхсәт ителми»“, – дип, шул кәгазьгә миннән кул куйдырды һәм теге китап-кәгазьләрне биреп, кайтырга кушты. „Без чакырсак, килерсең“, – диде» («Казан утлары». 2016. № 12. Б. 151).

Шуннан соң Сириннең күңеленә курку кереп оялый. Аны һәр минут «Мине тагын кайчан чакырырлар икән? Исән калырмынмы икән?» дигән сорау борчып тора башлый. Әмма Сирин әле бу шартларда да ихлас күңелдән партия яклы булып кала. Бунтарь йөрәгендә кайнаган хис-тойгыларны тезгенләп, совет идеологиясе таләпләренә җавап бирә торган әсәрләр иҗат итә. Ул иҗади эзләнә, милли чикләнгәнлек кысаларында гына калырга теләми, рус һәм дөнья поэзиясен өйрәнә. Аның иҗатының тематикасы киңәя, каләме чарлана, шагыйрьнең үз-үзенә ышанычы арта. Аның Маяковскийга ияреп язган «Идәнгә төкермәгез!» (1928), «Кытай җыры (Кытай шагыйре Ши-Кингтан)» (1928), «Гейне фикере» (1929) кебек әсәрләре Сириннең үз өстендә җитди эшләгәнлеген күрсәтеп тора.

1928 елда Сиринне яңа гына оешкан Татар пролетар язучылар ассоциясенә (ТАПП) әгъза итеп алалар. Нәкъ менә студент еллары һәм шуннан соңгы биш-алты ел (1928–1935) – Сириннең иң актив иҗат иткән, көчле трибун шагыйрь булып танылган чоры.

Аның бу чордагы эзләнүләре башлыча поэзиядә үз язу стилен, үз шигъри формасын эзләүдә, эчтәлек белән форманың берлегенә ирешергә тырышуда күренә. Ул Маяковский үрнәгенчә иҗатын дәвам итә. Әсәрләрнең сәнгатьлелегенә ирешүдә ул һәр сүзне аерып алып, аның тирән мәгънәсен ачу, аларны бер-бер артлы юлдан-юлга тезеп бару алымын куллана. Бу исә шигырьнең эчке ритмын нечкә тоемлап, ачык яңгырашлы рифмалар сайлап язуны таләп итә. Иҗатының башыннан ук Сирин шушы юнәлештә тәҗрибәләр ясый башлый: «Салкын энәләр» (1922), «Тегүче кыз» (1925) әсәрләре шушы алым белән язылган. «Тегүче кыз»да, мәсәлән, машинада кием теккән вакытта чык-

кан тавышларны бирергә омтыла: *«Сөеклем бул, машинам, тек. Әйдә тек, тек! / Таралган вак кисәкләрне бергә беркет! / Тигезләрмен, килмәгәнен үтүкләрмен / Кулымда бар кыздырылган кайнар үтүк»*, – ди.

1927 елда шушы алым белән Сирин иң атаклы әсәрләренең берсен – «Язгы тамчылар» шигырен яза. Бу әсәрдә ул, бер яктан, охшаш яңгырашлы сүзләрне сайлап, тамчылар тавышын чагылдырырга омтылса, икенче яктан, әсәрнең эчтәлегенә дә тирән мәгънә сала:

Там,
Там,
Тамчы, там,
Тамуыңны яратам.
Тамчы-тамчы
Җырларыңны
Ак кәгазьгә таратам.

Ул язгы тамчыларның поэтик матурлыгын җырлап кына калмый, ә бу күренешне җәмгыять тормышы белән дә бәйли, шуның белән әсәрнең иҗтимагый ролен көчәйтүгә ирешә. «Там, там, тамчы там!» сүзләрен ул рефрен итеп куллана һәм алар һәр кулланган саен әсәрнең иҗтимагый мәгънәсен көчәйтә, тирәнәйтә баралар, идеясен ачарга ярдәм итәләр.

Там,
Там,
Тамчы, там,
Бергә тамыйк ичмасам!
Мин дә тамчыланып тамыйм,
Көрәшләрдә аксын кан!

Басылып чыгу белән (1927) бу әсәр бик тиз халык арасына таралган һәм халык, аны яратып, аңа көй дә язган. Шул көй безнең көннәргә кадәр килеп җиткән – ул көй әле бүген дә балалар бакчаларында музыка дәресләрендә нәниләрне биеткәндә уйнала.

Әлеге язу алымын Сирин күпчелек шигырьләрендә куллана. Шушы ук алым белән ул үзенең икенче бер күренекле, программ әсәрен – «Йөрәк каны белән» шигырен (кайбер кулъязмаларда бу шигырь «Минем трагедиям» исеме белән йөри) (1929) иҗат итә. Бу – фәлсәфи әсәр. Монда Сирин – шагыйрь-новатор: совет чоры татар шагыйрьләреннән беренче буларак, ул җәмгыять һәм шагыйрь, шагыйрьнең җәмгыятьтәге урыны, роле, яңа җәмгыятьтә шагыйрьлек миссиясе проблемаларын күтәреп чыга. Үзенең поэтик иҗатын Сирин болай сурәтли:

Бу – минем
          уйларым,
                    бу – ритм.
Бу – минем
          йөрәгем тибүе.
Бу – минем
          канымның
                    тәнемнән
Җыр булып
          кәгазьгә
                    күчүе.

Төзелеп кенә килә торган яңа җәмгыятьтә (ә Сирин бөтен күңеле белән киләчәктә якты, гадел, җәбер-золымсыз җәмгыять төзибез дип ышана) шагыйрьнең миссиясен ачыграк күзаллау өчен, ул үз-үзенә шундый сорау да бирә: *«Ни өчен, ни өчен мин болай / Ак кәгазь өстендә кан коям?/ Каләмнән тамдырып канымны / Үземне вакытсыз ник суям?»* Шушы сорауга ялгап, ул шагыйрьнең тормыштагы

вазифасының авторның шәхси мәнфәгате, эгоистлыгы, дан-шөһрәткә омтылуы белән бәйле түгеллеген әйтә: *«Шөһрәт кирәкме? – Кирәкми! / Мин үлгәч, шөһрәт нәрсәгә?»* – ди. Үзенең алда куйган соравына Сирин үзе үк *«Киләчәк тормышны күрәсе һәм шунда яшисе килә»*, – дип җавап бирә. Ә киләчәк тормышны автор матур итеп күзаллый: *«Киләчәк елларның тормышы / Уемда бик матур корылган./ Шул елларның нигез ташына / Безнең еллар өеп куелган».* Әмма ул матур киләчәкне кул кушырып утырып кына, яки елмаеп, эшләр-эшләмәс йөреп кенә якынайтып булмый. Шагыйрь кәеф-сафа корып, бизәнеп, үз-үзенә сокланып кына, эшсез утыруга каршы чыга: *«Ни булыр иде соң / Мин, Сирин, / Гөлсирин булып, гел бизәнсәм? / Яз саен яшәреп, / Таң саен зәп-зәңгәр чәчкәдә утырсам?»* – ди ул. Һәм автор якты киләчәкне тизрәк җиткерү өчен үзенең шигърияте, ялкынлы сүзе белән көрәшәчәген, хәтта шушы юлда үзен корбан итәргә дә әзер торуын белдерә:

Юк,
каным жәл түгел,
коелсын чәчкәм дә,
Каләмнән тамдырып
канымны,
кәгазьгә чәчәм дә,
Җыр итеп
тезәм мин.
Беләм мин:
корбансыз
җиңү юк,
Авырлык күрмичә,
рәхәтләр күрү юк.

Күренә ки, Сирин шагыйрьнең тормыштагы миссиясен поэтик югарылыкка күтәреп тасвирлый: үзен шагыйрь дип исәпләгән иҗат кешесенең бары тик янып, үз халкының кайгы-шатлыкларын үз йөрәге аша үткәреп кенә, «йөрәк каны белән» генә язарга тиешлеген белдерә. Шунысы кызык: шагыйрьлек миссиясен аңлауда да Сириннең карашы Тукай карашы белән аваздаш. Тукай да бит шагыйрьнең вазифасын бик югары бәяләде: аны авторның үзенең шәхси мәнфәгате турында кайгыртуында түгел, ә халыкка хезмәт итүендә күрде. «Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә; Бу юлда һәртөрле хурлыкка, зорлыкларга түзмәккә!» дигән чакыру ташлады. Үз чорының вазгыятеннән чыгып, ул шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси ролен «йоклаган» татар халкын уятуда, тергезү-терелтүдә күрде. Ә Тукай, үз чиратында, бу мәсьәләдә рус әдәбияты классиклары А.С. Пушкин белән М.Ю. Лермонтовка таянды, алардан үрнәк алды: «Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам / Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам» (Г. Тукай. Бер татар шагыйренең сүзләре). Монда шундый типологик параллельлек тә үткәреп була: 1826 елда Пушкин, 1841 елда Лермонтов «Пәйгамбәр» («Пророк») дигән әсәр язалар һәм шагыйрьнең җәмгыятьтәге миссиясен пәйгамбәрлек миссиясе дәрәҗәсенә күтәреп тасвирлыйлар. Тукай да «Пәйгамбәр (Лермонтовтан үзгәртелгән)» (1909) шигырендә шагыйрьнең миссиясен пәйгамбәр миссиясе югарылыгында күрә һәм Сирин әсәрендәге фикергә охшаш фикер әйтә: шагыйрь үз

мәнфәгате өчен түгел, ә халкы өчен армый-талмый хезмәт итәргә тиеш: «Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә / Ашамый-эчми көндез, кич белән баш куймый мендәргә»; шагыйрь рухи ут белән янарга тиеш: «Янып рухани ут берлә, ашыккан хәлдә юл тотсам», – ди [Аминева, с. 24–49]. Тукайның бу фикерләре үзенең остазлары – Пушкин һәм Лермонтов фикерләре белән аваздаш [Пехтелев, с. 106]. Шулай итеп, Сириннең фикерләре Тукай фикере белән дә, Пушкин һәм Лермонтов фикерләре белән дә аваздаш булып чыга: «Пушкин – Лермонтов – Тукай – Сирин» дигән чылбыр барлыкка килә һәм Сирин бу чылбырда ахыргы бер буын ролен үти. Гомумән, «Йөрәк каны белән» әсәре 1920–1930 елларда гына түгел, ә бөтен XX гасыр татар поэзиясендә гражданлык лирикасының иң матур үрнәкләренең берсе булып санала.

Ритмик һәм аһәңлелек җәһәтеннән нәфис эшләнгән «Киләләр» (1930) шигыре дә оптимистик рухта язылган. Монда автор тормышта үзенең нинди теләк-омтылышлары булса, шуларның барысын да «килә» дип санап чыга да, киләчәкнең чыннан да матур буласына ышанып, *«киләсе көннәрнең көлгәнен күрәсе килә»* дигән теләк белдерә. Игътибар итик: бу шигырьләр шулкадәр ихлас күңелдән язылганнар ки, алардан, әйтерсең, укучыларга бары уңай энергия генә бөркелә.

Шулай итеп, 1930 еллар татар поэзиясендә башка беркемнекенә дә охшамаган «Сирин стиле» дигән күренеш барлыкка килә. Бу Такташ стиле дә, Хәсән Туфан стиле дә түгел. «Сирин стиле», бер яктан, хыялның көчле булуы, тирән эмоция, лиризм һәм революцион романтика белән сугарылган булса, икенче яктан, яңгыравыклы ритмы, халыкның гади, йөгерек, матур, музыкаль телен файдалануы белән үзенчәлекле. Сирин музыкаль яңгырашлы сүзләр белән төрле күренеш, халәт-хәрәкәтләрне күз алдына китереп бастыра. Шулай итеп, шигырьгә музыкальлек килеп керә, аңарда төрле тавышлар яңгыраган төсле, тәэсирле итеп бирелә, шул ук вакытта автор шигырьнең эчтәлегенә дә тирән мәгънә сала белә: һәр әсәренең киң иҗтимагый яңгырашы турында да кайгырта. Поэтик идея белән публицистик фикерләүнең синтезына ирешергә омтыла.

Татар шагыйрьләреннән аеруча Такташны якын күрә Сирин. Алар икесе дә бунтарь җанлы. Бер-берсе белән якын дус булганнар, ярыша-ярыша иҗат иткәннәр. Ул елларда Казанның иң зур залларында уздырыла торган әдәби кичәләрдә икесе дә яңгыратып шигырь укыганнар, яшьләрнең, студент кызларның иң яраткан шагыйрьләренә әверелгәннәр. Рифгать Батыршин (Рифгать Батыршин – Сириннең энесе Мәхәсимнең улы) үзенең истәлекләрендә Казан авыл хуҗалыгы институтында немец теле укытучысы, өлкән яшьтәге Алмаева Фатыйманың Сирин турында әйткән сүзләрен китерә: «Без, студент кызлар, Сирин, Такташ, Кутуй нинди клубларда чыгыш ясыйлар, шунда чаба

торган идек. Шигырьне бигрәк шәп сөйлиләр иде», – дигән ул. Ә Ямаш Игәнәй исә Сирин турында: «Заманында сәхнәләрдә Һади Такташ белән ялкынлы шигырьләрен укып йөргән шагыйрь бит ул. Татар шигърияттендә яңалык ачучы», – дип яза һәм Сириннең үз сүзләрен китерә: «Сәхнәнең бер ягыннан Такташ, икенче ягыннан мин килеп чыга идем. Укып җибәрәбез шигырьне, зал ни эшләргә белми, сихерләнә, илаһи шаукымга тоташ уралып, тылсымлы-серле халәтнең иң югары ноктасында бөтерелә», – дип сөйләгән иде ул бер очрашу вакытында» [Игәтәй Ямашев, б. 96].

Әйтергә кирәк, мондый дуслык аларның иҗатларында да чагылыш таба. Такташ белән Сирин әсәрләре арасында байтак кына охшашлык-аваздашлык бар. Бер үк темага яки бер үк мотивка алар икесе ике төрле әсәрләр язганнар (язучы Р. Мостафин Сиринне Такташның көндәше дип атый: «Мәдәни җомга», 1996. 3 май). Менә аларның кайберләре: Октябрьнең ун еллыгына Такташ үзенең «Үпкәлим», ә Сирин «Урам уртасында» шигырен багышлый; кызыл кавалеристларга багышлап Такташ «Атлы сугышчыга», ә Сирин «Атлы шлемнар» әсәрен яза. Кызларның кыска күлмәк киеп йөрүләренә Такташ «Җырым сиңа булсын» (1927), ә Сирин «Бала итәкле озын күлмәкләр» (1933) шигырен, кар яву күренешеннән этәрелеп китеп Такташ «Ак чәчәкләр» (1929), ә Сирин «Кышкы чәчәкләр» (1933), халыкара күләмдә тыныч тормыш турында Такташ «Лорд Чемберленга СССР крестьяны Һади Такташтан җавап нотасы» шигырен (1927), ә Сирин «Халыкара сугышка каршы Конгресста Сириннең сөйләгән беренче речe» поэмасын (1933) иҗат итәләр.

1929 елда педагогия институтын тәмамлагач, Сирин бер ел Казанның М.Вахитов исемендәге мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта; бер үк вакытта, Татар пролетар язучылар ассоциясе тарафыннан билгеләнеп, Казан тегү фабрикасында яшь каләм тибрәтүчеләрнең әдәби түгәрәгенә җитәкчелек итә. 1930 елда аны Татиздатның авыл хуҗалыгы бүлегенә редактор итеп эшкә чакыралар. Анда ул 1935 елның августына, ягъни кулга алынганга кадәр эшли.

1930–1935 елларда Сирин иҗаты киң колач ала, үзенең иң югары ноктасына җитә. Ул татар халкының иң үзенчәлекле, иң популяр шагыйрьләренең берсенә әверелә. Бу елларда ул заманының актуаль мәсьәләләрен күтәргән иң камил, иң атаклы әсәрләрен иҗат итә. Мәсәлән, зур күләмле «Булмый! Булмый!» шигыре (1930) шул чорның көнүзәк мәсьәләсе – авыл хуҗалыгын коллективлаштыру темасына багышланган. Күмәк тормышның никадәр өстен, никадәр файдалы икәнлеге турындагы фикерне шагыйрь әле күмәк хуҗалыкка кермәгән кеше аңына барып җитә алырлык гади сүз-алымнар белән бирә. Бу – авторның гади крестьян белән шигъри телдә сөйләшүе булып чыккан. «Ашлыгыңны җилгәрәмсең, җилгәр, җилгәр» сүзләрен Сирин реф-

рен итеп куллана һәм алар һәр кулланган саен әсәрнең иҗтимагый мәгънәсен тирәнәйтә баралар. Әсәрдә ялгыз хуҗалыкның төп коралы булган сукага күмәк тормыштагы машина каршы куела. Шулай итеп, Сирин күмәк хуҗалыкны мактый, пропагандалый. Бу әсәр ул елларда бик популяр була, аны күп кенә әдәби кичәләрдә сәхнәдән сөйлиләр.

1930 елда Сирин студентлар тормышына багышлап «Микроскоплы күзләр», «Койрыклы студент» әсәрләрен язган. Аның лирикасы да үзенчәлекле. Яшьлек-мәхәббәт темасына «Ай яктысы», «Каш астыннан», «Эзләрең» (Урал Уралов дигән композитор Сириннең «Эзләрең» шигыренә җыр язган (Урал Уралов. Шагыйрь Сирин турында уйлар // Ватаным Татарстан. 1997. 25 февраль). Әмма әлегә ул җырның ноталары табылмады), «Никтер җаным...», «Үзбәк кызы «Дәрдем бар»га», «Ялгыз каен» һәм башка әсәрләр иҗат иткән. Шагыйрь балалар әдәбиятына да зур өлеш кертә. Балалар өчен «Кыш» (1929), «Көз» (1929), «Яз» (1929), «Җәй» (1929), «Кеше» (1930), «Бә-ә-ә дә мә-ә-ә» (1931), «Корыч атлар» (1931), «Тимер юл» (1931), «Трамвайлар ник туктаган?» (1932), «Җиләк бакчасы» (1933) исемле кечкенә-кечкенә китапларын чыгара, «Күккү» шигырен иҗат итә. 1931 елда «Тамчылар» исемле күләмле генә шигырьләр җыентыгы дөнья күрә (61 бит).

Шагыйрьнең новаторлыгын, үзенә генә хас форма белән иҗат итүен кайбер тәнкыйтьчеләр кабул итеп бетермиләр, аны «формализм»да, футуризмда гаеплиләр; көнләшүчеләр дә табыла. Әдипнең «Тамчылар» җыентыгына язган кереш мәкаләсендә Закир Гали Сиринне пассивлыкта һәм формализмда гаепләп чыга [Сирин, б. I–XI]. «Совет әдәбияты» журналында (1933, № 12) Сириннең «Кышкы чәчәкләр» шигыре басылгач, журналның 1934 ел 1–2 санында аны тәнкыйтьләгән мәкаләләр дөнья күрә: Гомәр Гали аны «Социалистик җәмгыять чынбарлыгының алдынгы идеяләре белән коралланмау»да гаепли, ә Нур Баян исә «Кышкы чәчәкләр» темасының актуаль түгеллеген әйтә («Совет әдәбияты». 1934. № 1–2. Б. 94–95).

Такташның вафатын (1931) Сирин бик авыр кичерә. Якын дустына багышланган «Зәңгәр күзле егет юк инде», «Такташ табуты янында» шигырьләрен ул шул ук көнне, 1931 елның 10 декабрендә язган. Сирин аларда, Такташ үзе вафат булса да, аның иҗатының үлмәячәген, ерак киләчәккә дә барачагына чын күңелдән ышанганлыгын белдерә.

Такташ үлеменнән соң Сирингә тормышта бөтенләй ямь калмаган кебек тоела башлый; беркадәр вакытка хәтта аның иҗаты да туктап калгандай була: актив кына иҗат итеп килгән Сирин, кайбер мәгълүматлар буенча, 1932 елда нибары дүрт әсәр язган. Аның күңеле дә тыныч булмый: куркытулар, сорау алулар дәвам итә. Истәлекләрендә Сирин Татиздатта эшләгән чагында үзен берничә тапкыр Эчке эшләр Халык комиссариатына чакырып сорау алулары турында

яза (кара: «Казан утлары», 2016. № 12. Б. 151–153). Аларның барысы да, әлбәттә, шагыйрьнең иҗатына көчле йогынты ясый, әсәрләрендә дә чагылыш таба.

Сирин җәмгыятьтәге гаделсезлек, аның тамырлары турында уйлана. Еллар дәвамында совет җәмгыятенең патриоты булып та, үзен һаман гаепләүләре, эзәрлекләп торуларының сәбәбен ачыкларга тели. Һәм, әкренләп, моның серенә дә төшенә: тышкы яктан кызыл лозунглар белән төреп-бизәп алынган совет системасының эчендә мәкерлек, алдашу, бер-берсен кыерсыту, байлык-акча өчен көрәш ятканлыгын һәм үзенең шул система эчендә яшәргә мәҗбүр булуын аңлап ала. Шагыйрьнең ирек сөюче, хөр, бунтарь җаны мондый икейөзлелек, мәкерлелек белән килешә алмый, аңа каршы нәфрәт белән тула. Җәмгыятьтәге гаделсезлекләргә каршы ул иҗаты белән көрәш ача: Сириннең 1932–1935 еллар иҗатындагы төп мотивлары, җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне, икейөзлелекне тәнкыйтьләүгә, ачы сатирага юнәлә.

1932–1935 еллар – Сирин иҗатының иң каршылыклы һәм иң катлаулы чоры. Күңеле бәргәләнгән, кемгә ышанырга да белмәгән шагыйрь (ул елларда бер-берсе өстеннән донослар язу таралган күренеш була) нинди генә темалар күтәрми дә, нинди генә темаларга язмый ул елларда! Иң элек, эзоп теленә мөрәҗәгать итеп, җәмгыятьтәге тискәре күренешләрне мәсәл жанры аша камчылый: «Кәҗә белән сарык» (1931), «Сатучы һәм сатып алучы» (1932), «Карга белән саескан» (1934), «Ишәк белән куян» (1935) һ.б. әсәрләр. «Сатучы һәм сатып алучы» шигырендә шагыйрь җәмгыятьтә сүз ирекле булмауны «утка тота». «Күңелле – күңелсез» шигырендә (1934) совет җәмгыятендәге чынбарлык күренешләрен ничек бар – шулай сурәтли.

Сириннең икенче алымы – шигырьләрне ул үзенә килгән хат яки телеграмма формасында яза башлый. Мәсәлән, «Лермонтовтан хат» шигырен (1933) Лермонтов исеменнән яза. Бу алымны «Тукаевтан Сирингә телеграм» («Мәйдан», 2016. № 4. Б. 62), «Тумаган балалардан хат», «Бөтен дөньяга телеграм» әсәрләрендә дә куллана. «Тумаган балалардан хат» әсәрендә балалар, дәүләтләргә мөрәҗәгать итеп: *«Тик сезнең файдагыз өчен / Кан түгү өчен генә, / Канлы фронтларга барып / Егылып үлү өчен генә / Без ул дөньяга тумыйбыз, / Яшәмибез, тормыйбыз / Әниләрнең карынында, / Нервалардан тыңлыйбыз»*, – дигән дәгъва белдерәләр.

Киләчәкнең нинди булачагын белмәү, һәр көн, һәр сәгатьтә үзеңне алып китүләрен көтеп яшәү шагыйрь күңелендә давыл куптара. Аның бунтарь җаны бәргәләнә, күкләргә аша. Тормышта кемнән ярдәм көтәргә, каян ямь табарга белми. «Хис» шигырендә (1933) ул, гаҗизләнеп, хәтта әҗәлгә дә эндәшергә мәҗбүр була. Әйтергә кирәк, бу елларда үлем темасы Такташта да күренә. Такташның «Ертык бүрек» (1927) әсәрендә, гәрчә ул оптимистик рухта язылган бул-

са да, «Үләрмен мин, бу ел кыш килгәч» дигән сүзләр, ә «Болай... гади җыр гына» (1928) шигырендә «асылып үлгән берәү» мотивы китерелә.

Тормышта шундый янау-куркытулар булуга да карамастан, Сириндә әле һаман да оптимистик рух саклана. «Шәфкать туташы» (1930), «Пушкиннан бер өзек» (1934), «Карлы» (1934) шигырьләрендә ул «киләчәктә бу авыр заманнар узар» дигән өмет белдерә. Бу елларда иҗат ителгән әсәрләрнең байтагында җәмгыять һәм шәхес, шагыйрь һәм хакимият проблемалары күтәрелә.

Юаныч эзләп, Сирин рус һәм чит илләр поэзиясенә мөрәҗәгать итә, алардан үзенең рухи халәтенә аваздаш мотивларны эзли. «Гаҗәпләнү (Әбел Галә әл-Мәгарридән)» (1933), «Алтын металл (Шекспирдан)» (1933), Есениннан этәрелеп китеп, «Зәңгәр кичтә», «Алсу кофта, зәңгәр күзләр» (1934) кебек әсәрләре языла. «Алтын металл (Шекспирдан)», «Каторжаннар» (1933) шигырьләрендә җәмгыятьтәге күп нәрсәнең акчага корылуы тәнкыйтьләнә.

1933 елда шагыйрь «Халыкара сугышка каршы Конгресста Сириннең сөйләгән беренче речь» дигән поэма язган. Безгә аның аерым бүлекләре генә килеп җиткән. Биредә автор берничә проблема күтәрә. Әсәрнең баш өлешендә ул төрле дәүләтләрдәге тынычлык һәм коралсызлану сәясәте хакындагы үз фикерләрен бәян итә. Аннан соң дәүләт һәм шәхес проблемасын алга чыгара. Монда еш кабатлана торган рефрен итеп:

Кеше өчен дәүләтләр яшиме?
Дәүләт өчен мәллә кешеләр?
Кеше өчен дәүләтләр яшәсә,
Нигә болай безнең бу эшләр? –

дигән сүзләрне ала. Әсәр эчендә автор аны төрле вариантларда куллана. Нәтиҗә рәвешендә дәүләтләрнең эшчәнлеге бары гади кешеләрнең ирекләрен кысуга гына юнәлдерелгән булуы турындагы фикер әйтелә.

1934 елда Сирин «Ана» поэмасын язган (Поэманың бер варианты астына «1934 ел, 25 ноябрь» дигән дата куелган). Әсәргә «1931 елда кулак итеп авылыннан куылган бер ананың Казан урамында үз малае белән очрашуы» дигән аңлатма бирелгән. Бу – шагыйрьне репрессияләүгә сәбәпче булган әсәрләрнең берсе. Поэманың тулы тексты безгә билгеле түгел, бары Эчке эшләр Халык комиссариаты архивында сакланган версиясе генә мәгълүм (поэма тәмамланмыйча калган ахрысы, чөнки текст тулы түгел).

Сталинның «Социализм җиңә барган саен җәмгыятьтә сыйнфый көрәш тә кискенләшә бара» дигән күрсәтмәсенең гади кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә ничек чагылуы, нинди каршылык-фаҗигаләр китереп чыгаруы тасвирлана бу поэмада. Сәяси карашларыннан чыгып, хәтта ана белән бала да икесе ике, капма-каршы лагерьда торып калалар. Әсәр нигезендә ана белән бала арасындагы сыйнфый-психологик конфликт ята. Унөч бала тәрбияләп үстергән ананы, ике сыер асрауда гаепләп (сыер бозаулагач, ике сыер булган), кулак дип, өен, барлык

мал-мөлкәтен тартып алалар, өеннән куып чыгаралар; ул хәзер шәһәр урамында хәер сорашырга калган. Вакыйга лирик герой – ананың улы исеменнән сөйләнә. Ана үз улыннан мәрхәмәтлек сорый. Үзен ничек итеп кулак ясауларын сөйли; аның сүзләрендә шул чордагы курку атмосферасы искиткеч реаль чагылыш таба. Ана, гаҗизлектән, хәер сорашырга мәҗбүр булган. «Әтиегез вафат булды, үлеп котылды», ди. Әмма революция идеяләренә нык бирелгән улы үз әнисенә карата коточкыч рәхимсезлек күрсәтә: әнисен сыйнфый дошман санап, аңа ярдәм итүдән баш тарта. Әсәрдә шундый мәрхәмәтсезлек күргән ананың тирән кичерешләре тасвирлана. Ананың өзгәләнүләренең нәтиҗәсе буларак, аның кулындагы күкрәк баласы шул вакыт җан бирә. Шулай итеп, әлеге поэма укучы күз алдына 1930 елларда махсус күпертелгән сыйнфый көрәшне, ул көрәшнең никадәр рәхимсез, кешелексез булганлыгын ачып сала [Шәрипов, б. 157–159]. Татар поэзиясе тарихында әлеге теманы бу кадәр тирәнлек белән күрсәткән башка әсәр юк шикелле.

Р. Мостафин: «„Идеологик тотнаксызлыкта“ гаепләп, Сиринне Язучылар берлегенә дә алмыйлар, „формализм“да һәм башка „изм“нарда гаеплиләр, – дип күрсәтә. – Ә сәләтсез шагыйрьләрне, „идеология“ ягына карап, бастыралар, бүләклиләр, югары күтәрәләр» [Мостафин, б. 163]. Поэзиядә үз дәрәҗәсен белгән, ачы телле Сирин үзен мондый кимсетүгә көчле сатира белән җавап бирә. Казанда оешкан язучылар төркемен ул «Ат кәмите» дип атый. Язучылар берлеге билеты булган каләм ияләрен «Күтәрик бокалларны!» (1934) шигырендә тәнкыйтьли, кешеләрнең авыр тормыштан, гаҗизлектән эчүгә бирелүләрен тасвирлый. «Паганини» (1935) шигыре дә ачы сатира белән сугарылган: анда «Паганини булмаса да, бездә „поганыйлар“ бар», дигән фикер үткәрелә.

Булат Солтанбеков Сириннең Сталинга эпиграмма язганлыгын хәбәр итә. Берләштерелгән дәүләт сәяси идарәсе (ОГПУ) архивындагы материалларга таяып, ул бер шымчының түбәндәге хәбәрен китерә: 1935 елның февралендә Сирин Һади Атласи фатирында үзенең башка әсәрләре белән беррәттән Сталинга язган эпиграммасын да укыган. Эпиграмма тексты безгә килеп җитмәгән, әмма Б. Солтанбеков аның эчтәлеген китерә. Анда «Сандугачым, һәр җырыңда син Сталинны мактап җырла. Шул чакта сине күреп алырлар һәм сиңа „СССРның атказанган сандугачы“ исеме бирерләр» дигән сүзләр булган [Солтанбеков].

Шагыйрь үзен кайчан да булса кулга алачакларын сизенгән, күңеленнән инде туган иле, иптәшләре белән хушлашып та куйган. 1934 елда ук ул «Хушыгыз, әй, кырларым» дигән шигырь язган. Анда болай диелә:

...Хушыгыз таллар, имәннәр,
Хушыгыз, әй, алмагач!
Кичерегез шагыйрь Сиринне:
Кыш сайрамый сандугач.

(шигырьгә «23. 11. 1934 ел» дигән дата куелган).

Сиринне 1935 елның 22 августында кулга алалар. Сорау алулар 1936 елның гыйнвар ахырына кадәр дәвам итә. Февраль башында карар чыгарыла: Сиринне биш елга Себергә сөрәләр. Ул анда, хәзерге Кемерово өлкәсендәге лагерьда, сәяси тоткын рәвешендә (ә сәяси тоткыннарга мөнәсәбәт аеруча кырыс була), искиткеч газаплар кичереп, биш еллык срогын үткәрә. Андагы тормыш турында безгә Сириннең машинкада басылган истәлекләре килеп җиткән (шагыйрь аларны сөргеннән кайткач, берәрсенә әйтеп яздырган булса кирәк).

1936 елдан алып Сирин иҗатында икенче чор башлана. Сөрген елларыннан аның «Мин кайда булдым? – Мин шунда булдым» (шигырьнең бер варианты «„Син кайда булдың?“ диючеләргә» дип атала. ОГПУ архивында саклана торган бу текст ахырына «29/VII–33» дигән дата куелган. Димәк, Сирин аны 1933 елда, үзен вакытлыча изоляторда тоткан чакта ук язган булырга мөмкин), «Мунча ташы» (Беренче вариант), «Стаканнарым», «Яшьлегем яшькә буялып...», «Уйнак яр (үзбәк җыры «Яр-яр»га ияреп)», «Җыр турында» һ.б., барлыгы уннан артык шигыре килеп җиткән. Гәрчә аларга «1936 ел» дигән дата куелган булса да, Сирин аларны сөргеннән кайткач, хәтереннән алып теркәп куйган булса кирәк. Аларда шагыйрь үзенең тоткын булуын, туган җиреннән аерылып яшәү ачысын сурәтли.

Ниһаять, 1940 елның көзендә Сирин, сөрген срогын тутырып, туган иленә кайта. Ул бик бетеренгән, хәлсезләнгән, ябыккан була. «Бала вакытым» шигырендә (1941) шагыйрь үзенең шул чактагы кыяфәтен сурәтли:

«Мин кешеме, түгелме?» – дип,
Хәзер карыйм көзгедән.
«Бу – мин, чын үзем түгел», – дип,
Куркып китәм үземнән.

1941 елда, бераз хәл алгач, Сирин үз теләге белән Ватан сугышына китә. Смоленск юнәлешендәге сугышларда катнаша. 1942 елның көзендә, авыр контузия алып, Кәрәкәшлегә кайта. 1942–1943 елның кышын авылда үткәрә. Сәламәтләнә төшкәч, колхоз эшенә чыга: атлар карый, кырдан салам ташый, басуда кар тота. Шул чакта ул «Кар тотканда» дигән әсәрен (1942) иҗат иткән. Монда ул тыныч тормышка, табигать кочагында эшләп йөрүгә дан җырлый: шундый газаплар күреп кайткан кешегә колхоз эше уен кебек кенә күренә. Әсәрдә тыныч хезмәтнең кешегә шатлык алып килүе тасвирлана.

1943 елның язында Сирин яңадан фронтка китә. Шул ук ел ахырында, авыр яраланып, Ташкент госпиталенә җибәрелә. Анда бераз сәламәтләнгәч, әмма хәрби хезмәткә яраксыз рәвештә, туган авылына кайта; бераздан колхозда эшли башлый. Сугыштагы батырлыклары өчен Сирин «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен», «Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакарь хезмәт өчен» һәм «Бөек Ватан сугышында җиңүнең 20 еллыгы» медальләре белән бүләкләнә.

1946 елдан Сирин Баулы районы үзәге Акбуа бистәсендә яши башлый. Колхоз аны берьеллык умартачылар курсына җибәрә. Курсны тәмамлагач, Кәрәкәшле һәм Ташкичү авылларында умартачы булып эшли. Монда да ул бик тырышып хезмәт куя. Хезмәттәге уңышлары өчен ике тапкыр Баулы район хакимиятенең Мактау кәгазе белән бүләкләнә. Сирин Татарстан АССР Югары Суды Президиумының 1957 елның 13 июнь карары белән реабилитацияләнә.

Тормышында бер-бер артлы тезелеп килгән каршылык-авырлыклар аркасында Сириннең гаилә тормышы озак еллар буена оешып җитә алмый. Өстеннән гаебе алып ташланганнан соң гына, 1960 елның 1 сентябрендә Сирин Акчишмә авылыннан Фәһимәгә өйләнеп, үз гаиләсен корып җибәргән. Бу вакыйга аның иҗатына уңай йогынты ясаган, иҗаты җанланып, үсеп киткән.

Сөргеннән соңгы елларда, кайбер белгечләр язганча (Р. Мостафин, мәсәлән, «1935 елдан алып 1970 елга чаклы аның яңа язылган бер генә шигъри юлы да билгеле түгел» дип яза [Мостафин, б. 164]), Сириннең иҗаты туктап калмый, ул бераз сүлпәнләнә генә, элеккеге ярып сала торган кискенлеге йомшара төшә. Шунысы хак: сөргеннән соң ул инде 1930 елларда үзе барлыкка китергән «Сирин стиле»нә әйләнеп кайтмый, ә традицион стильдә иҗат итә. Чөнки җәмгыятьтәге вазгыять тә инде үзгәргән: революцион күкрәнүләр заманы узган, тормыш салмакланган һәм андый шигырьләргә дә ихтыяҗ инде беткән була. Шагыйрь архивыннан күренгәнчә, сөргеннән соң ул барлыгы 90 нан артык шигырь һәм берничә әкият иҗат иткән. 1940–1959 елларда ел саен икешәр-өчәр әсәр язып килгән булса, гаилә корганнан соң – 1960 елда ул 11, ә 1961 елда барлыгы 35 шигырь иҗат иткән. Әмма мондый иҗади активлык озакка бармый, шагыйрьнең сәламәтлеге начарлана: сөргендә алган суык тиюләр, яралар, сугышта алган контузияләр өстенә аңарда туберкулез авыруы башлана. Шулай да ул әле каләмен ташламый. 1962 елда аның авыруы көчәеп китә һәм ул Акбуа (Баулы) туберкулез диспансерына кереп ятарга мәҗбүр була. Аның архивында 1961 елдан соңгы бары биш кенә шигыре сакланган.

Сөргеннән кайткач, Сирин үзенең яшьлек дусты Хәсән Туфан белән дә очрашкан. Мәсәлән, Локман Бадыйкшан истәлегендә 1959 елның 19 декабрендә Казанда язучыларның Г. Тукай клубында үткән бер кичәдән соң Хәсән Туфан белән Сириннең кочаклашып күрешкәнлеге турында язылa [Бадыйкшан]. Шуннан соң ике шагыйрьнең дуслыгы тагын яңарып китә. Алар үзара хатлар алышалар, бер-берләрендә кунакта да булалар. Х. Туфан Сирингә 1958 елда чыккан «Җырлар, шигырьләр» китабын үзенең яшел карасы белән «Сирин! Дөньяда икенче кат яшәгән кабатланмас матур көннәребез истәлеге булсын бу сиңа. Ихтирам белән, Х. Туфан. 27.XI.61» дип язып бүләк иткән (бу китап Сирин архивында саклана).

Сириннең 1940–1969 елларда язган әсәрләрен аның иҗат юлындагы аерым бер этап итеп карасак, ул дәвер шагыйрь иҗатында түбәндәге темалар күтәрелүен күрербез.

Сирин сәяси темаларга язуын дәвам итә, җәмгыятьтәге тәртипсезлекне, «кызыллыкны» сатира утына ала. Мәсәл жанрын җанландырып җибәрә. «Карт большевик, милиционер һәм кызыл сыбызгы» (1952) («Мәйдан» журналы, 2007 ел, № 3. Б. 108–109) әсәрендә карт большевик белән милиционер арасындагы сөйләшү китерелә. Берәү, исереп егылгач, милиционер сыбызгысын сызгырта. Карт большевик канәгатьсезлек белдергәч, милиционер сыбызгының гади түгеллеген, ә «социалистик сыбызгы» икәнлеген әйтә. «Шатлыклы үлем» мәсәлен (1953) Сирин Сталин үлеменә багышлаган.

«Матур хатын» әсәрендә (1956) дә шагыйрь «социалистик агач» дигән гыйбарәне сатирик максатта куллана. Халыкка кояш тотылуның сәбәбен аңлатып, Сирин «Дөнья бетми мәңге дә!» шигырен язган. 1961 елның 12 апрелендә Юрий Гагаринның Җир тирәли әйләнеп кайтуына Сирин «Күкләр капкасы ачык!» шигырен багышлаган. Анда автор совет фәне һәм техникасының алга китүе белән горурлана. «Канцлер Аденауэр һәм шагыйрь-доктор» әсәрендә (1961) шагыйрь намусы, аның җәмгыятьтәге роле темасы күтәрелгән.

Сирин балалар әдәбиятының җәүһәрләре булып саналырлык әсәрләр иҗат итә: биш бүлектән торган «Бишек җыры», нәниләр өчен «Чеп-чепләрем, пип-пипләрем», «Безнең өйдә иң кадерле кеше» әсәрләрен яза. Сәнгатьчәлек ягыннан алар искиткеч камил эшләнгән, «җырлап торалар».

Мәктәп, белем алу, балалар тәрбияләү темасына Сирин «Кире малай» (1942), «Күзлек (1945), «Ана белән бала» (1948), «Нәни оратор» (1951), «Мин кунак дип тормаган» (1951), «Мәктәп» (1958), «Алтын күзлек» (1958), «Биек баскыч, көмеш ачкыч» (1958) һ.б. әсәрләрен багышлаган.

Умартачы булып эшли башлагач, Сириннең сизгер күңеле табигатьнең башкалар игътибар итмәгән нечкәлекләрен дә күрә, тоя, үз күңеле аша үткәрә башлый. Бал корты белән чәчәкләр арасындагы гармонияне, аларның бер-берсенә тартылуларын поэтик югарылыкка күтәреп, ул «Зур кунак» шигырен яза (1961). «Кортлар шәһәре» (1960), «Бал бабай» (1961) шигырьләрен дә Сирин шундый ук нечкәлек һәм тирән мәхәббәт белән иҗат иткән. Әдип архивында аның үзенең умартачылык эше тәҗрибәсеннән чыгып язылган «Эшче кортларның серкә урлап кайтулары турында бер тәҗрибә» дигән мәкаләсе дә сакланган (ул аны берәр матбугатта бастырып чыгарырга дип язган, ахрысы. Әмма бастырырга өлгерә алмаган). «Кошлар – безнең дусларыбыз» (1961), «Күрәсем килә» (1961) шигырьләре исә кошларга карата тирән ярату һәм хөрмәт белән сугарылган.

Шулай итеп, Сирин 1940–1960 елларда да кулыннан каләмен ташламаган, хәле килгәнчә әдәби процесста да катнашып барган. Алда искә алынганча, үзе исән чагында, Татарстан китап нәшриятында 1959 елда, Зыя Мансур редакцияләвендә аның зур булмаган «Шигырьләр» китабы басылып чыккан (бу китапка рецензияне М. Латифуллин язган: «Совет Татарстаны» газетасы. 1960.12 январь. № 9). Шигырьләре сирәк булса да вакытлы матбугатта да басылгалап килгән (кара: «Совет әдәбияты». 1962. № 2. Б. 76–77, «Көнче күрше», «Сугыш кырларыннан», «Күрәсе килә» шигырьләре); «Ялкынлы еллар поэзиясе» җыентыгы (төз. С. Мортазин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Б. 169. «Ачлар тавышы» шигыре; «Ялкын» журналы, 1980, № 1. Б. 12–13. «Язгы тамчылар» шигыре). «Мәйдан» журналының 2015 елдагы 12 нче саны тулысынча Сирин иҗатына багышлап чыгарылды: анда аның күп кенә шигырьләре, прозасы, аның турында истәлекләр, мәкаләләр һәм аның фотолары басылды.

Шагыйрьнең архивында проза әсәрләре дә бар. Мәсәлән, 1927 елда ук ул «Авыл яшьләре» журналында (№ 6) «Диңгез пароходында» дигән зарисовка-репортаж бастырган. Анда «Аврора» крейсерында хезмәт иткән сугышчыларның көндәлек шөгыльләре бәян ителә. 1930 елларда Сирин «Казенный печән» хикәясен, «Кич белән» нәсерен һәм «Уполномоченный» дип язарга ниятләгән әсәренең планын чәчмә белән язып куйган.

Сөргеннән кайткач, әдип берничә әкият иҗат иткән, архивында шулай ук аның үз кулы белән язган «Мәгънәсез тәнкыйтькә җавап» мәкаләсе, әдәби иҗат турындагы фикерләре, «Язучылар берлегендә Сириннең чыгышыннан бер өземтә» дигән язма да сакланып калган.

Шагыйрь тормышының соңгы еллары рәхимсез туберкулез авыруы белән көрәшеп узган. Иң соңыннан язган «Уты сүнгән вулкан» (1960), «Бер кисәк» (1964) шигырьләрендә Сирин үзенең хәл-әхвален тасвирлый. «Бер кисәк» шигырендә мондый юллар бар:

Теләкләрем чиксез минем,
хисапсыз;
Йөрәк тибүләрем санлы, хисаплы.
Исәп-хисап эшләрем күп ничаклы,
Тәндә җаным кунак, белмим,
ничаклы?

Шагыйрь Сирин озак һәм каты авырудан соң 1969 елның 23 ноябрендә Акбуада вафат була һәм шул бистәдәге татар зиратына җирләнә. Әдипнең тууына 90 ел тулуны билгеләп үткән вакытта аның каберенә Баулы районы хакимияте тарафыннан Сириннең барельефы төшерелгән истәлекле таш куелды. Баулыда, Урыссу бистәсендә һәм Кәрәкәшледә Сирин Батыршин исемендәге урамнар бар. Үзенең бөтен гомерен гаделлек өчен көрәшкә багышлаган күренекле шагыйрьнең якты истәлеге бүген әнә шулай саклана.

## Әдәбият

*Аминева В.Р.* Габдулла Тукай и русская литература XIX века: типологические параллели. Казань: Татар. кн. изд-во, 2016.

*Әхмәт Исхак.* Бәләкәй генә бер истәлек // Чаян, 1987. № 3.

*Бадыйкшан Л.* Шагыйрь белән очрашулар // Ватаным Татарстан. 1997. 14 гыйнвар.

*Игәнәй Ямаш.* Эз сызып атылган йолдыз...// Аргамак. 1996. № 12. Б. 96.

*Мостафин Р.* «Кыш сайрамый сандугач...» // Казан утлары. 1996. № 12. Б. 163.

*Пехтелев И.Г.* Тукай и русская литература. Казань: Таткнигоиздат, 1966.

*Сирин.* Тамчылар. Казан: Татиздат, 1931. Б. I–XI.

*Солтанбеков Б.* Серең ач, Сирин!.. // Мәдәни җомга. 1995. 21 июль.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 95–96.

*Шәрипов Ә.* Сириннең Тукайга шигъри җавабы // Мәйдан. 2016. № 4. Б. 57–62.

*Шәрипов Ә.* Шагыйрь Сириннең «Ана» поэмасы // Ислам и тюркский мир: проблемы образования, языка, литературы, истории и религии: материалы VIII Международной тюркологической конференции (Россия, Республика Татарстан, г. Елабуга, 22 апреля 2016 г.) / отв. ред. А.З. Нигамаев. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2016. Б. 157–159.

***Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр*
*һәм ресурслар институты профессоры*

УДК 821.512.145-2

***Ф.Х. Миңнуллина***

# Н. ИСӘНБӘТ ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ШӘХЕС ИРЕГЕ

Проблема духовной свободы личности, свободы любви, нравственного выбора человека в сложнейших жизненных обстоятельствах, поднятые в пьесах Н. Исанбета «Миркай и Айслу», «Муса Джалиль», «Ходжа Насретдин», «Марьям», «Идегей», решаются в каждом из этих произведений по-новому. В них показана трагедия человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания.

**Ключевые слова**: трагедия, личность, пьеса, конфликт, драма, свобода, нравственный выбор.

Нәкый Исәнбәт – татар драматургиясенең төрлелеген, үсеш-үзгәрешен, тема һәм жанр байлыгын, заман проблемаларын чагылдырган авторларның берсе. Ул әдәбиятта үз йөзе, үз урыны булган, театр сәхнәләрендә әсәрләре зур уңыш белән барган каләм иясе. Инкыйлабка кадәр үк сәхнә әсәрләре язуда үзен сынап караган язучы, совет хакимиятенең беренче елларыннан башлап, бу жанрга төп игътибарын юнәлтә һәм бер-бер артлы күренекле комедия, драма һәм трагедияләрен иҗат итә. Әдипнең драматургия өлкәсендә эзләнүләре, тормышны чагылдыру омтылышы да универсальлеккә дәгъва итә. «Н. Исәнбәтнең нәфис әдәбият өлкәсендәге иң зур уңышлары драматургия белән бәйле. Әле революциягә кадәр үк сәхнә әсәрләре язуда каләм тибрәткәләгән әдип, совет властеның беренче елларыннан башлап, бу жанрга төп игътибарын юнәлтә һәм бер-бер артлы күренекле комедия, драма һәм трагедияләрен иҗат итә. Ул – утыздан артык сәхнә әсәре авторы» [Даутов, Нуруллина, б. 211–210]. Аның драма әсәрләре сан-күләме белән генә түгел, югары сәнгать дәрәҗәсенә ирешү ягыннан да әдип иҗатында һәм татар әдәбияты үсешендә күренекле урын тота.

Н. Исәнбәтне 1920 еллар татар әдәби барышында күренекле драматург итеп таныткан «Һиҗрәт» (1923), «Культур Шәңгәрәй» (1927), «Пикүләй Шәрәфи» (1929), «Портфель» (1929) кебек сатирик комедияләрдә НЭП чорында җанланып киткән спекулянтлар, яңа заман түрәләре һәм алар белән эш итүче шәхесләр рәхимсез көлү объекты итеп алына, чорның кимчелекле күренешләре кискен сатира ярдәмендә фаш ителә. Бу юнәлештә иҗат ителгән комедияләре Н. Исәнбәтне яңа хакимияттәге уңай күренешләрне чагылдырмауда гаепләүләргә китерә. Мәсәлән, Дәүләткол дигән автор: «Портфель» авылдагы муллаҗанизмны рәхимсез рәвештә ярып күрсәтә дә, аларга каршы куелган сыйнфый көч – авылдагы хәзерге социализм һөҗүме – колхоз хәрәкәте бөтенләй яктыртылмый» [Дәүләткол] –

дип яза. «Пикүләй Шәрәфи» комедиясенә бәйле Г. Кутуй, С. Фәйзи мәкаләләрендә яңа хөкүмәт шартларында карьеристларның чынбарлыкта булуы шик астына алына. Заман тәнкыйте драматургның совет законнарын яхшы белеп эш иткән тискәре геройларны сәхнәгә чыгару максатын: элеккеге мулла Миргаянның («Портфель»), советлашкан сәүдәгәр Шәрәфинең («Пикүләй Шәрәфи») совет хакимиятендә җылы урын эзләүләрен сурәтләп, җәмгыятьтәге ялганга, алдауга юл калдырылу хакында кисәтергә омтылуын ачыклый-билгели алмый. Автор чынбарлыкның кешеләргә тәэсирен, заманның яңа кешесе формалашуын да шул рәвешле игътибарга ала.

Н. Исәнбәт иҗатында 1930 еллардан соң кайбер үзгәрешләрне дә күзәтергә мөмкин. Биредә сүз әдипнең иҗат эволюциясе, герой концепциясе, тематиканың яңарышы турында бара. Халык авыз иҗатына һәм геройларына нигезләнгән «Спартак» (1932), «Миркәй белән Айсылу» (1935), «Хуҗа Насретдин» (1939), «Түләк» (1942), «Әбүгалисина» (1959), «Кырлай егете» (1968), «Хәйләкәр Дәлилә, яки «Мең дә бер кичә»дән бер кичә» (1978) кебек әсәрләрендә драматург фидакарь көрәшче, гуманист, халыкларны яклаучы геройларны әдәбият мәйданына чыгара.

Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу» (1935) драмасында, мәсәлән, XIX йөз татар авылындагы яшәеш, мохит, 1891 елгы корылык, ачлык Миркәй белән Айсылуның мәхәббәт тарихы аша тасвирлана. Гашыйклар фаҗигасе дини әхлак кануннарына бәйләп аңлатыла. Халыкның иреге, хокуклары, хәтта мәхәббәткә дә урын булмаган бу дәвердә яшьләр арасына кулак Дәүли керә: бинахакка рәнҗетелгән, урамда мәсхәрәләнеп йөртелгән Айсылу акылдан язып суга ташлана, сөйгәнен югалткан Миркәйнең дә гомере өзелә. Фаҗига очраклы түгел, ә гаделлеккә, кеше бәхетенә каршы куелган явызлыкның көчлерәк булуыннан килеп туа. 1966 елда сәхнәгә куелган нөсхәдә егетнең үзенә аткан Дәүлине пычак белән кадап үтерүе яки 1946 елгы үзгәртелгән вариантта суга күтәреп атуы Миркәйне коралга тотынган бунтарь-көрәшче дәрәҗәсенә күтәрә [Ханзафаров, б. 111]. Ләкин аның гадел хөкеме – бунтарь шәхеснең формалашу процессын күрсәтүче фактор гына. Шушы хәлләрдән соң авыл кешеләре изүгә каршы оешкан төстәрәк протест белдерә башлыйлар. Бу бәрелешләр халык арасында социаль көрәшнең тууын хәбәр итә, ул дөньяга караш, әхлакый кыйммәтләр яссылыгында да бара. Кеше бәхете аның ирегеннән башка була алмый, шәхес иреге халык азатлыгыннан аерылгысыз дигән фикер укыла.

Сугыш елларында язылган «Түләк» драматик поэмасының нигезен дә халыкта яшәгән өметләр-хыяллар, легенда-риваятьләр тәшкил итә. Н. Исәнбәт либреттосына Н. Җиһанов иҗат иткән «Түләк» операсы театр сәхнәләрендә зур уңыш белән бара. Текст болгарларның илбасарларга каршы көрәшенә багышланган, әлеге каршылыкны

Алимбәк ханның кызы Аембикә һәм Түләк арасындагы мәхәббәт тагы да кискенләштерә. Кыз тарафыннан кире кагылган Сартлан Болгар иленә монгол гаскәрләрен алып килә. Бу көрәштә хан да, аның кызы Аембикә дә үтерелә. Халык авыз иҗатындагы кебек үк, кол анадан туган, кыерсытылган, әмма Ватаны, мәхәббәте өчен җанын да кызганмаган Түләк халкын яклап дошманга каршы күтәрелә. Әсәрдә аның бабасы – чал чәчле ил карты образы бар, ул «Идегәй» дастанындагы халкыбызның үткән тарихын гәүдәләндергән Субра кебек ил агасы булып күзаллана [Татар әдәбияты тарихы, б. 447]. Бу драмалардан аермалы буларак, «Хуҗа Насретдин», «Җирән Чичән белән Карачәч Сылу» комедияләрендә кораллы көрәшкә каршы акыл, үткенлек, зирәклек куела. «Хуҗа Насретдин»да Болгар чорында халыкның чит ил басып алучыларына каршы һәм үзләренең булдыксыз түрәләре белән көрәше гәүдәләнә. Фольклор мотивларына нигезләнеп язылган һәм беренче мәртәбә 1940 елда сәхнәгә менгән, бүгенге көндә дә яратып башкарыла торган «Хуҗа Насретдин» комедиясе (1939) язучыга аеруча зур уңыш китерә. Анда халыкның гасырлар дәвамында гадел патша турындагы уй-хыяллары чагылыш таба: Хуҗаның хан булуы, халыкчан идарә итә башлавы шуның белән аңлатыла. «Җирән Чичән белән Карачәч Сылу»ның төп каһарманы Җирән хезмәт кешеләрен чит илләргә ялланган солдат, кәнизәк итеп озатуга, өстен сыйныфларның үз ватандашларын сатып табыш алуларына каршы чыга. Ул илләр арасындагы бәхәсләрне тыныч юл белән хәл итә: хан да аның шәхси хокукларын таный, егетне иректе дип белдерә.

Җирән Чичән – шулай ук халык үзе тудырган образ. Н. Исәнбәт Карачәч сылу һәм Җирән Чичән образларында халыктагы җорлык, тапкырлык, акыл көче ярдәмендә дошманнарын җиңү кебек сыйфатларны туплап бирә, аларны Янгура, Кәбеш кебек мәрхәмәтсез, кайчак надан, куркак хаким сыйныфларга каршы куя. Хан Җирән чичәнгә үз сакалын теләгәнчә сыпырырга да хакы юклыгын аңлатканда, автор шушы гротеск аша Сталин репрессияләренә дә ишарә ясый. Халыкны гәүдәләндергән Җирән чичән һәм Карачәч сылу дәүләт идарәсенең әхлаксызлыгын, мәкерен җиңеп чыгалар.

«Миркәй белән Айсылу», «Түләк», «Җирән Чичән белән Карачәч Сылу» кебек әсәрләрдә драматург хакыйкатьне, халык мәнфәгатьләрен яклап чыккан геройлар – халык арасында гасырдан-гасырга күчеп яшәгән әкияти каһарманнарны тергезә. Соңрак Исәнбәт тарихи шәхесләрне, ил күләмендә барган масштаблы вакыйгаларны сурәтләүгә дә игътибар бирә. Мәсәлән, «Мулланур Вахитов» (1943–1944) героик драмасында Октябрь инкыйлабы һәм гражданнар сугышы елларында эшче-крестьяннарга бәйсезлек яулау юлында үзен корбан иткән каһарман М. Вахитов гәүдәләнә, драмада ул инкыйлаб символы дәрәҗәсенә куела. Идеологик басым гаять көчле булуга

карамастан, Н. Исәнбәт драматургиядә, инкыйлаб идеяләренә үреп, гомумкешелек идеалларын, гуманистик фикерләр яңгыратуны дәвам итә. Татар театрының формалашуын һәм үсешен тасвирлаган «Гөлҗамал» драмасы, колбиләүчеләр белән гладиаторлар арасындагы конфликтка корылган «Спартак» трагедиясе шундыйлардан.

Н. Исәнбәт сурәтләвендәге Спартак, мәсәлән, көчле, алдан күрүчән, максатчан шәхес. Ул таркау коллар, гладиаторлар белән Рим кебек көчле дәүләтне җимереп булмаячагын, бу канлы бәрелешнең үзләре өчен һәлакәт белән тәмамланачагын белә. Үткән тарихка мөрәҗәгать итеп, драматург тигезлек, туганлык, ирек, бәхет кебек мөһим гомумкешелек кыйммәтләре өчен көрәшү мәҗбүрияте проблемасын күтәрә.

Бөек Ватан сугышы елларында халыкның тылдагы батырлыкларына багышлап, Н. Исәнбәт «Мәрьям» трагедиясен иҗат итә. Сугышның беренче көннәрен чагылдырган әсәрдә тылдагы дошманга каршы бердәм күтәрелгән халык илбасарларга каршы куела. Әмма драматург һәрбер геройның ни өчен көрәшкәнлеген – «тормыш тарихын» ачып бирә алган. Мәрьям кебек фидакарь геройлар туган нигезе, иле өчен гомерләрен җәлләмәсә, элеккеге кенәз, эмигрант, хәзер дошман ягында тәрҗемәче булып торган Лыков кебекләр мал-мөлкәтләрен кайтару максаты белән йөриләр. «Әйе, мин Лыков. Сез мине беткән иде дип уйлаган идегезме? Урманны кистегез, җиремне сөрдегез, менә хәзер мин кайтып, сезнекеләрне тагын җиремнән сөрәм, туташ» [Исәнбәт, б. 217], дип аңлата ул үзенең эш-гамәлләрен. Исәнбәтнең мондый геройлары күп язмышларны берләштергән, шулардан җыйнала торган ил, кешелек тарихы хакында уйлануларга китерә.

«Муса Җәлил» трагедиясендә дә драматург сугыш фаҗигасендә буыннар, милләтләр фаҗигасен чагылдырырлык геройлар таба. Н. Исәнбәт туган җирләреннән Алман иленә күчеп киткән, туганлык җепләрен югалткан Зәбир Альбиков нәселенең өч буын вәкилләрен сурәтли: Зәбиргә, Лыков кебек, туган җиренең малы гына кирәк; улы Фәрит туган телен оныткан, халкының милли йолаларын белмәгән һәм белергә теләмәгән каты күңелле кеше булып үсә, Бөек Ватан сугышында ватандашларына каршы көрәш юлына баса. Горефгадәтләреннән, теленнән аерылган, туган халкының җырын ишетүгә сусап яшәгән Газизә карчык туган туфрагына кайтып үлү теләгенә дә ирешә алмый.

Трагедияләрнең төп каһарманнары гадәттә көчле шәхес буларак ачыла. Н. Исәнбәт тә Мәрьямнең, Спартакның, Муса Җәлилнең кешелек идеаллары өчен тирән борчылу, газаплану кичерүен алгы планга чыгара. «Муса Җәлил» трагедиясендә шагыйрь белән илбасарлар арасында барган фаҗигале бәрелеш Җәлилнең ватанчылык хисен, халкына, туган иленә бирелгәнлеген, милли горурлык белән янып яшәвен күрсәтә. «Драматург иҗат максатын «шагыйрь һәм тиран көрәшен күрсәтү» дип билгеләсә

дә, чынлыкта, пьеса тагын да киңрәк колач ала. Ул заман проблемалары, халык язмышы, идеяләр көрәше турында әсәр булып үсә» [Ханзафаров, б. 158]. Шәхес язмышы милләт язмышына, ил, Ватан язмышына әверелә. Тарихи трагедияләрдән булган «Идегәй» (1938–1941) илдә патриотик рух күтәренкелеге хөкем сөргән чорда, заказ белән иҗат ителә. Исәнбәт, эпосның 17 вариантын файдаланып, җыйнама вариант әзерли һәм аны 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында махсус мәкалә рәвешендә бастырып чыгара. С. Липкин эпосны рус теленә тәрҗемә итә башлый. Трагедия Казанда күрсәтелә, 1941 елда Мәскәүдә узачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы программасына кертелә. Әмма сугыш башланып китә [Тагиров, б. 86–93].

1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында» дигән карарда татар халкының «Идегәй» дастанына «ханнар-феодаллар эпосы» дигән нахак бәя бирелә. Аны халыкка каршы юнәлдерелгән әсәр дип атыйлар. Н. Исәнбәт иҗат иткән трагедия дә шундый ук язмышка дучар була. «Идегәй» дастаны 1980 еллар ахырында гына халыкка кайта: 1988 елда татарча, ә бер елдан соң рус телендә нәшер ителә.

Н. Исәнбәт әсәрендә Идегәй образы, изелгәннәрне яклаучы буларак, тарихка һәм халык авыз иҗатына (дастанга) тугрылыклы рухта языла. Ул – кыю хәрби җитәкче, зирәк дәүләт эшлеклесе, драматик язмышлы ата, ил азатлыгы һәм иминлеге өчен көрәшүче фидакарь. Заман «тәнкыйтьчеләре» Идегәйне «хезмәт иясе вәкиле» буларак сурәтләргә тәкъдим итәләр. Алай тарихилык бозылачак дип, Н.Исәнбәт башка юл таба: эпоста булмаган «хезмәт ияләрен» әсәргә кертә (Янбулат, сукачы Килмәт, Чулпан һ.б.) [Татар әдәбияты тарихы, б. 251].

Трагедиядә халык дастанын турыдан-туры кабатлау юк. Үзәк конфликт итеп Идегәй белән Туктамыш хан арасындагы көрәш алына, дәүләт язмышының аерым бер кешеләр холыкларына, теләк-омтылышларына мәгълүм дәрәҗәдә бәйле булуы тасвирлана. Туктамыш хан тәхет өчен көрәш алып барса, Идегәй, гаделсезлекләргә чик кую максатыннан, ханга каршы күтәрелә. Бу вакыйганың дастани нигезләренә кагылып, Ф. Урманчеев болай дип яза: «Идегәй, заманында, ханга каршы нинди дә булса заговор оештыргандыр дип кистереп әйтеп булмый. Һәрхәлдә, тарихи чыганакларда бу хакта бернинди дә мәгълүмат юк.... Сүз ниндидер оешкан заговор яисә халык күтәрелеше турында түгел, ә бәлки нигездә хан тәхете, аның сарае тирәсендәге интригалар, хакимлек өчен ызгыш-талашлар хакында барырга тиеш» [Урманчеев, б. 84–85].

Тарихта каһарманның Җучи Олысы биләмәләренә Аксак Тимер гаскәре белән кайтуы төрлечә шәрехләнә. В. Жирмунский, А.Д. Греков, А.Ю. Якубовский һ.б. аны Алтын Урда дәүләтенең гомерен озынайткан, бу дәүләт

өчен көч куйган шәхес буларак бәяләсәләр, Р. Фәхретдинов, М. Сәфәргалиев, М. Гайнетдинов һ.б. Идегәйне Алтын Урда дәүләтен таркатуда гаеплиләр.

«Халык телендә дастан каһарманнары гадәттә «батыр» дип атала. Зур батырларны зур вакыйгалар тудыра. Зур вакыйгаларда халык ягыннан торып көрәшкән, шул юлда гадәттән тыш эшләр күрсәткән кеше халык каршында батыр булып санала. Мондый батырлар көтелмәгән рәвештә корбан булып калулары мөмкин» [Исәнбәт, б. 75–99]. Н. Исәнбәтнең бу сүзләре куркыныч һәм тигезсез көрәшкә чыккан трагедия герое холкына һәм гамәлләренә ачыклык кертә. Драматург Идегәйнең ханга каршы баш күтәрүен Туктамыш алып барган сәясәт белән килешмәвенә бәйләп аңлата. Ханның да аны һәм бүтән биләрне эзәрлекләвен шикләнүләр нәтиҗәсендә туган репрессия дип карарга мөмкин: Идегәйнең этисе дә шул мотив белән юк ителә. Хан алып барган сәясәтнең гаделсезлеге әсәрдәге коллар сату күренешендә дә чагыла. Янбулат, сукачы Килмәт, Чулпан кебек уйланма персонажларны иҗат итеп, драматург халыкның авыр язмышын сурәтли.

Җыеп әйткәндә, Н. Исәнбәт драматургиядә ил-халык язмышына бәйле тарихи вакыйгаларны, шул вакыйгаларда катнашкан легендар каһарманнарны гәүдәләндерү юнәлешендә иҗади активлык күрсәтә. «Һиҗрәт» (1923) сатирик комедиясе, «Хуҗа Насретдин» (1939), «Зифа» (1954) комедияләре, «Миркәй белән Айсылу» (1936) драмасы, «Спартак» трагедиясе (1940), «Мулланур Вахитов» (1946), «Муса Җәлил» (1956) тарихи-биографик драма һәм трагедияләре – чын-чынлап татар әдәбиятының яңа үсеш этаплары булып, татар драматургиясенең алтын фондын тәшкил итә.

**Әдәбият**


*Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.* Совет Татарстаны язучылары. Казан, 1986. 122 б.

*Дәүләткол.* «Портфель» сәхнәдә // Коммуна. 1930. 19 январь.

*Исәнбәт Н.* Татар халык эпосы «Идегәй» дастанының 500 еллыгына // Совет әдәбияты. 1940. № 11. Б. 75–99.

*Исәнбәт Н.* Сайланма әсәрләр: өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Т. 3. 217 б.

*Тагиров И.* «Идегәй» эпосына кем богау сала? // Мирас. 1997. № 7. Б. 86–93.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 5. 447 б.

*Урманчеев Ф.* Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 84–85.

*Ханзафаров Н.* Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 158 б.



***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***А.М. Сафина***

# ӘДӘБИ КҮРЕНЕШ БУЛАРАК МИЛЛИ ХАРАКТЕР

Значимость данной работы состоит в том, что она раскрывает представление о роли и значении национального характера как литературоведческой категории. Анализируются и осмысливаются различные взгляды литературоведов на проблему национального характера.

**Ключевые слова:** национальный характер, литература, художественный характер, литературовед

Хәзерге чорда җәмгыятьнең үсеш шартлары, иҗтимагый мөнәсәбәтләр, мәдәният һәм фән-техника өлкәсендәге үзгәрешләр халыкның борынгы тамырларына, тарихи үткәненә, йолаларына, гореф-гадәтләренә, диненә һәм хәзерге тормыштагы ролен, урынын аңлауга игътибарны арттыра. Санап үтелгәннәрне ачыкларга милли хис, милли тойгы, милли аң, милли характер ярдәм итә. Милли хисләр һәм милли аң конкрет эшчәнлекне тудыра, ә милли характер шушы эшчәнлекнең сыйфатын билгели. Милли характер, кешенең конкрет юнәлештәге эшчәнлегенең нәтиҗәсе буларак, фәкать милли хисләр, милли мәнфәгатьләр турында уй-фикер йөртү аша гына формалаша ала. Милли характер – реаль күренеш, ул чынбарлыкның үзендә, кешеләрнең фикерләү ысулында, телендә, сәнгатендә, йолаларында, әйләнә-тирәдәге күренешләргә мөнәсәбәтендә чагыла.

Мәкаләдә төп нигез итеп алынган *милли характер* төшенчәсенең асылын, төзелешен, үзенчәлеген матур әдәбият мисалында ачыклау максаты куелды. Милли характерның әдәбияттагы урынын ачыклауга зур урын бирелгәнлектән, әдәбиятта характерның роленә дә тукталып китү урынлы булыр. Әдәбиятта характер матур әдәбиятның төп хасияте, язучының сурәтләү объекты төсендә карала. «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә характер төшенчәсе: «индивидуаль конкретлык белән, әмма шул ук вакытта тулы итеп тасвирланган кеше образы; аның иҗтимагый-тарихи шартлар формалаштырган характер сыйфатлары, үз-үзен тотышында, эш-хәрәкәтендә, уй-кичерешләрендә, сөйләшендә чагылган эчке дөньясы, аңа гына хас үзенчәлекләре», – дип ассызыклана [Әдәбият белеме..., б. 230]. Чөнки әдип, үз алдына куелган идея-эстетик бурычтан чыгып, характер тудыра, аңарда теге яки бу үзенчәлекле сыйфатларны туплый. Галим, татар әдәбияты белгече Ф. Хатипов әдәби характерны «герой табигатенә, холык-фигыленә хас үзенчәлекле билгеләр җыелмасы» дип ассызыклый [Хатипов, б. 157]. Әдәбияттагы характерны күренекле рус әдәбияты белгече Л. Тимофеев: «Характер – язучы тарафыннан

эстетик нормаларга туры китереп үзгәртелгән, тарихи шартларга тәңгәлләштереп әсәрдә сурәтләнгән кеше тибы, аның үз-үзен тотышы (эш-хәрәкәтләре, фикерләре, кичерешләре)», – дип аңлата [Тимофеев, с. 152].

Әдәби характер турында әйтелгән фикерләрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин: әдәби характер – гомумилек (барлык кешеләрдә дә очрый торган уртак сыйфатлар) һәм индивидуальлек (аерым шәхестә генә чагыла торган үзенчәлекләр) кушылуы, объективлыкның (кеше тормышының социаль-психологик чынбарлыгын прототибы аша күрсәтү) һәм субъективлыкның (авторның прототипка мөнәсәбәтен, бәясен күрсәтү) берләшүе. Димәк, әдәби характер, сәнгатьтә «яңа чынбарлык», реаль кеше тибын гәүдәләндерүче, сәнгатьчә «иҗат ителгән» шәхес буларак, тормышның идеологик ягын сурәтләүче вазифасын башкара.

Әдәби характерны ачуда, әдәбият галимнәре фикеренчә, тышкы, эчке, сюжет-композиция ысуллары файдаланыла. Тышкы ысул белән әдәби характер тудырганда автор бәяләмәсе, башка геройларның бәяләмәләре, әйләнә-тирәне, табигатьне, яшәү шартларын тасвирлау, диалог кебек алымнар кулланыла. Автор бәяләмәсе алымы әдәби характерны ачуда аеруча зур роль уйный. Әдәбият галиме М. Бахтин әсәрдә автор бәяләмәсенең әһәмиятен герой характерының һәрбер сыйфатын, тормышында, уй-кичерешләрендә булган һәрбер вакыйганы авторның җентекләп сурәтләвендә күрә [Бахтин, с. 9]. Әдәби характерны ачуда башка геройлар бәяләмәсе алымы, С. Остудина фикеренчә, геройның характер сыйфатларын аңларга булышып кына калмый, шулай ук бәяләмә бирүче герой характерын ачарга да ярдәм итә [Остудина, с. 43].

Эчке монолог, аң агышы, фикер, тойгы, омтылыш, кичереш, герой сөйләме, көндәлек, хат, әдәби детальләр кебек алымнар да әдәби характерны ачуда мөһим роль уйныйлар. Аң агышы алымының әдәби характерны ачудагы үзенчәлегенә игътибар итеп, В. Пэшко бу алымның әһәмиятен геройның рухи байлыгын ачуында саный. Аның фикеренчә, аң агышы алымы бу вакытта геройның психологик халәте көзгесе ролен үти [Пэшко, с. 45].

Әдәби характерны формалаштыруда сюжет сызыкларын, экспозицион материалларны, геройларның эш-гамәлләрен ачыклау кебек алымнар әһәмиятле урын алып торалар. Алар сюжет сызыгында характерны башлангыч ноктасыннан алып китеп, нинди карашларда, нинди сәбәп-йогынтылар тәэсирендә формалашуын тасвирлап бирүгә һәм формалашкан характерларны ачыклауга ярдәм итәләр.

Экспозицион материал әдәби характерны ачуда да зур роль уйный. Чөнки ул укучыны герой белән таныштырып, танышудан беренче тәэсир тудыруга булыша. Әдәбият галимәсе Л. Гинзбург укучыны беренче мәртәбә герой белән таныштыруны «әсәрнең алдагы төзелешен оештырырга юнәлдерелгән индекс» дип атый

[Гинзбург, с. 35]. Шулай итеп, *характер* төшенчәсе төрлечә ачылса да, төп вазифасы бер үк булып кала.

Матур әдәбият дөньяны танып белү, кешеләргә тормышны аңлатып бирү, идея-рухи яктан тәрбияләү максатына хезмәт итә, тормышны сурәтләр ярдәмендә чагылдыра. Ул кешеләрнең иҗтимагый тормышын да, шулай ук аларны чолгап алган табигать күренешләрен дә милли, «җирле» формада гәүдәләндерә. Рус язучысы Н.Г. Чернышевский моны түбәндәгечә аңлата: «Әгәр дә әсәрдә хәрәкәт итүче персонажлар милли яктан характерланмыйлар икән, алар чынбарлыктан һәм дөреслектән ерак торалар булып чыга» [Чернышевский, с. 129].

Әдәбиятта әдәби характер милли характер проблемасын ача. Чөнки матур әдәбиятта әдәби характерның милли сыйфатлары, фәнни яктан өйрәнүгә караганда, тирәнрәк һәм күпкырлырак итеп сурәтләнә. Бу – образларны үсештә һәм тарихи-социаль контекстта тикшерергә, матур әдәбиятта милли типларның күптөрлелеген, аларның сыйнфый табигатен һәм тарихи үсешен күрергә ярдәм итә. Әдәбиятта милли характер кешенең эчке дөньясын, аның объектив чынбарлыгын, кешеләр һәм җәмгыять белән үзара мөнәсәбәтен ача.

Матур әдәбиятта милли характер – язучының дөньяга карашын, реалистик һәм эстетик критерийлар күзлегеннән объектив чынбарлыкны образлы эмоциональ чагылдыруы. Әдәбиятта милли характер икегә бүленеп карала: сәнгать әсәре героеның милли характеры һәм сәнгати образлар тудыручының милли характеры. Сәнгать әсәре героеның милли характеры – милли чынбарлык үзенчәлегенең турыдан-туры чагылышы. Ул геройның хисләрендә, уйларында, мәнфәгатьләрендә һәм конкрет эшләрендә чагылып, аны иҗат итүче әдип тарафыннан тудырыла.

Милли характерның асылы табигый-климатик һәм биологик-соматик факторлар йогынтысында тарихи, социаль-икътисади һәм рухи үсеш юлында формалашкан милләтнең типик ныклы сыйфатлары җыелмасы буларак ачыла. Ул милләтнең рухын һәм үзенчәлеген, аның менталитетын, гадәтләрен, зәвыгын күрсәтә, Милли характер үз-үзеңне тотуда, шәхси аралашуларда, традицияләрдә, гореф-гадәтләрдә һәм тормыш образында күренә.

Милли характерны өйрәнгәндә рухи дөньяның кешелеккне гасырлар дәвамында уйландырып килгән әхлакый-фәлсәфи һәм социаль проблемалары игътибарга алына. Әхлакый-фәлсәфи проблемалар матур әдәбиятта чагылыш таба. Матур әдәбиятта милли характер җәмгыятьнең тарихи вакыт эчендәге үсеше һәм милли тарих белән бәйләнеше аша сурәтләнә. Рус әдәбият белгече Н. Воробьева да үзенең хезмәтендә әдипнең, үзе яшәгән һәм иҗат иткән милли эстетик дөнья күзлегеннән чыгып, милли характерны сурәтләвенә тукталып китә [Воробьева, с. 162–185]. Матур әдәбият, геройны конкрет эшләрендә һәм

гамәлләрендә сурәтләп, үз тарихының төрле этапларында үзгәрүен күзәтеп, милли характерны ныклап өйрәнергә мөмкинлек бирә. Милли характерны сәнгать әсәрләрендә сурәтләү халыкка үзенең яшәешен аңларга булыша.

Әдәби әсәрләрдәге милли характер аерым кеше шәхесен сурәтли, аның үзенчәлеген, психикасын, дөньяга карашын күрсәтә. Милли характер шәхеснең эчке психологик дөньясында, аерым сыйфатлар җыелмасында чагыла. Милли характерның асылы күпкырлы һәм күптөрле, шуңа да ул һәрбер чорда яңача ачыла.

Халыкның әхлакый сыйфатлары, намусы, яшәү рәвеше, күркәм традицияләре, гореф-гадәтләре аның әдәбиятында тупланып килә. Әхлакый-фәлсәфи проблемалар матур әдәбиятта чагылыш табуга игътибар итеп, милли характерның асылын, төзелешен, үзенчәлеген матур әдәбият мисалында тикшердек. Матур әдәбият дөньяны танып белү, кешеләргә тормышны аңлатып бирү, идея-рухи яктан тәрбияләү максатына хезмәт итә, тормышны сурәтләр ярдәмендә чагылдыра. Әхлакый-фәлсәфи проблемалар матур әдәбиятта геройның һәм әдипнең милли характерлары аша ачыла. Әдәбиятта милли характер кеше һәм җәмгыять белән үзара мөнәсәбәтен ачып, кешенең эчке дөньясын, аның объектив чынбарлыгын яктырта.

**Әдәбият**


Әдәбият белеме сүзлеге / төз А. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 239 б.

*Бахтин М.М.* Эстетика словесного творчества. М.: Искусства, 1986. 445 с.

*Воробьева Н.Н.* Принцип историзма в изображении характера: классическая традиция и советская литература. М.: Наука, 1978. 264 с.

*Гинзбург Л.Я.* О литературном герое. Л., 1979. 222 с.

*Остудина С.В.* Особенности построения характера в романе Г. Бёлля «Групповой портрет с дамой» // Проблема характера в зарубежных литературах. Свердловск, 1992. С. 43–53.

*Пэшко В.Е.* Взаимохарактеристики и внутренняя речь как характерологические средства // Проблема характера в зарубежных литературах. Свердловск, 1985. С. 43–45.

*Тимофеев Л.И.* Основы теории литературы. М.: Просвещение, 1976. 448 с.

*Хатипов Ф.М.* Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студ. өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2000. 351 б.

*Чернышевский Н.Г.* Полное собрание сочинений: в 15 т. Т. 12. М.: Гослитиздат, 1949. 700 с.



***Сафина Алия Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 398.34

*Г.М. Сөнгатов,*
*Ф.Х. Җәүһәрова,*
*А.Д. Батталова*

# ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ (ТЕЛӘКЛӘР, ӘЗЕР ҖАВАПЛАР, СЫНАМЫШЛАР ҺӘМ ЫШАНУЛАР) ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ ҺӘМ КОШЛАР БЕЛӘН БӘЙЛЕ КҮЗАЛЛАУЛАРНЫ ГӘҮДӘЛӘНДЕРҮ

В статье анализируются образцы татарских благопожеланий, примет и ряд текстов, связанных с верованиями. При отборе текстового корпуса авторы уделили внимание только на тех, которые в той или иной степени отражают скотоводческие и птецеводческие традиции народа. По результатам анализа пришли к следующим выводам: в исследуемых жанрах татарского фольклора образцов, связанных со скотоводческими традициями, достаточно много и они дают возможность судить о ментальных особенностях народа по отношению к тому или иному домашнему животному, птице и их разведению.

**Ключевые слова:** скотоводческие традиции, приметы, верования, благопожелания, ментальность, система питания, средство передвижения.

Фольклорның күп жанрлары халыкның үткәнен, мәдәнияте тарихын өйрәнүдә кыйммәтле чыганак булып саналалар. Без тикшеренү объекты итеп алган теләкләр, әзер җаваплар, сынамышлар һәм ышанулар билгеле бер дәрәҗәдә татар халкының матди мәдәнияте хакында да фикер йөртергә өлеш кертә алалар. Аларда кешеләрнең борынгыдан тупланган тәҗрибәсе, ышанулары, өмет-хыяллары чагылыш таба һәм тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре, хуҗалык итү рәвешләре дә гәүдәләндерелә.

Халыкларның дини ышануларында да хайваннарның роле гаять зур һәм төрле була. Алар Алланың юлдашы яки ярдәмчесе санала, күп халыклар үзләренең килеп чыгу тарихларын да хайваннарга барып тоташа дип саныйлар. Борынгы тотемизм – ыруг яки кабиләнең билгеле җанвардан яки коштан барлыкка килгәнлегенә ышану, аннан табыну культы ясау кешенең үзен табигатьтән, беренче чиратта хайваннар дөньясыннан аерып карамавы белән аңлатыла [Соколова, с. 202]. Галимнәр мал-туарның иминлеген явыз күзләрдән саклау, үрчемлелеген киметмәү гамәлләре системасының нигезендә мифологик ышанулар ятуын күрсәтәләр [Җәүһәрова, б. 50].

Төрки телләрдәге йорт хайваннары атамалары бүгенгә кадәр бик аз фонетик үзгәрешләр кичергәннәр. Төркиләр тормышында терлекләрнең зур урын тотуы аларга караган яшь, җенес, нәсел-токым белдерүче терминологиянең нык үсүенә китергән [Щербак, с. 5]. Этимологик анализга нигезләнеп, А.М. Щербак ат, сыер, куй, кәҗә исемнәре һәм

шушы төр хайваннарның тематик төркемнәренә караган атамалар нигездә төрки чыгышлы дип күрсәтә [Щербак, с. 159]. Р.Г. Әхмәтьянов ат асраучылык терминнарын тарихи-семантик яссылыкта тикшерә, төрки чыгышлы кайбер сүзләрнең монгол, бурят һәм калмык телләрендәге охшаш нигезләрен ачыклый. Галим күрсәтүенчә, татар телендә атны төсенә карап аера торган кырыктан артык сүз бар [Ахметьянов, с. 70]. З.Р. Садыйкованың «Татар теленең зоонимик лексикасы» исемле хезмәтендә татар әдәби телендәге һәм сөйләшләрдәге хайван исемнәрен белдергән күп материал тупланып анализлана [Садыкова, с .16].

Йорт хайваннары тоту төркитатарларга электән хас булган һәм әлеге тармак белән матди мәдәниятнең шактый зур өлкәләре бәйләнгән. Кышкы һәм җәйге киемнәр әзерләүдә, азыктөлекнең күп өлешен җитештерүдә һәм туклануда төп өлешне терлекчелек продуктлары алып торган һәм шунлыктан шактый этнографик үзенчәлекләр туугa да сәбәп булган. Ир-егетләрнең җыелмасын, күплеген белдерү өчен *ир-ат* сүзе кулланылу үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Татар халкында атның ирнең канаты булуын ачып биргән мәкаль-әйтемнәр дә шактый. Сыер һәм кәҗә-сарык исә (керәшеннәрдә дуңгыз да) – беренче чиратта азык-төлек, җылы кием чыганагы.

Терлекчелек күчмә чорда төркиләрнең төп кәсебе булган кебек, утрак тормышка күчкән татарларның да иң төп хуҗалык итү тармакларының берсе булып калган. Ат, сыер, сарык һәм кәҗә асрау бар төбәкләрдә дә табигый шартлар мөмкинлек биргән дәрәҗәдә киң үсеш алган. Татар кешесе, көндәлек тормышы мал-туар белән тыгыз бәйләнгәнлектән, табигать күренешләренә игътибар иткән кебек үк, хайваннарга да сынап караган, холыкларын күзәткән, аларның кәефе һәм үз-үзләрен тотышы үзгәрүгә карап, һава шартларының нинди булачагы, хәтта тормыш-көнкүрештә туачак вакыйгалар турында да нәтиҗәләр чыгарган. Мал асрау күптөрле һөнәр-кәсепләр тууга да китергән: ит, йон сату, тире иләү, бәйләү-тегүчелек, итек басу, мал-туар көтү, хайваннарны дәвалау, ит-сөт ризыклары пешерү кебек эш төрләре мәкаль-әйтемнәр, ырымнар, ышанулар, сынамышлар һ.б. жанрга караган әсәрләр тууга сәбәпче булган.

Галимнәр халык иҗатындагы кайбер афористик жанрлар арасында магик функцияне күздә тотып иҗат ителгәннәре булуын күрсәтәләр. Шундый жанрлардан *теләкләр* сүзнең тылсым ярдәмендә табигать көчләренә, авыруларга, дус-дошман кешеләргә тәэсир итү чарасы буларак карала [Мәхмүтов, б. 31]. Теләкләрне алкышлар һәм каргышлар дигән төркемнәргә аералар. Алкышлар – изге теләкләр. Алкышлар кеше тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар вакытында, шатлык-куаныч килгәндә, уңышка ирешкәндә һәм башка шундый очракларда хуплау, теләктәшлек йөзеннән әйтеләләр. Каргышлар – дошман тарафка

адресланган яман теләкләр, шулай ук каршы якның каргышын үзенә кайтару өчен әйтелә торган сүзләр [Мәхмүтов, б. 31].

«Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр» (1987) җыентыгында урын алган теләкләр арасында йорт хайваннарына бәйле сүзләр кулланылганнары күп түгел. *Мал* сүзе *өстәүле мал булсын* (малыгыз артып торсын мәгънәсендә) [Татар халык иҗаты, б. 480] һәм *малыма килсә килсен, башыма килмәсен* (бәла-каза турында) [Татар халык иҗаты, б. 479] дигән алкышларда очрый. Әлеге сүзнең хайван, терлекне генә түгел, гомумән байлык, мөлкәтне белдерүен дә искәртергә кирәк. Татар халык мәкальләрендә исә *мал* сүзе иң киң кулланылышлы гарәп-фарсы сүзләре рәтендә өченче урында тора – 932 тапкыр очрый [Федорова, с. 237]. Терлекчелек продуктлары – ит, май, сөт кебек сүзләр дә изге теләкләрдә урын ала. Мәсәлән, *юлың ак сөттәй булсын* [Татар халык иҗаты, б. 480] дигән теләкне юлга чыгучы кешегә сөт эчергәндә әйткәннәр [Татар халык иҗаты, б. 562]. Түбәндәге теләкләр яшь килен тарафына яңгыраган дип уйларга кирәк: *балдан рәхим итегез, майдан авыз итегез, дөньяда балдай татлы, майдай тук булып гомер итегез; бер кулың майда, бер кулың балда булсын; бәхетле булсын, итләр пешсен, май кайнасын* [Татар халык иҗаты, б. 478] дигән алкышны яңа мичне беренче якканда май сибеп әйткәннәр [Татар халык иҗаты, б. 562]. Ак майдан эретеп ясала торган *сары май* атамасы изге теләктә *(армый эшләгез, сары май тешләгез!)* [Татар халык иҗаты, б. 478] һәм бер антта *(ялганласам җаным кабыргама килсен, сары май тамагыма тыгылсын)* [Татар халык иҗаты, б. 482] теркәлгән.

Әзер җаваплар яки тапкыр җаваплар, шаян җаваплар дип йөртелә торган афористик жанрда йорт хайваннары атамалары еш кына аваз ягыннан охшашланып кулланылалар. Әзер җаваплар гадәттә ритмлы һәм рифмалы булалар, алар сөйләмгә җорлык, тапкырлык бирәләр [Мәхмүтов, б. 32]. Мәсәлән, кем тарафыннан да булса әйтелгән *оят* сүзенә каршы аңа аваздаш *өй-ат* сүзләре парлашып та, аерым да, пауза белән дә бүленеп, каршы кую интонациясе белән дә әйтелергә мөмкиннәр:

*– Оят! – Өй ат булса, күптән җигеп китәр идек;*

*– Оят! – Өй-ат Мәкәрҗәдә кыйбат, барып алырга ерак;*

*– Оят! – Өй – ат, сыер – келәт* [Татар халык иҗаты, б. 487].

Сорауга җавап рәвешендә әйтелгән әзер җавапларда башка йорт хайваннары исемнәре дә шактый очрый. Мәсәлән:

*– Бушлаймы? – Бушлай сыер гына мышный* [Татар халык иҗаты, б. 478].

*– Кая бардың? – Эт туена кода булып бардым* [Татар халык иҗаты, б. 485]. Юкны бушка аударып йөргән кеше авызыннан җаваплана.

*– Бер казанга ике тәкә башы сыямы? – Мөгезсез булса сыя, мөгезле булса сыймый* [Татар халык иҗаты, б. 486].

– *Нишлисең? – Дуңгыз дагалыйм* [Татар халык иҗаты, б. 485]. Юк эш белән шөгыльләнүне аңлата.

– *Кайчан? – Бозау агачка арты белән менгәндә* [шунда ук]. Беркайчан да булмаячак эш турында әйтелә. Шул ук мәгънәне хайван атамасы кулланылган башка бер әзер җавап та белдерә:

– *Кайчан? – Карт алаша тай булганда* [шунда ук].

Татар фольклорында йорт хайваннары төп персонаж булган үзенчәлекле жанрларның берсе – сынамышлар. Алар «киләчәктә һава хәлләренең, ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш уңышының ничек булачагы хакында алдан ук хәбәр бирү максатына хезмәт итәләр» [Мәхмүтов, б. 29]. Халык хәтерендә беркетелеп, күпьеллык тәҗрибәләрне саклый һәм яшь буынга тапшыра килгән сынамышларда татарның тормыш алып баруында төп көч булган атны күзәтүе, сыер, кәҗә, сарыкларның һәм йорт кошларының үз-үзләрен тотышларына карап һава торышын билгеләве, ел фасылларының нинди булачагын фаразлау һ.б. чагылыш таба. Бер төркем сынамышларда гомумән хайваннар турында сүз бара. Мәсәлән: *юеш, яңгыр, былчырак буласы булса, хайваннар тик тормый; яз көне хайван аяк эзләре эресә, җылытыр* [Татар халык иҗаты, б. 503]; *яз көне терлекләр башлап көтүгә чыкканда авызларына үлән яки тамыр кабып кайтсалар, терлекләргә ул җәй азык начар булыр* [Татар халык иҗаты, б. 512].

Ир-атның тугры юлдашы булган ат, беренчедән, йорт-хуҗалыктагы барлык эшләрне җигелеп тартучы хайван. Сукалау-тырмалау, чәчү-уру, көлтә ташу, печән һәм утын, су алып кайту – һәммәсе дә аның ярдәмендә башкарылган. Сабантуйлар өчен чабышкылар әзерләү, җиңелгә җигәргә яхшы атлар тоту да хәллерәк татарларга хас күренеш булган. Тагын да элегәк исә атның иң төп вазифасы яуда катнашу булган. Атның үзен төрле рәвештә тынычсыз тотуын халык гадәттә яңгырга юраган. Мәсәлән: *ат аягын тибенсә, яңгыр булыр; ат борынын тарта: бу көннәр явым булыр; ат көтүдә яки кырда йөргәндә үзлегеннән суга керсә, яңгыр булыр; ат пошкырынса, искәнсә, яңгыр булыр; иртән көтүдә атлар тыпырчынып, тибенгәләп торса, ул көн яңгыр була* [Татар халык иҗаты, б. 500]. Атка бәйле сынамышлар арасында көннең җылы яки буранлы булачагын хәбәр итә торганнары да бар: *ат юлга ятса, буран булыр; ат ятып торса, җылы булыр* [Татар халык иҗаты, б. 500]; *әгәр ат торганда арт аягы белән типкәләсә, һава җылыныр* [Татар халык иҗаты, б. 503].

Йорт хайваннарыннан сыер, үгез, сарык, дуңгызны күзәтеп барлыкка килгән сынамышларга мисаллар: *өлкәр җиргә төшкәндә, сыер суга төшә.* Өлкәр – Үгезбозау йолдызлыгындагы Иләк йолдыз төркеменең халыкча исеме [Татар халык иҗаты, б. 495]. Өлкәр горизонтта торган чакта бик эссе булып, көндезләрен сыерларның кызулыкка чыдый алмыйча суга кереп ятулары күздә тотыла [Татар халык иҗаты,

б. 563]; *сыер арт аягын калтыратса, салкын булыр; сыер сауганда сөт шаулап күбекләнсә, яңгыр булыр; сыер сауганда җилененең имчәк очы салкын булса, көн суытырга булыр* [Татар халык иҗаты, б. 502]; *үгез төш ягына таба борынын сузып торса, һәмишә ялангаласа, яңгыр булыр* [Татар халык иҗаты, б. 504]; *көн, һава яхшы буласы булса, сарыклар сикерешеп чабалар* [Татар халык иҗаты, б. 501]; *чучка авызына печән тешләсә, салкын була; яңгыр буласы булса, дуңгызлар чыркылдаша* [Татар халык иҗаты, б. 503] һ.б. Татар халкының сынамышлары арасында эт белән мәченең табигатенә нигезләнеп барлыкка килгәннәре дә шактый. Мәсәлән: *эт абзарда ятса, көн суытыр; эт аунаса: кышын – буран, җәен – тузан, җил була* [Татар халык иҗаты, б. 503]; *мәче битен бик озак юынса – озак яңгыр булыр; бик бөгәрләнеп ятса – суык булыр, стенаны тырнаса – һава бозылыр; песи мич башына менеп ятса – суык, идәнгә, җиргә ятса – җылы буласы* [Татар халык иҗаты, б. 502] һ.б.

Татар кешесе үз каралтысындагы йорт кошларының үз-үзләрен тотышларын да күзәткән, аларга карап гадәттә көннең, елның ничек булачагын фаразлаган. Мисаллар: *каз аягын күтәреп торса, салкын була; казлар суда чумып-чумып уйнаса, яңгыр була* [Татар халык иҗаты, б. 501]; *үрдәк коенса, салкын булыр; үрдәкләр суда кагынып кычкырсалар – яңгырга. Әгәр суда шыпырт кына торсалар – яшен булыр* [Татар халык иҗаты, б. 504]; *яңгыр алдыннан күркәләр җирдә аунар, кагыныр* [Татар халык иҗаты, б. 503]; *әтәч каралты арасына кереп кычкырса – һава бозылыр, югары урынга менеп кычкырса – аяз булыр; өйлә вакытында әтәч кычкырса, көн алышына* [Татар халык иҗаты, 504]; *әтәчләр өзлексез кычкырсалар, ашлык уңар* [Татар халык иҗаты, б. 512]; *сентябрь башларында тавыклар каурыйларын коя башласалар, ел суык була; тавык бер аяк белән басып торса, өй түбәсенә очып менсә – суык булыр* [Татар халык иҗаты, б. 502] һ.б.

Алдан нәрсә булачагын әйтү, юрау ягыннан сынамышларга якын торган ышануларда да төрле эш-хәлләр, вакыйгалар йорт хайваннарының үз-үзләрен тотышлары үзгәрүе белән бәйләп карала. Ышануларның эчтәлеге, еш кына, халыкның борынгы үткәненә, аның иске гореф-гадәтләренә, йола-ритуалларына барып бәйләнә. «...ышанулар тылсым, магия белән белән тыгыз үрелгәннәр» [Мәхмүтов, б. 30]. Шуннан чыгып, галимнәр аларны хорафатларга нигезләнгән жанр дип тә күрсәтәләр, шул ук вакытта ышануларның халык күңеленең көзгесе булуын, халыкның уй-теләкләрен, хыялөметләрен, шатлык-куанычларын гәүдәләндерүче әсәрләр икәнлеген дә әйтәләр [шунда ук].

Татар халкында ир-атның күкрәге, аяк-кулы йонлы булса, аңа бәхет билгесе итеп карау булган. Әйтик, *төкле аягың белән!* дигән теләктә балтыры йонлач кеше килгәч, өй, гаилә бәхетле булыр дигән ышаныч чагылыш

тапкан. *Аягы йонлы – мал-туардан бәхетле булыр* [Татар халык иҗаты, б. 485] дигән ышану да нәкъ шундый тәҗрибә-күзәтүне чагылдыра.

Кайбер ышануларда абзар иясенең холкы һәм гамәлләре сурәтләнә. Әйтик, аның яраткан һәм яратмаган хайваннары була: *абзар иясе яраткан атларының ялын үрә; кура* (абзар) *иясе атны яратмаса, атланып йөреп атны тирләтеп бетерә, кыйный, ашатмый икән* [Татар халык иҗаты, б. 514].

Ишек өстенә яки ишеккә ат дагасы кадаклап кую татарларда гына түгел, башка халыкларда да таралган. «Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр» китабында моңа караган ышануның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фольклор фондыннан алынган түбәндәге варианты теркәлгән: *ишек астына ат дагасы кадаклап куялар. Шулай иткәндә аяк арасыннан өйгә шайтан керми, ди* [Татар халык иҗаты, б. 514].

Ышану-ырауларның бер өлеше хәвеф-хәтәрне кисәтү, кешене саклыкка-уяулыкка чакыру һәм чисталыкка, тәрбиялелеккә чакыру чарасы да булып тора: *хайван сатканда йонын йолкып калырга кирәк: токымы китмәсен дип* [Татар халык иҗаты, б. 517]; *тәрәзәдән сөяк ташлама – өйгә яшен керер* [Татар халык иҗаты, б. 515]; *сөтне кояш баегач бирергә ярамый – сыерның сөте кими* [Татар халык иҗаты, б. 517]; *ерак юлга чыкканда ат тугарылса, юлда зыян килә* [Татар халык иҗаты, б. 516]. Ахыргы мисал юлга чыгар алдыннан яхшылап, игътибар һәм төгәллек белән әзерләнергә куша.

Сынамышлардагы кебек үк, ышануларда да эт-мәченең холкы үзгәрүенә, үзен ничек тотуына карап булачак хәлләрне, һава торышын юрау киң таралган. Мәсәлән: *йортта эт җир казыса – мәет, чикерткә сызгырса – янгын, таракан качса – ачлык* [Татар халык иҗаты, б. 516]; *эт уласа, бәхетсезлек була* [Татар халык иҗаты, б. 517]; *авылда янгын булса, йорттагы мәчене карарга кирәк: әгәр янгын йортка килмәс булса, мәче тыныч кына утырыр. Әгәр куркыныч киләсе булса – мәче чыгып качар* [Татар халык иҗаты, б. 516]; *әгәр мәче ишек тупсасына утырып битен юса – кунак килә. Әгәр икенче урынга күчереп куйгач та битен юуны дәвам итсә – куна килә* [Татар халык иҗаты, б. 517].

Татар кешесе электән каз асрарга яраткан, каз күп булу йортта муллык, байлык билгесе булып саналган. Шунлыктан, каз бәпкәләре күп чыксын дип һәм исән-сау үссеннәр өчен, халык төрле ышану-ырымнарга таянып төрле йолалар башкарган. Мисаллар: *каз бәпкәләре чыккач, йомырка кабыкларын озын чыбыкка тезеп чорма кыегына кыстырып куялар: бәпкәләр югалмый; каз йомырка өстендә утырган вакытта киек казлар килгәнне күргәч, каз оясына бер уч салам кертеп салалар: бәпкәләр киек казлар шикелле тезелеп, күп булып чыга; каз өмәсеннән чыгып киткәндә тастымалны хуҗа башына салып чыксаң, киләсе елга каз күп*

*уңа имеш* [Татар халык иҗаты, б. 516]; *төнлә туган кешегә – кара каз, көндез туган кешегә – ак каз, таң алдында туган кешегә – ала каз адарыналар: шулай төсләре туры килгәндә генә казлар үрчи имеш* [Татар халык иҗаты, б. 517] һ.б.

Югарыда тикшерү өчен алынган мисаллар – күптәннән халык телендә йөргән һәм язып алынган ядкәрләр. Күп төбәкләрдә йорт хайваннары тоту кими барганлыктан, әлеге жанрлар малтуарга, терлекчелеккә караган материаллар белән тагын да тулыланыр, баер дип фаразлап булмый. Бу юнәлештәге фольклор-лингвистик эшчәнлекне киңрәк җәелдерү өчен, язма мирасыбызга мөрәҗәгать итү, төрле фондлар һәм архивлар тупланмаларын өйрәнү, экспедицияләрдә максатчан материал җыйнау кирәк булачак.

*Мәкалә Россия фундаменталь тикшеренүләр фонды (РФФИ) финанс ярдәме белән һәм Татарстан Республикасының 17-14-16021 номерлы фәнни проеты кысаларында нәшер ителә.*

**Әдәбият**

*Ахметьянов Р.Г.* Некоторые названия лошадей в татарском языке // Советская тюркология. 1975. № 2. С. 69–76.

*Җәүһәрова Ф.Х.* Татарларда мал тоту традициясенә бәйле мифологик күзаллаулар // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. Казан: Ихлас, 2012. 7 китап. Б. 50–52.

*Мәхмүтов Х.Ш.* Татар халкының афористик иҗаты // Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 5–36.

*Садыкова З.Р.* Зоонимическая лексика татарского языка. Казань, Татар. кн. изд-во, 1994. 130 с.

*Соколова З.П.* Культ животных в религиях. М.: Наука, 1972. 215 с.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 592 б.

*Федорова Э.Н.* Татар халык мәкальләрендә гарәп һәм фарсы алынмалары. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2004. 249 б.

*Щербак А.М.* Названия домашних и диких животных в тюркских языках // Историческое развитие лексики тюркских языков. М.: Изд-во АН СССР, 1961. С. 82

***Сөнгатов Гафур Мәсгут улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фәнни хезмәткәре*

***Җәүһәрова Фәнзилә Хәким кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге җитәкчесе*

***Батталова Алсу Дамир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 82.512.1-131:398.22

***Л.Х. Мөхәммәтҗанова,***
***Г.Р. Хөсәенова***

# ТАТАР ЭПОСЫНДА РОМАНИК ТӨР ДАСТАННАР

Статья посвящена теме взаимосвязи между национальным историко-культурным процессом и жанровыми особенностями словесного творчества татар. Авторы апробируют термин «романический» по отношению к стадиально новому эпосу – дастанам с любовной тематикой, популярных среди татар вплоть до начала XX в., поднимают вопрос о необходимости выявления места и роли татарских романических дастанов в системе фольклорных и литературных жанров.

**Ключевые слова**: дастан, романический, тематический, фольклор, литература, сюжет, жанровая разновидность, традиционный.

Татар халкы гомер-гомергә китаплы халык булган. Язу культурасына, күп гасырлык бай язма мираска ия булуы аның фольклорына да тәэсир итми калмаган. Иң беренче чиратта нәкъ менә шушы сәбәп татар халкында дастан жанрының язма иҗат булып формалашуын тәэмин иткән. Мондый дастаннар шул ук фольклор традицияләрен язмада дәвам итүләре, Идел буе татарларына хас җирле эпик үзенчәлекләр белән бергә, башка халыклар рухи мирасын гасырлар буе саклап килеп, безнең көннәргә китереп җиткерүләре белән кыйммәт.

Вариантларының күплеге, актив таралышы һәм халык арасында яратып укылуы җәһәтеннән татар дастаннары арасында романик характердагылары әһәмиятле урын алып тора. Болар – Таһир белән Зөһрә, Йосыф, Сәйфелмөлек, Ләйлә белән Мәҗнүн, Шаһсанәм һәм Гариб, Бүз егет һ.б. турындагы мәшһүр сюжетларга иҗат ителгән әсәрләр. Мондый истәлекләрнең үз чорында гаять популярлыгын эмоциональ-маҗаралы әсәрләргә халыкта заманына күрә зур ихтыяҗ булу белән аңлатырга мөмкин.

Романик дастан борынгы төрки һәм фарсы әдәбиятындагы атаклы поэмалар белән тыгыз бәйләнгән. Башкача әйткәндә, бу – индивидуаль язма иҗат, әдәбият белән үтә җитди керешкән өлкә. Фольклорның башка жанрлары (әйтик: миф, әкият, бәет, мөнәҗәт, риваять, афористик һәм йола фольклоры) янәшәсендә дастан жанрының төп хасияте дә нәкъ менә шунда. Татарларда мондый әсәрләр – Урта гасырлардан Яңа чорга күчү чорыннан алып, XX гасыр башынача дәвердә язма әдәбият составындагы иң продуктив иҗат төре.

Урта гасырлар иҗат методы бер үк сюжетның төрле милли версиядә эпик әсәрләр буып таралуын тәэмин иткән. Шушындый «күчмә» сюжетлар, әлбәттә, Идел буе татарларына да килеп җиткән. Алар биредә җирле

традицияләргә туры килә торган яңа яңгыраш алганнар, әдәбимәдәни процесска фольклор стилендә кушылып киткәннәр. Идел буе татарларында дастаннар кулъязмалар рәвешендә дә таратылганнар, халыкта сөйләмә формада да билгеле булганнар, басма китап дәверендә исә алар аерым китаплар булып та басылып чыкканнар.

XVII йөз урталарыннан соң, сәяси вазгыятьнең кырысланып яки йомшарып китүенә бәйле рәвештә, романик характердагы дастаннар халык тарафыннан яратып укылган. Татар романик дастаннары нигездә авторыкүчерүчесенең исеме белән йөри. Романик дастаннар – татар эпосының язма фольклор традициясеннән индивидуаль авторлыкның аерылып чыгу этабын да күпмедер дәрәҗәдә үз эченә алган стадиаль иң соңгы төре.

Романик китаби дастаннар белән Борынгы һәм Урта гасыр әдәби әсәрләре һәм шул ук сюжетка корылган традицион (көйсүз әйтеп башкарыла торган) эпик текст арасында төгәл чикне билгеләү гаять авыр. Иҗатка хирыс шәхесләр мәгълүм сюжетларга, дастаннар язу белән бергә, оригиналь әсәрләр иҗат итү белән дә шөгыльләнгәннәр. Мәсәлән, татар шагыйре Әхмәтҗан Тубылиның, йөзләгән шигырь һәм дини-фәлсәфи характердагы прозаик әсәрләр авторы булуы белән бергә, мәгълүм сюжетларга дастаннар да иҗат иткәнлеген беләбез. Мондый төр иҗат белән шөгыльләнүчеләр каләмендә фольклор стиле гадәттә үтә җиңеллек белән әдәби традицияләргә үрелеп китә, шуңа да романик дастаннар дигәндә аларга гына хас чик сызыгын тотып алу һәм аерып чыгару җиңел эш түгел.

Мәхәббәт темасына язылган, берничә вариантта таралган уртак сюжетлы әсәрләр романик дастаннар төркеменә керә. Бу төркем дастаннар өлешчә шартлы рәвештә «романик» термины белән билгеләнә. Күләме һәм эчтәлеге ягыннан мондый дастаннарның материалы Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятларында барлыкка килгән роман жанрын колачлый, әмма һич тә роман жанрының бөтен хасиятләрен дә сакламый. Роман жанры тематик (автобиографик, хәрби, детектив, документаль, мәхәббәт, интеллектуаль, тарихи, сәяси, маҗаралы, сатирик, сентименталь, иҗтимагый, фантастик, фәлсәфи һ.б.) һәм структур (шигъри роман, роман-памфлет, роман-сага, роман-кыйсса, роман-фельетон, эпистоляр роман һ.б.) яктан шактый күп төркемнәргә бүленсә, романик характердагы дастаннар дип карала торган татар телле әсәрләрнең тематикасы шактый чикле: аларның һәркайсы, гадәттә, бер генә теманы ача – ике гашыйкның мәхәббәт тарихын бәян итә. Бу төр дастаннарны төзелеше белән дә артык катлаулы дип әйтеп булмый. Шул ук вакытта романик дастаннар, роман жанры (тарихи романнардан кала) кебек үк, шәхси тормыш вакыйгаларына нигезләнә, гади кешеләр язмышын тасвирлый. Романик китаби дастаннар бигрәк тә Яңарыш әдәбиятында шәхси тормыш эпосы буларак

мәйданга чыккан романнарга якын торалар, адәм балаларының шәхси омтылышларын, шатлык-кайгыларын, уңыш-фаҗигаләрен тасвирлыйлар.

Яңарыш чоры романында шәхеснең кичерешләре һәм гамәлләре иҗтимагый мотивлаша, чөнки яңа җәмгыятьтә шәхси һәм иҗтимагый тормыш – кеше яшәешенең бер дәрәҗәдәге яклары. Мондый әсәр үзәгенә үзенең аң дәрәҗәсе, үзаңы белән башкалардан аерылып, җәмгыятьнең әдәби сурәтләнештәге хәл-халәте белән каршылыкта торучы шәхес куела. Роман жанрындагы әсәрдә «бер язмышта, бер кеше тормышы мисалында шул чор өчен иң характерлы шартлар әдәби гомумиләштереп тасвирлана, тормышның ниндилеге бер образ итеп җыеп сурәтләнә» [Әдәбият белеме сүзлеге, б. 167]. Роман бүгенге чынбарлыкны якындагы үткән белән бәйли.

Ә романик дип билгеләнгән дастаннарда вакыйгалар һәрвакыт ерак үткәнгә карый, биредә роман жанрына хас тенденциозлык, әсәрдә шәхси тормыш мисалында тормыш-яшәеш мәгънәсен ачарга, яшәү рәвешен чагылдырырга омтылу кебек әдәби концепциянең булуы артык сизелми. Романик китаби дастаннар аерым бер темаларны һәм традицион мотивларны кабатлый, бәхетсез төгәлләнә торган сюжеты белән дә, кайбер геройларның чынбарлыкта яшәгән шәхесләргә барып тоташуы ягыннан да алар гаять мавыктыргыч.

Дастаннарның романик төркемгә карый торганнары, билгеле бер тема-мотивларны үстерүләре һәм текст эчтәлегендә романтик иҗатка хас шәркый кануннар, кайбер эстетик алымнар, бизәклелек кулланылу ягыннан романтизм (нем. *romantic,* фр. *romantisme,* ингл. *romantism*) әдәби юнәлешенең Көнчыгыш романтик иҗат тибына да бик нык якын торалар. Романик дастанарда романтизм иҗат юнәлешенә хас булган кайбер сыйфатлар күзгә чалына, әйтик, хисләр байлыгы, тәэсирлелек, геройны идеаллаштырып сурәтләү, рухи башлангычка өстенлек бирү. Романик дастаннарның әдәбияттагы роман жанры һәм романтизм юнәлешенең икесенә дә берьюлы һәм төрле яклап тартылуы кайвакыт мондый әсәрләргә карата «романтик дастаннар» дигән билгеләмә кулланырга мөмкинлек бирә. Фольклор белән әдәбият арасында торган, халыкта берничә вариантта һәм версиядә таралыш алган, мәхәббәт темасына багышланган уртак сюжетлы дастани әсәрләрне әдәбият һәм фольклор галимнәре романик дастаннар дип тә, романтик дастаннар дип тә атыйлар. Шулай да дастани эпоска бай халыкларда очрый торган мондый төр иҗатка карата «романик дастаннар» дигән термин куллану «романтик дастаннар»га караганда ешрак очрый. Е.М. Мелетинский, П.А. Гринцер, В.М Жирмунский, С.Ю. Неклюдов кебек галимнәр төрле халыкларның мондый категориядәге эпик әсәрләре турында сүз барганда «романик» терминына өстенлек бирәләр [Мелетинский, 1986, с. 141, 143, 145, 167 и др.; Гринцер, с. 3–44;

Жирмунский, с. 19, 643; Неклюдов, с. 251–267].

Тематик принципка һәм романтизм методына хас кайбер сыйфатлары булуга карап, татар дастаннарының мондый төрен романтик дастаннар дип атау хата булмаса да, традиционлык һәм индивидуальлек җәһәтеннән әдәби иҗатка, китапка бик нык якын торулары сәбәпле, мондый әсәрләрнең эчтәлеген «романик» термины төгәлрәк ача кебек, шуңа күрә, атаклы галимнәр фикеренә кушылып, роман жанры чалымнары кергән, идея-эчтәлегендә романтизм юнәлешенең бер агымына хас сыйфатлар чагылыш тапкан, мәхәббәт тематикалы дастаннарны «романик дастаннар» дип атау дөресрәк булыр.

Татар халык иҗатының романик дастаннары төркемендә төп тема, чыннан да, – мәхәббәт. Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әдәбияты традициясендә илаһи мәхәббәткә дан җырлаган әсәрләр татар дастаннарның иң зур өлешен алып тора [Мухаметзянова]. Романик дастаннар һәркайсы диярлек үзләренең чагыштырмача күләмле булулары белән аерыла. Татар романик китаби дастаннарын Урта Азиядә мәгълүм «Рөстәмхан», «Сәят-Хәмра», «Асли-Кәрәм» һ.б. дастаннар кебек саф романик әсәрләр дип әйтеп булмый. Татар телле дастаннар алардан шигъри эшләнешенең күбесенчә тезмә аралаш чәчмә булулары, күләменең чагыштырмача кечкенәлеге, сюжет җепләренең артык катлауланмыйча, бер я берничә сызыктан гына гыйбарәтлеге, төгәл структуралы булулары, милли җирлек чагылыш тапкан сюжет үзенчәлекләре һ.б. сыйфатлары белән аерылып торалар. Идел буе татарлары романик дастаннары нигездә барысы да китап стиленә тартыла. Бу төркем дастаннарда әдәби сюжетлар, әдәбиятның поэтик формалары фольклор стилендә үзләштерелгән. Персонажлар сөйләмендә дә «тере» башкарылуга хас билгеләргә караганда әдәби телгә якын нейтраль тел өстенлек итә.

Идел буе татарлары язма фольклорындагы мәхәббәт дастаннарында, шул ук сюжетка жанрның «тере» традицион төре белән чагыштырганда, әлбәттә, динамикалык, башкарудагы киң диапозон, телдән хикәяләүдә очрый торган пафос инде юылган, шигырь төзелешендә халык стиле буларак кулланылып килгән силлабикага нигезләнү дә бик нык кимүгә йөз тоткан. Романик дастаннарда кайвакыт героика чалымнары да чагылып китә. Әйтик, «Сәйфелмөлек», «Бүз егет», хәтта «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә дә бу ачык күренә. Ә менә атаклы «Түләк», гәрчә ул мәхәббәт дастаны булса да, үзенең архаиклыгы белән һәм алыплар турындагы хикәятләргә охшашлыгы ягыннан күбрәк каһарманлык дастаннары төркеменә якын.

Романик дастаннар, каһарманлык дастаннары кебек үк, төп герой исеме белән аталып йөртеләләр, ягъни әсәр эчтәлеген аның исеме үк әйтеп тора. Төп эчтәлеген мәхәббәт тарихы алып торган романик дастаннар парлы исемнән гыйбарәт: «Таһир белән Зөһрә», «Ләйлә белән Мәҗнүн»,

«Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга һәм Һәмра» һ.б.

Мәхәббәт тарихын бәян итә торган дастаннарыбызның янә бер үзенчәлеге дастан вакыйгаларының фаҗига белән тәмамлануыннан гыйбарәт. Бәхетле кавышу мотивы фәкать «Йосыф китабы»нда һәм «Хурлуга белән Һәмра»да гына сакланган. Башка төрки халыкларда гашыйкларның бергә булулары белән тәгәлләнә торган «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Сәйфелмөлек» кебек дастаннарның татар версиясендә дә әлеге фаҗигале үлем идеясе киң таралган. Романик китаби дастаннарыбызда трагик мәхәббәт тематикасының популярлыгы турыдан-туры борынгы гарәп риваятьләреннән килә. Әйтик, татар халкында «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжеты бик киң таралган булган, мәхәббәт дастаннарының фаҗигале бетеменә бу әсәр зур йогынты ясаган. Шулай ук XIII–XV йөзләрдә төрки халыклар иҗатында киң таралган «Кузы Күрпәч белән Баян-Сылу» дастанының да тәэсире зур булган. Әсәрне трагик ноталарда тәмамлау дастанны тагын да тәэсирлерәк, эмоциональрәк ясаган, шуның белән укучыны ныграк җәлеп иткән. Бу җәһәттән Казан татарлары романик дастаннары, күпмедер дәрәҗәдә, Е.М. Мелетинский тарафыннан Көнчыгыш новеллалары дип билгеләнгән язма истәлекләргә, аерым алганда «Мең дә бер кичә»гә якын тора. Е.М. Мелетинский мәхәббәт темасы өстенлек иткән романик новеллаларда егет-геройның, кагыйдә буларак, бик пассив, самими, әмма үтә намуслы, вөҗданлы, ә кыз-геройның исә актив һәм инициатива күрсәтүчән булуының гомуми планда алга чыгуына игътибарны юнәлтә [Мелетинский, 1990, с. 34]. Татар романик дастаннарында аңлы рәвештә холыкны тасвирлау турында сүз алып барырга бик чикле булса да, һәр заман өчен таныш зыялылык, гомуми олы хисләр пәрдәсе артында геройларны аерым бер сыйфатларыннан танып алырга мөмкин. Татар халык дастаннарында кыз-герой хәтта үзенең зирәклеге, тапкырлыгы, кыюлыгы, сөйгәненә карата демократик холкы белән Көнчыгыш новеллаларыннан, шулай ук дастаннарның Көнчыгыш халыклардагы версияләреннән аерылып тора.

Татар романик дастаннары Көнчыгыш әдәбияты тәэсирендә туганнар һәм озак гасырлар дәвамында шул әдәбият йогынтысында формалашканнар, шул сәбәпле аларда Борынгы һәм Урта гасыр Көнчыгыш әсәрләреннән килә торган консервативлык традицияләре үзен бик нык сиздерә. Боларда заман таләпләрен канәгатьләндерерлек дөньявилык, Европа мәдәниятенә, әдәбиятына, фәненә омтылыш идеяләре бөтенләй юк. Әмма татар әдәбиятын һәм мәдәниятен борынгыдан азыкландырып килгән Шәрык мәдәнияте һәм аның аша романик дастаннарыбызга үтеп кергән идеяләр, стиль-үзенчәлекләр билгеле бер чорга кадәр милләтебезнең табигатенә гаять ярашлы булган. Романик дип билгеләнгән төргә керә торган әсәрләрнең татарларда XX гасыр башынача

популярлыгын шул сәбәп белән аңлатырга мөмкин.

Романик китаби дастаннарның һәркайсында әдәбият кануннары белән фольклор кануннары табигый үрелештә чагылыш таба. Бу төр әсәрләр – гашыйклык дастаны гына түгел, ә «гомумән мәхәббәт, кешенең бөтен барлыгын биләгән олы хис» [Татар халык иҗаты, б. 23] турындагы дастан. Мәхәббәттән дә зуррак көчнең булмавы идеясе романик дастаннарның һәрберсендә үтә җете кызыл җеп булып сузылган. Мондый дастаннар Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятына хас суфичылык идеяләреннән дә азат түгел. Бу төркемгә керә торган дастаннарда китап традицияләре фольклор үзенчәлекләре белән бик тыгыз аралашкан. Татар халкының романик дастаннары Көнчыгыш романтик иҗат методыннан бик күп сыйфатлар алган. Шул ук вакытта бу төр дастаннарыбыз татар әдәбиятында XX йөз башында иҗат методы буларак, роман жанры формалашуга да йогынты ясап, аның үсешендә мәгълүм бер баскыч ролен дә үтәгәннәр. Димәк, романик характердагы дастаннарыбызның татар дастаны үзенчәлекле специфик бөтен барлыкка китерүдә бик зур роль уйнавы бәхәссез.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар халкында Урта гасыр иҗат методы традициясендә әсәрләр язу бик киң таралган була. Бу метод мәгълүм сюжетка корылган мәшһүр бер әсәргә ияреп язу, аны тулысынча яки өлешләп тәрҗемә итү, шул сюжеттан илһам алып, яңа җирлектә өр-яңа әсәр иҗат итү, ул әсәрнең халыкта популярлашып, әллә ничә вариантта таралуы аша туган ядкәрләрдә тормышка ашырылган. Һәрхәлдә татар халкында, аерым алганда Идел буе татарларында, әлеге методның нәкъ менә шундый – чагыштырмача иркен стильдәге юнәлеше өстенлек иткән. Шушы гаять күпкырлы һәм масштаблы күренешнең бер чагылышы булып, татар халык иҗатында «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Таһир белән Зөһрә» кебек популяр дастаннар барлыкка килгән. Халыкта борынгы чорларда ук киң таралыш алган мондый сюжетлар татарларда XX гасыр башынача актив яшәгән. Татар телендә ярым әдәби, ярым фольклор текстларны төзегән иҗатчы-күчерүчеләр китап теленә, китаби гыйбарәләргә һәм образларга мөрәҗәгать иткәннәр, шул рәвешле романик дастаннарда фольклор катыш әдәби стиль ныгыган. Татар романик дастаннары эпик фольклорның зур өлешен алып торуы, әдәби процесста актив катнашуы ягыннан гаять әһәмиятле, махсус өйрәнелергә хаклы өлкә.

**Әдәбият**

*Гринцер П.А.* Две эпохи романа (вводная статья) // Генезис романа в литературах Азии и Африки. Национальные истоки жанра. М.: Наука, 1980. С. 3–44.

Әдәбият белеме сүзлеге. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 163.

*Жирмунский В.М.* Тюркский героический эпос. Л.: Наука, 1974. 728 с.

*Мелетинский Е.М.* Введение в историческую поэтику эпоса и романа. М: Наука, 1986. 320 с.

*Мелетинский Е.М.* Историческая поэтика новеллы. М.: Наука. Главная редакция восточной литературы, 1990. 275 с.

*Мухаметзянова Л.Х.* Тематическая классификация татарского эпоса: романические и героические книжные дастаны // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота. 2014. № 6 (36). Ч. 2. С. 161 – 163.

*Неклюдов С.Ю.* От эпоса к роману // Неклюдов С.Ю. Героический эпос монгольских народов. М.: Наука, 1984. С. 251 – 267.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*
*e-mail: lilmuhat@mail.ru*

***Хөсәенова Гөлнира Рәзиф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге аспиранты*
*e-mail: gulnira2010@yandex.ru*

УДК 297

*З.Р. Хәбибуллина*

# СӘЯХӘТЛӘР АНТРОПОЛОГИЯСЕ ОБЪЕКТЫ БУЛАРАК УРАЛ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ ХАҖ СӘФӘРЕ

В статье с позиций антропологии путешествия рассматривается феномен религиозного паломничества. Главным и незабываемым путешествием, предписанным Кораном, для мусульманина является хадж, или паломничество в Мекку. Несмотря на обязательность хаджа как пятого столпа ислама, верующие считают его путешествием в земном и сакральном пространствах. Для большинства мусульман мира он представляет собой преодоление определенного пути и связан с разного рода трудностями, теологически – это ряд церемоний, которые должны быть выполнены в определенных священных местах. В центре нашего внимания – паломничество мусульман Южного Урала, его место и роль в жизни мусульманского населения региона. На основе полевых материалов, полученных в работе с паломниками, представителями Хадж-миссии России, духовенством и верующими, рассмотрены мотивы, поведенческие схемы современных паломников, культурное значение хаджа, факторы, оказывающие влияние на развитие паломнической традиции местных мусульман.

**Ключевые слова:** антропология, паломничество, путешествие, ислам, хадж, Мекка, Медина, Урал

Сәяхәтләр антропологиясе – илебезнең тарих фәнендә әле яңа юнәлеш, ул дөньяның глобальләшүе һәм XXI гасырда туризмның гадәттән тыш киң таралуы нәтиҗәсендә актуальләшә. Бу юнәлеш хәрәкәт итүнең күптөрлелеген һәм аның эзлекле эшчәнлек схемасы һәм вакыйгалар барышына бәйле эш-гамәлләргә ярашлы рәвештә барлыкка килгән механизмнарын өйрәнүгә нигезләнә. Социаль төркемнәрнең хәрәкәтен тикшереп өйрәнү иҗтимагый аңны һәм ачыкланып җитмәгән уй-фикерләрне (хәрәкәт мотивларын, карар кылу механизмнарын, акция һәм реакцияләрнең үзара нисбәтен) танып белүгә юл ача [Головнев, с. 10]. Кеше сәяхәткә билгеле бер мотивлар белән һәм нәрсәне дә булса күреп өйрәнүне күздә тотып чыга.

География «сәяхәтләр» ландшафт төрлелеген күреп белүгә юнәлдерелә һәм ул ландшафттан, шәхси һәм әһәмиятле уртак нокталарга ия когнитив киңлекләрдән чыгып билгеләнә [Наука странствия…]. Бу билгеләмәгә хаҗ кылу да керә, ул сәфәр кылучыларга изгелек ландшафтына төшенергә ярдәм итә. Бүгенге дөньяда борынгыдан килгән изге урыннарга күмәкләп зиярәт кылу йоласы активлашты һәм ул массакүләм мәдәни күренешкә әверелде. Яңа (XVII гасырдан башлап) һәм Иң яңа заманнарда фәннең көчле үсеш алуы һәм дөнья турында фәнни карашлар йогынтысында традицион дини-мәдәни ландшафтны

юкка чыгарырга омтылу процессы дини йола-тәртипләрнең мөһим бер компоненты саналган хаҗ кылу гадәтен туктата алмады. Изге урыннарга күмәкләп сәфәр кылу, дини функцияләрдән тыш, экзистенциаль пространство формалаштыруда һәм аны билгеле (ягъни аерым кешеләр яки төркемнәр күңелендә тамырланган, әмма аларның һәркайсы өчен генә хас булган мәгънәгә ия) калыпка салуның җитди ысулына әйләнә бара [Замятин, с. 3].

Изге урыннарга сәфәр кылу бөтен диннәрдә бар, исламда ул аерым әһәмияткә ия. Хаҗ кылу һәр мөселман өчен Аллаһ карашындагы фарыз гамәлләрнең бишенчесе (соңгысы) булып санала. Хаҗ сәфәре, исламда мәҗбүри үтәлергә тиешле төп бурычтан тыш, исламның дөньякүләм үсешенә йогынты ясау функциясен дә үти: ул мөселманнарда үз диннәренең тиңсез кодрәтенә инану ихтыяҗын канәгатьләндерә, бу диндәгеләрнең бердәмлеген тормышка ашыру механизмын тәшкил итә. Мөселманнарның ел саен, дөньяның барлык кыйтгаларыннан да килеп, изге Мәккәдә очрашуы аларның рухи, мәдәни элемтәләрен, психологик бердәмлеген, ислам берлегенең социаль тупланганлыгын ныгыта. Исламда чиркәү институтлары да, катгый мәгънәдәге руханилык та юк, шуңа күрә Мәккәгә хаҗ кылуның берләштерү роле көчәя һәм ул мөселманнарның дөньяви өммәтен (җәмгыятен) символлаштыра һәм гәүдәләндерә.

Хаҗ кылуның Мөхәммәд һәм Коръәнгә исеме теркәлгән башка персонажлар тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле төп объектлары Согыд Гарәбстаны Корольлегенең Хиҗаз өлкәсендәге изге шәһәрләрендә урнашкан: Мәккәдә – изге «кара таш» урнаштырылган Кәгъбә, шәһәр читендә Сафа һәм Мәрвә калкулыклары, изге «Зәм-зәм» чишмәсе, Гарәфәт үзәнлегендә Муздалиф җирлеге; Мәдинәдә – Мөхәммәд пәйгамбәр, аның кызы Фатыйма, изге Әбү Бәкер, Гомәр, Госман хәлифәләрнең, Мөхәммәднең хатыны Гайшәнең каберләре, Мөхәммәд мәчете (Пәйгамбәр мәчете). Бу өлкәнең территориясенә туристларга һәм башка диндәгеләргә керү тыела, болардан тыш мөселманнарның үзләренә дә (вакытлы, урынга бәйле, догматик күрсәтмәләре, визасы булмаганнарга) чикләүләр билгеләнгән.

Хиҗазга бару хаҗ кылган очракта гына рөхсәт ителә, бу таләп изге шәһәрләргә нинди дә булса эш белән баручыларга карата да куела. Россиядән хаҗ кылырга баручыларны озатып йөрүче дин эшлекләләре, табиблар, гидлар, хаҗ миссиясе һәм турагентлык вәкилләре һ.б. барысы да, үз вазифаларыннан тыш, хаҗ кылырга тырышалар. Хиҗазда табынуның ике варианты кулланыла: зур хаҗ (яки хаҗ) кытгый бер вакыт кысаларында – ай календареның уникенче ае – зөлхиҗҗәдә; кече хаҗ (өмрә хаҗы) Мәккәдә елның (зур хаҗ көннәреннән кала) теләсә кайсы вакытындда уздырыла. Кече хаҗның йолалары зур хаҗныкыннан аерылмаса да, дин тотучылар өчен аның әһәмияте бик үк югары булмый.

Шәригать кануннары нигезендә хаҗ сәфәренә чыгу өчен мөселманга түбәндәге таләпләр куелган: балигъ булу; үз акылында булу; азат булу (кол түгел); талау, үтерү һ.б. кебек тыелган гамәлләр үтәргә мәҗбүр ителмәү; үз сәфәренә һәм өйдә калган гаилә әгъзаларын матди тәэмин итәргә, хуҗалыкны алып барырга җитәрлек акчасы булу; сау-сәламәт булу; юлда үзенең иминлеген сакларга сәләтле булу. Шулай ук зөлхиҗҗә ае башында тиешле йолаларны үти башлау өчен хаҗ сәфәренә алданрак чыгу да мөһим [Керимов, с. 100–102]. Шәригатьтә матди мөмкинлеге чикләнгән булса һәм сәламәтлеге зәгыйфь булса (ягъни үзенең тормышын куркыныч астына куеп) хаҗ сәфәренә чыгу тыела. Әмма, шундый таләпләр куелуга карамастан, мөселманнар Мәккәгә омтылалар. Бер генә илдә дә кешеләргә хаҗ кылу өчен чикләүләр закон нигезендә каралмаган. Руханилар дин тотучыларга «хаҗ кылу – ул байлар өчен, ярлыларга мәчеткә йөрү дә җитә. Әгәр бай кеше хаҗда булмаса, ул, үлгәч, динсезләр рәтендә саналачак», дип аңлаталар [АЭМ, Уфа, 2013].

Россиядә хаҗ кылу мөселман динен тотучылар йоласы булып санала, дәүләт белән мөселман җәмгыяте арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең мөһим элементын тәшкил итә. Бүгенге заман мөселманнарының хаҗ кылу йоласын өйрәнү проблемасы, 1990 еллардан башлап хаҗга баручылар санының артуы сәбәпле, аерым әһәмияткә ия. Согыд Гарәбстаны корольлеге тарафыннан мөселманнар яши торган илләргә карата билгеләнгән норма – 1 мең мөселманга бер кеше. 2009 елдан башлап Россиядән Согыд Гарәбстанына ел саен хаҗ кыларга 20500 чамасы мөселман бара. Ә безнең ил өчен квота күләме 20 мең. Хаҗ сәфәрен оештыручылар советы мәгълүматлары буенча ел саен анда барырга теләүчеләрнең 3–4 меңенә (чынлыкта бу сан күпкә артык) хаҗга бару өчен юллама җитми кала [Ильяс Умаханов…].

Россиядә ислам бербөтен социомәдәми бердәмлек тәшкил итми, тикшеренүчеләр аның социаль, мәдәни, психологик үзенчәлекле төзелешкә ия берничә ареалын аерып күрсәтәләр. Алар – Төньяк Кавказ, Идел буе, Урал һәм Көнбатыш Себер. Мәкаләдә Көньяк Уралда яшәүче мөселманнарның Согыд Гарәбстанындагы изге өлкә – Хаҗазга сәфәре үзенчәлекләре анализлана, анда баручыларның составы, мотивлары һәм бүгенге мөселман хаҗиларының үз-үзен тотыш формалары тасвирлана. Күпконфессияле Көньяк Урал регионында ислам факторын өйрәнү кысаларында РФАнең Уфа фәнни үзәге тарафыннан Башкортстан Республикасы (Аскын, Балтач, Белорецк, Бүздәк, Бөрҗән, Караидел, Зианчура, Туймазы, Уфа районнары) буйлап, шулай ук Оренбург өлкәсенә (Оренбург шәһәре), Курган өлкәсенә (Сафакүл, Әлмәт, Щучан районнары) оештырылган экспедицияләр вакытында безгә хаҗилар белән очрашып әңгәмәләшергә дә туры килде. Хаҗ кылу йоласын өйрәнүдә төп игътибарны аның

субъектына – җәмгыятьтәге теге яки бу катламга караган, дөнья турында билгеле бер карашка, тәртипкә һәм шәхси психологик үзенчәлекләргә ия булган кешегә юнәлтү мөһим [Калужникова]. Андый шәхесләр белән әңгәмәләр һәр кешегә хас каршылыклы эмоцияләр һәм кабул итүләр белән дә очрашырга мөмкинлек бирә.

Көньяк Уралда ислам йолаларын татарлар, башкортлар һәм казаклар үти. Башкортстан Республикасында хәзер барлык халыкның 53,8% ын этник мөселманнар тәшкил итә, Оренбург өлкәсендә бу күрсәткеч – 17%, Чиләбе өлкәсендә – 13,3%, Курган өлкәсендә – 6% [Всероссийская…]. Регионда, традицион исламны торгызу белән беррәттән, мөселманнарның социомәдәни дәрәҗәсе түбән булу, исламда «авыл» һәм «шәһәр» аерымлыкларының тотрыклы саклануы, руханилар һәм аларның җитәкчеләрнең дәүләткә таянуы, икътисади яктан тулы бәйсезлек булмау бүгенге көндә мөселманнарның хаҗ кылу активлыгы сүлпән булуда чагылыш таба [Юнусова]. Төньяк Кавказ һәм Татарстан Республикасы белән чагыштырганда, Мәккәгә хаҗ сәфәре кылу Уралда бик үк популяр түгел. Гомумроссия масштабыннан чыгып караганда хаҗиларның иң күп саны Дагстанга туры килә (80%), гәрчә илдә мөселманнар саны ягыннан зур күпчелекне татарлар һәм башкортлар тәшкил итсә дә (53%) [Нуриманов, с. 73]. Бу күренеш билгеле бер дәрәҗәдә икътисади кыенлыклар белән бәйле: Урал мөселманнарына хаҗга барып барлык йолаларны да үтәп кайту өчен 200 мең – 400 мең сум акча кирәк. Әмма Уралдагы хәйриячеләрнең матди ярдәме Төньяк кавказлыларныкы масштабында түгел. Чечен Республикасы башлыгы Р. Кадыйров белән Дагстан Республикасыннан сенатор С. Кәримов ел саен әз керемле 5–6 мең мөселманга хаҗ сәфәре кылу өчен хәйрияви юлламалар өләшәләр.

Төньяк Кавказда мөселманнар өчен биш фарыз гамәлнең соңгысын үтәүнең югары дәрәҗәдә булуы бу территориядә исламның үзенчәлекләре, аны торгызуның темплары зур булу һәм бу регионның географик яктан Согыд Гарәбстанына якын урнашуы белән аңлатыла. Хаҗ кылу йоласын үтәүнең бүгенге торышын регионнарда ислам үсешенең интенсивлыгы билгели, ә ул алардагы социаль-икътисади күтәрелеш дәрәҗәсе, халыкның хезмәт белән мәшгульлек сферасы өстенлеге, таралып урнашу формалары һәм социотабигый җайлашу кебек фактларга бәйле [Галләмов, с. 77]. Идел–Урал регионы мөселманнары Россиянең Европа өлешендә һәрвакыт исламның үзенчәлекле аванпостында булдылар, андагы гади дин тотучылар ислам илләрендәге мәдәният һәм көнкүреш белән якыннан таныш булмадылар.

Согыд Гарәбстанының хаҗ кылу урыннары Көньяк Уралга бик ерак, шуңа да карамастан, биредәге мөселманнар, ислам урнашканнан башлап, анда барып хаҗ кылырга омтылып яшиләр. Элек хаҗ кылып кайту вакыты,

ярты елдан башлап, берничә елларга сузыла торган булган, нигездә аны дини эшлеклеләр һәм бай мөселманнар гына үтәгән. Совет чорында хаҗга баручылар исәбе катгый регламентлаштырыла (бөтен илдән 20–30 кеше) һәм анда сәфәр кылучылар куркынычсызлык органнары тарафыннан сайланып, тикшерү үтәләр [Мухаметзянова-Дуггал, с. 53]. Хәзер хаҗ сәфәре кылу бик кыйммәткә төшә. 2013 елда, мәсәлән, «стандарт» программасы буенча ул 4200 доллар тәшкил итте [Рисалят, с. 12], 2014 елда мәчетләрдә таратылган мәгълүмати буклетларда 5500 доллар күрсәтелгән иде. Шәригать нигезендә бу максат өчен акчаны намус белән хезмәт итеп тупларга кирәк. Мөселманнар хаҗ сәфәренә юлга чыкканчы бер ел алдан әзерләнә башлыйлар: кирәкле документларны җыялар, прививка ясаталар, Диния нәзарәтләре каршында рөхсәт (виза) эшләтәләр. Урал хаҗилары һава транспортыннан файдалана, аларның Хиҗазга сәяхәте 25–30 көн дәвам итә. Гомумән алганда хаҗилар саны арту күзәтелә. 2007 елдан башлап, мәсәлән, Башкортстаннан Мәккәгә ел саен 300–400 дин тотучы бара, ә 2001 елда бу күрсәткеч 42 генә булган.

Хәзерге Россия дәүләте хаҗ сәфәрен оештыруда эчке һәм халыкара уңайлы шартлар тудырырга тырыша. Моның өчен Россиянең барлык регионнарында да дәүләти, административ, матди-техник, финанс, халыкара һәм кадрлар ресурслары, дәүләттән тыш иҗтимагый һәм дини потенциаллар җәлеп ителә. 1990 елларда хаҗ сәфәре билгеле бер тәртип буенча оештырылмый, ул чынлап та зур түземлелеккә сынау чарасы була: берничә көн авиарейслар көтеп утыру, алданулар, түләнгән юлламалар һәм хәтта турфирмалар юкка чыгу, Согыд Гарәбстаны корольләге тарафыннан аз керемле мөселманнарга дип җибәрелгән юлламаларны сату кебек хилафлыклар еш кабатлана. Россиядән хаҗга баручы төркемнәр таркау хәрәкәт итә, кешеләр, соңга калган ватандашларын көтеп яки кунакханәгә урнашу өчен бронь булмау сәбәпле, берничәшәр көн дәвамында тукланмыйча автобусларда көн уздыралар; сәяхәтчеләрнең төп массасына медицина ярдәме бөтенләй күрсәтелми, яисә ул вазифаны хаҗилар арасындагы медицина белеменә ия кешеләр үти [Сахаутдинов, с. 21]. Хәзер хаҗилар идентификацияләнгән электрон беләзекләр белән тәэмин ителә, ул, кирәге чыкканда, аларның кайсы урында булуларын ачыкларга ярдәм итә. Шулай ук 1990 елларда хаҗилар составын һәм санын бик тикшереп тормыйлар, анда теләүчеләрнең барысы да диярлек бара иде. Соңгы елларда Диния нәзарәтләре илгә бирелгән квотадан, совет чорында хаҗ кылу чикләнгән булу сәбәпле, иң элек өлкән яшьтәге мөселманнарга өстенлек бирәләр.

Хаҗның мәҗбүри йола таләпләре булуга карамастан, мөселманнар бу сәфәрне тормышка ашыру вакытында үзләренең шәхси мотивларына таянып эш итәләр. Ул мотивлар дөньяви

һәм рухани-дини хаҗиларны аерырга ярдәм итәләр. Дини хаҗилар өчен хаҗ кылу исламның фарыз гамәлләренең берсен үтәү булып санала, аларның андагы вакытлары һәм матди чыгымнары диннәренә инануларын тулы чагылдыра. Хиҗазга сәяхәт аларга рухи чистарыну һәм тормышларын өр-яңадан башлау мөмкинлеге бирә. Дөньяви хаҗилар исә хаҗга үзләре өчен исламның асылын ачу, табыш алу яки сәяси мәнфәгатьләрен күздә тотып баралар. Хаҗ кылу кеше тормышының хәлиткеч мизгеленә әйләнергә мөмкин, күпчелек очракта ул ортодоксальлек ягына үзгәрә. Бу тенденция интеллигентлар өчен характерлы.

1990 елларда хаҗ кылу республикалар башлыклары арасында популярлашты. Мәсәлән, президент булганчы ук М. Шәймиев (Татарстан), М. Рәхимов (Башкортстан), А. Кадыйров (Чечен Республикасы) хаҗ сәфәре кылдылар. Федерация субъектлары белән халыкка һәм туган илгә тугрылык антын Коръән тотып биргән президентт-хаҗилар идарә итте. Ислам руханилары «дәүләт һәм хөкүмәт җитәкчеләре Ходайдан куркалар икән, аларга ышанып була, алласызлар янәшәсендә беркайчан да тәртип булмаячак», дип фикер йөртәләр [АЭМ, с. Зигибяк, 2014].

Дөньяви һәм дини мотивларның кисешүе дә күзәтелә, бу күренеш аеруча дини эшлеклеләр арасында еш очрый. Бу төркем дини йолаларны тулырак саклый. Дингә ышанучылар даирәсендә хаҗ кылу Аллаһтан куркуны, иманга тугрылыкны раслый. Мөселман җәмгыяте җитәкчесе вазифасына билгеләгәндә яки аны сайлап куйганда хаҗда булып кайтучыларга өстенлек бирелә.

Мотивлар төркемнәрдәге мөселманнарның яшьләре белән дә аерыла: яшьләр өчен хаҗ кылу мәгърифәтлелек (дини яктан белемлелек) функциясен үти, өлкән буын исә бу сәфәргә гөнаһларыннан арыну, Аллаһ нигъмәтләрен үз күзләре белән күреп кайту нияте белән чыга. Көньяк Урал регионындагы яшьләр һәм мул тормышлы мөселманнар үзләрен әле хаҗ кылырга әзер түгел дип саныйлар, алар бу гамәлне рухи үсешнең иң югары этабы буларак бәялиләр.

Физик яктан да, рухи яктан да шактый авыр саналган хаҗ сәфәрендә мөселман хатын-кызлар да актив катнаша, алар хәтта күпчелекне тәшкил итә. Хәзер хаҗияләр саны арту дәвам итә, алар арасында хаҗ кылуга зур омтылыш саклана. Хатын-кызлар төрле юллар белән Мәккәдә булырга тырышалар. Хаҗ кылу тарихыннан мәгълүм булганча, XX гасыр ахырларына кадәр күп төрле катлаулылыклар белән бәйле бу сәфәргә нигездә ир-ат чыккан. Ислам мәхрәмнән (өйләнешү тыелган якын кардәштән) башка хатын-кызга сәфәр кылуны тыя, әмма 45 яшь тулганнан соң андый чикләү бетерелә. Әлеге яшькә җитмәгән хатын-кызлар төркеме хаҗ сәфәренә дини идарә вәкиле җитәкчелегендә юл ала.

1990 еллар башында күп кенә хатын-кызлар, дини йолалар үтәү белән бергә, үзләренең юл чыгымнарын каплау өчен, аннан

дини атрибутлар, кием-салым, келәм, алтын эшләнмәләр алып кайтып, сату белән шөгыльләнделәр. Хәзер дә хаҗ сәфәрен табыш алу максатында кулланучы хатын-кызлар бар, алар нигездә эшсезләр һәм пенсия яшендәгеләр. Югары белемгә ия һәм уңышлы эшмәкәрлек итүче яки дәрәҗәле урында эшләүче хатын-кызлар арасыннан да хаҗ кылучылар саны арта бара. Мәккәгә берничә мәртәбә (4–5 тапкыр) барган хатын-кызлар бар. Алар анда беренче тапкыр булганнан соң, курортларда ял итүгә караганда, акча җыеп яңадан Согыд Гарәбстанына барырга тырышалар [АЭМ, г. Уфа, 2013].

Хатын-кыз хаҗияләр саны арту, беренче чиратта, хаҗ сәфәре шартларының үзгәрүе белән бәйле, хәзер анда хезмәт күрсәтүләр туристларныкы дәрәҗәсендә, Мәккәгә бару да кыенлык тудырмый. Уралдагы динилек вазгыяте илкүләм хәлдә чагылыш таба, Россиядә хатын-кызлар чиркәүләргә һәм башка гыйбадәтханәләренә күбрәк йөриләр һәм дини йолаларны бирелеп үтиләр. Көньяк Уралда да ислам таләпләрен үтәүчеләрнең төп өлеше хатын-кызлар, аларның күбесе шәригать кануннарын катгый үтиләр, шуңа күрә хаҗга баралар.

Хаҗ кылучы хатын-кызлар артуның төп нәтиҗәсе дип мөселман хатын-кызларның үз-үзен тотышында яңа стереотиплар һәм җәмгыятьтә аларны кабул итү нормалары формалашуны атарга була. Хатын-кызларда башка илләрдәге мөселман хатын-кызлары белән уртаклыклар барлыкка килә, аларның дингә инануларын арттыра, аларга исламның уңай якларын (әйтик, яулык бәйләү, ябык кием кию) табарга ярдәм итә. Алар башта ислам йолалары символларын дин белән бәйле модага ияреп кенә үтәгән булсалар, хаҗ сәфәреннән соң аларны чын күңелләреннән эшлиләр. Мөселман хатын-кызлардан бу хакта сораштырганда, аларның күбесе хаҗ кылулары турында күз яшьләре белән сөйлиләр. Хатын-кызлар, ир-атлардан аермалы буларак, хаҗ сәфәреннән һәрчак зур рухлану алалар, ир-ат исә хаҗ кылу шартларын аек акыл белән кичерә һәм күңелсез хәлләрне дә исендә калдыра. Мөселман ир-атлар хаҗ вакытында кайбер хатын-кызларның озатучысыз йөрүеннән, кайткач сатарга дип әйбер җыюыннан, «үз-үзләрен бәйсез тотуыннан, үзләренә карата кирәгеннән артык игътибар таләп итүләреннән, башка ир-атлар белән аралашуларыннан, хатын-кызларга кагылмаган проблемалар турындагы сөйләшүләрдә катнашуларыннан» һ.б.дан ризасызлык күрсәтәләр [Сахаутдинов, с. 23–24, 27]. «Исламның бөтен яңалыгы (Мөхәммәднең сүзләренә һәм гамәлләренә каршы килә торган чаралары һәм гамәлләре) хатын-кыздан», – диләр алар [АЭМ, с. Караидель, 2013]. Шул ук вакытта алар хатын-кызларның түземлелеген һәм үзара оешканлыгын да билгеләп үтәләр.

Дин тотучылар бергәлеге эчендә хаҗилар элита өлешен тәшкил итәләр һәм үзләренең бергәлегендә алар иҗтимагый климат формалаштыруга нәтиҗә-

ле йогынты ясыйлар. Хаҗ кылган кеше «хаҗи» яки «хаҗия» (хаҗ кылучы) дигән мактаулы исем ала, диндәшләренең хөрмәтенә лаек була. Аның әйләнәсендә «аеруча тәкъва кеше» нуры барлыкка килә. Мөселман кешесенә хаҗ вакытында туплаган рухи тәҗрибәсенең дини мәхәлләдә җитди кабул ителүенә шикләнергә кирәкми. Хаҗ кылу мөселман җәмгыятендә хатын-кызларның статусын да күтәрә. Хаҗи яки хаҗия белән очрашканда хатын-кызларга, мәчеткә кергәндәге кебек, яулык бәйләү гадәткә кергән; мәхәлләдә җитди карарлар кабул иткәндә хаҗияләрнең дә фикере исәпкә алына [АЭМ, с. Карткисәк, 2013]. Башкортстан Республикасының район үзәкләрендәге һәм авыллардагы мәктәп музейларында махсус бизәлешле стендларда соңгы елларда хаҗга барган авылдашлары хакында мәгълүмат урнаштырылагн [АЭМ, Зианчуринский р-н…, 2013]. Дин тотучы, әмма хаҗга барырга мөмкинлеге булмаган кешеләр хаҗи, хаҗияләр белән аралашырга омтылалар: Хаҗга баручыларны озату һәм каршылау йолаларында катнашып, юлаучыга хәер бирәләр; кайтучылар бүләк иткән изге Зәм-зәм коесы суыннан авыз итәләр. Алар өчен хаҗ кылып кайткан кешегә кагылу да зур бәхет санала [АЭМ, г. Оренбург, 2009].

Хаҗда булып кайтучылар белән әңгәмәләрдән аңлашылганча, нинди генә уңайсызлыклар, кыенлыклар кичерүләренә карамастан, аларның күбесенең хаҗ сәфәреннән тирән рухи канәгатьләнү хисләре белән кайтуларын тоясың. Мәккәгә барып ирешүгә алар үзләрен оҗмахтагыдай хис итәләр. Хәзер хаҗ сәфәрләре оешкан төстә уздырыла, дөньяви һәм сакраль пространстволар бердәмлеге күзәтелә. Мөселманнарга үзләренең төрле максатларын (коммерция шөгыле, башка илләрдән килгән диндәшләре белән аралашу, мөселман мәдәнияте белән танышу) тормышка ашыру мөмкинлеге бар. Дин тотучылар хаҗда исламча яшәү рәвеше белән танышалар. Көньяк Уралдан һәм Россиянең башка регионнарыннан хаҗга баручылар саны арту илдәге мөселманнарның ислам белән тирәннән кызыксынуын, мөселман йолаларының искеләрен торгызуын һәм яңаларын формалаштыруын дәлилли. Сәяхәт вакытында региональ тәңгәллек көчәя, мөселманнар изге җиргә Россиянең төрле почмакларыннан килеп төшәләр. Анда булучылар Мәккәдә яшәүче гарәпләрнең, кызганычка каршы, Россия мөселманнарының Кавказдан һәм Татарстаннан килүчеләрен генә белүләрен, Урал регионы (Башкортстанны да кертеп) алар өчен таныш булмавын искәртәләр [АЭМ, с. Балтачево 2013].

Хаҗ кылганда чит мәдәният белән танышу, аның белән турыдан-туры очрашу һәм үзеңнекенә читтән карау сәяхәтчегә уртак якларны баетырга ярдәм итә [Белоруссова, с. 5]. Хаҗ дин тотучыларга идеалдагы исламның асылын аңлау, күзәтүләрен һәм хисләрен үзләре яшәгән төбәкләргә алып кайту мөмкинлеге бирә. Хаҗ кылуның торган

саен киңрәк колач ала баруы Россия мөселманнарының дөнья күләмендәге гомумислам бергәлеге процессына кушылуының котылгысызлыгын раслый, ул Согыд Гарәбстаны, Төркия, Мисыр кебек эре ислам үзәкләренең Россия мөселманнарына йогынтысы астында бара. Хаҗ халыклар арасындагы туганлык элемтәләрен ныгыта, ислам мәдәниятенә һәм цивилизациясенә якынаерга этәргеч бирә. Россиядәге, шул исәптән Көньяк Уралдагы, мөселман халыкларның «Мөселман өммәте» төшенчәсенә хас булган бердәмлеккә, тупланганлыкка омтылышы көчәя бара. «Хаҗга бөтен мөселманнар да барса иде, әгәр анда бара алсам, мин иң бәхетле кеше булыр идем», – диде миңа бер дин тотучы [АЭМ, Уфа, 2013].

## Чыганаклар

АЭМ (авторның экспедиция материаллары), Оренбург өлкәсе. Оренбург шәһ., 2009.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Аскын районы Карткисәк ав., 2013.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Балтач районы Балтач ав., 2013

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Уфа шәһ., 2013.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Зианчура районы Исәнгол ав., 2013.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Караидел районы Караидел ав., 2013.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Туймазы районы, Җегетәк ав., 2014.

АЭМ, Башкортстан Республикасы. Уфа шәһ., Уфадагы Беренче җәмигъ мәчете, 2013.

Всероссийская перепись населения // Официальный сайт Госкомстата Российской Федерации. URL: http://perepis2002.ru

Рисалят (религиозно-просветительская газета). 2013. № 6 (179).

*Сахаутдинов В.Г.* Воспоминание о паломничестве. Уфа: МРО Ихлас, 1997. 36 с.

## Әдәбият

*Белоруссова С.* Антропология путешествия (южноевропейские путешественники XV века). Saarbruken: Lambert, 2013. 143 с.

*Галлямов Р.Р.* Исламское возрождение в Волго-Уральском макрорегионе: сравнительный анализ моделей Башкортостана и Татарстана // Ислам от Каспия до Урала: макрорегиональный подход: сб. статей / под ред. К. Мацузато. М.: Росспэн, 2007. С. 71–117.

*Головнев А.В.* Антропология движения (древности Северной Евразии). Екатеринбург: Волот, 2009. 496 с.

*Замятин Д.Н.* Феномен паломничества: географические образы и экзистенциональное пространство // Феномен паломничества в религиях: священная цель, священный путь, священные реликвии: материалы XIII Санкт-Петербургских религиоведческих чтений. СПб.: Акционер и К°, 2006. С. 3–4.

Ильяс Умаханов о хадже 2011 года. ИД «Медина». URL: http://www.idmedina.ru/books/history_culture/74748 (дата обращения: 20.02.2017)

*Калужникова Е.А.* Паломничество как ритуал: сущность и культурно-исторические типы: дис. ... канд. культурологии. Гуманитарный университет, Екатеринбург, 2007. 167 с.

*Керимов Г.М.* Шариат: закон жизни мусульман. Ответы Шариата на проблемы современности. СПб.: Диля, 2012. 512 с.

*Мухаметзянова-Дуггал Р.М., Хабибуллина З.Р.* Россия и Индия: государственное регулирование хаджа // Азия и Африка сегодня. 2011. № 1. С. 53–56.

Наука странствий: корни и перспективы. Учение о путешествиях обречено на возникновение. Интервью с В. Каганским // Частный корреспондент. 2013. 23 апр. URL: http://www.chaskor.ru/article/nauka_stranstvij_korni_i_perspektivy_31878 (дата обращения 25.11.2017)

*Нуриманов И.* Хадж мусульман России. Из прошлого к настоящему // Хадж российских мусульман: сборник путевых заметок о хадже. Нижний Новгород: ИД Медина, 2008. С. 67–79.

*Юнусова А.Б.* Ислам в России // Россия и мусульманский мир. 2010. № 6. URL: http://www.promreview.net/moskva/islam-v-rossii?page=0,6 (дата обращения: 15.12.2017).

***Хәбибуллина Зилә Рәшит кызы,***
*Россия Фәннәр академиясенең Уфа фәнни үзәге*
*Р.Г. Кузеев исем. Этнологик тикшеренүләр институты*
*дин белеме бүлеге фәнни хезмәткәре*
*E-mail: zilyahabibi@mail.ru*

*М. Бигиев*

# МӨСЕЛМАН РУХАНИЛАРЫНЫҢ 1905 ЕЛГЫ УФА КОРЫЛТАЕНДА КАРАЛГАН КАЙБЕР ПРОЕКТЛАР[1]

## Әбү әс-Согуд әфәнде Әхтәм җәнапләренең собрание хакында фикере

1. Собрание мөселманнарның бөтен рухани эшләре хакында баш мәркәз мәхкәмә улып, биля васита [турыдан-туры] тугры дахилия назараты [эчке эшләр министрлыгы] илә эш күрер.

2. Баш мәркәз собрание тәхет идарәсендә [идарәсе астында] урта дәрәҗә собрание мәхкәмәләре дә хаҗәт кадәренчә тәэсис кылынып, мәхәлләләрнең мәктәп-мәдрәсәләрнең һәммә эшләренә биля васита нәзарат итәрләр [идарә итәрләр, күзәтерләр].

3. Баш һәм урта собрание әгъзалары халык ихтыяры илә сайланыр. Мөфти император хәзрәтләренең фәрманы илә, баш собрание әгъзалары дахилия назаратының тәсдыйкы илә, урта собрание әгъзалары баш мәркәз собрание тәсдыйкы илә тәгаен кылыныр.

Һәр интихаб [сайлау] мувәкъкать [вакытлы] улыр, интихаб дәфтәренә кайд кылыначак [беркетеләчәк] кандидатлар өчен махсус бер низам төзелер. Һәр мөселман сайланмак хакына малик улып, ялгыз руханиларга хас улмас.

4. Мәркәз һәм урта собраниеләргә 1418 статьяда бәян кылынмыш хокук өстенә вәкыфларны идарә итмәк, яңа мәсҗед бинасына, яңа мәхәллә тәэсисенә рөхсәт вирмәк хакы да вирелер. Архитекторга җәһәте илә вилаят правлениеләре мөдахәлә [катышу, кушылу] итмәс.

5. Мөселманнарның рухани идарәләре хакында мөфассал канун маддәләре төзү өчен, хөкүмәт адәмнәре илә бәрабәр мөселманнарның мөмтаз галимнәре, могтәбәр зыялылары рәи сахибы улмак сыйфаты илә хазир улса иде. Мәхкәмәләрдә, хөкүмәт идарәләрендә, комиссияләрдә мөселманнарга гаид бер мәсьәлә каралачак улыр исә, мөфти һәрвакыт хозури лязим әгъзалардан хисап кылынса иде.

6. Баш мәхкәмә хөкеме һәрвакыт һәр хосуста соң хөкем улыр, шикаять хакында малик улмас. Баш мәхкәмә дахилия назаратына табигъ исә дә, карарларын дахилия назараты тәгъйир итәмез [үзгәртәбез, алмаштырабыз]. Әгәр дә баш мәхкәмә хөкеме билкөлли [бөтенләй, тулысынча] закон әсасларына хилаф [каршы] исә, яхуд дәүләт өчен зарары вар исә, яхуд чит милләт кешеләре-

[1] Җарулла Муса. Ислахат әсаслары. Пг.: М.-А.Максутов типографиясе, 1917. Б. 91–105. Дәвамы. Проектларның бер өлеше «Фәнни Татарстан» журналының 2 нче һәм 3 нче саннарында дөнья күрде.

нең, җәмгыятьләренең хаклары заегъ [югалган] улачак исә, шул тәкъдирләрдә генә дахилия назараты баш мәхкәмә өстеннән вәзирләр [министрлар] мәҗлесенә я Сенат тәфтишенә [тикшерүенә] мөраҗәгать итәр.

### Самара ахунды Шиһабеддин хәзрәт ляихәсе

Корылтай мәҗлесләренең мөзакәрәләренә [фикер алышуларына] хәзерлек юлы илә улса кирәк, Самара ахунды Шиһабеддин хәзрәт Минуш җәнапләре тарафыннан да 33 маддәлек бер ляихә язылмыш. Әүвәлге ляихәләрдә юк маддәләрен бу раддә нәкыль итәем:

15. Ибтидаи мәктәпләргә мөгаллим тәгаен кылыныр исә, мәхәллә имамы тәгълим вазифаларыннан азат улыр.

23. Имам улачак адәм шәһадәтнамәсе буенча һәр никадәр мөстәхикъ [хаклы, лаеклы] исә дә, әүвәлге указда имам-хатип дәрәҗәсеннән зиядә [артык] дәрәҗә вирелмәс. Ибтидаи мәктәпләрдә ике сәнә тәгълим итмәенчә мөгаллимлек указы, өч сәнә мәдрәсәдә тәдрис итмәенчә мөдәррислек указы, биш сәнә гүзәл хезмәт күстермәенчә ахундлык указы вирелмәс.

25. Имтиханда тәгаен кылыначак дәрәҗә дүрт булыр: 1) имам, 2) мөгаллим, 3) хатип, 4) мөдәррис. Тәхсил кылынмыш голүмнең, мәгълүматның кәсрәтенә [артыклык, күплегенә], кыйлләтенә [азлыгына] бакып.

26. Мәдрәсә дәресләрен тәмам итүдән шәһадәтнамәсе юк шәкертләр имтихан кылынмас.

30 Мәктәптә мөгаллим юк исә, тәгълим итмәк вазифасы имамнарга лязим улыр.

32. Мәктәп, мәдрәсәләрдә тәгълим, тәдрис мәҗанән [түләүсез, буш] улыр, таләбәләрдән бәдәл [бәя, хак] алынмас, иҗратсыз улыр. Мөгаллимнәргә, мөдәррисләргә айлык вазыйфә [хезмәт хакы] вирелмәс, бәлки мөгаллимнәрнең, мөдәррисләрнең мәгыйшәтләрен тәэмин итмәк кифаяләрен [җитәрлек булуын] вирмәк мәхәллә җәмәгате өстенә инсаният моктәзасы улмак [кирәксенелгән, лязим булган] әүзәрә шарт кылыныр.

33. Тәгълим, тәдрис эшләрендә иҗтиһад [тырышлык] итеп, имтияз [өстен булу] кәсеп итәчәк мөгаллимнәргә, мөдәррисләргә һәр биш-ун сәнәдә бер дәфга [кат, тапкыр] мөкяфәт [хезмәт бәрабәренә бирелгән премия, бүләк.] сәрмаясы тәшкил кылыныр. Мөкяфәт сәгать кеби гайни [әһәмиятле], бакый [мәңгелек] ула булачак шәйләрдән вирелер.

Галимнәр мәҗлесенә бәлки лязим улыр хыялы илә улса кирәк, мәрхүм мөфти Мөхәммәдьяр әфәнде Солтанов җәнапләре дә 70 маддәдән гыйбарәт бер проект язмыш. Тәрҗемәсе көтепханәмдә вар. Працтта яңа бер шәй юк, бәлки 11 нче томда мөселманнарның идарәләренә гаид (1672–1342) маддәләрдән зиядәсез тәртипсез туплама бер шәһдер. Мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләренең гүзәл ляихәсе беркәсендә улса кирәк. Мөфти ляихәсе мәҗлес мөзакәрәләренә вирелмәмеш. Закон статьялары тәрҗемәләре илә бәрабәр

мәҗлестә укылдыкыннан соң, хаҗәте дә, файдасы да, әлбәттә, юк иде.

Голяма мәҗлесләрендә хәзрәтләр кулында ул вакыт хәзер улмыш ляихәләрне, маддәләрне яздык. Ул ляихәләрдән, ул маддәләрдән интихаб кылынып алынмыш маддәләрне дүрт хәзрәттән тәшкил кылынмыш бер һәйәт [комиссия] ике көн эчендә язып хәзерләделәр. Һәммә хәзрәтләр тарафыннан имза мөфти хәзрәтләренә тәслим иттеләр. Остаз мөхтәрәм Риза эфәнде хәзрәтләренең ляихәсеннән тәхриф кылынып [язылган сүзләрне үзгәртеп] интихал [әдәби караклык, плагиат] кылынмыш кеби бер шәй иде.

**Мохтәлитъ һәйәт**
[катыш комиссия]

Сигез дәфга [тапкыр] тупланмыш голяма мәҗлесләре – корылтай үзенең мөзакәрәләрендә, хезмәтләрендә гүзәл сурәттә иҗтиһад илә биш көн дәвам итеп, 1905 сәнә апрель 15 ндә җомга көн хәер сәгатьтә тәмам улды, ябылды. Йосыф әфәнде Акчура гаризасында мөзтәрәм могтәбәр алты зат тарафыннан таләп кылынмыш әүвәлге рәҗа бәркәсендә [кәгазь битендә] улса кирәк, корылтайда хәзрәтләрнең биш көн иҗтиһадлары сәмәрәсендә [нәтиҗәсендә] хәзерләнмеш карарлары тәртип итеп, тәһзиб итеп [төзәтеп], тәрҗемә итмәк өчен мөфти хәзрәтләре тарафыннан бер мохтәлитъ һәйәт дәгъвәт кылынды. Һәммә маддәләрен закон статьялары формаларына куймак, косурлары булыныр исә тәгъмир итмәк [яңартылды, төзекләндерелде]; я хаталары, я зарарлары булыныр исә, ислах итмәк вазифалары да шул һәйәтнең әманәтенә вирелде.

Һәйәт әгъзалары:

1) Котлугмөхәммәт мирза Баһадиргәрәй угылы Тәвкилев, полковник, Бәләбәй шәһәрендә уездный предводител; Җансолтан Чуак угылы Сәйдалин (Сәедгали), Троицки окружной суд әгъзасы;

2) Габдулла Тимур угылы Тимуров, Уфа окружной суд әгъзасы;

3) Сәлигәрәй Сәедхан угылы Җантурин, Уфимский губернский присутствиеда әгъза;

4) Әбуссогуд Габделхалик угылы Әхтәм, Казан палатасы хозурында земельный дәгъваи вәкиле;

5) Сәедгәрәй Шаһиәхмәд угылы Алкин, Казан палатасы хозурында земельный дәгъваи вәкиле;

6) Ризаэддин Фәхреддин угылы, имам, мөдәррис, ахунд; собрание әгъзасы, бөек әсәрләр сахибы;

7) Дамелла Габдулла хәзрәт Габделкәрим угылы Апанай, Казанда имам, мөдәррис.

8) Ибраһим әфәнде Хәрәмшаһ угылы Акчурин, фабрикант, эдип.

9) Мөхәммәдзакир Мөхәммәдсадыйк угылы Рәмиев, эдип, әгънияддан [байлардан] беренче дәүләт думасында әгъза.

10) Мөхәммәтйосыф Мөхәммәтәмин угылы Дибирдиев, фабрикант, суфый.

Шул һәйәтнең мәҗлесләре апрель 18 дүшәнбедән апрель 20 шәһаршәнбе көненә кадәр

дәвам итеп, өч көн эчендә бишалты мәҗлестә мөзакәрәләрен тәмам итмеш исә дә, русча иншасы, закон статьяларына муафыйк шәкелдә тәртип хезмәтләре 1905 сәнә 3 нче май көннәренә кадәр дәвам итеп, чәршәнбе көн рәбигыль әүвәл 12 дә тәмам улмыш.

Соң 13 көн дәвам итмеш хезмәтләр ялгыз Ибраһим әфәнде Акчурин, Әбуссогуд әфәнде Әхтәм, Закир әфәнде Рәмиев җәнапләренең иҗтиһадлары бәрәкәсендә тәмам улып, араларында бераз тәфавет [аерма] вар өч-дүрт нөсхә ляихәләрнең табгы кылынып Русия мөселманнары арасында интишарына [таралуынаа, җәелүенә] юл ачты. 1) бере имамнар ляихәсе, 2) Йосыф әфәнде Акчура ляихәсе, 3) Уфа башкортларының ляихәсе.

Маддәләренең саннары, тәртипләре, гыйбарәләре җәһәте илә шул өч ляихәдә бераз тәфавет вар исә дә, мәфһүм [аңланган] максуд җәһәте илә һәммәсе бердер.

«Корылтай» исемле әсәрендә бәянына күрә, остаз мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләре мохтәлитъ һәйәт мәҗлесләренең башыннан ахырына кадәр хазир улыр [шунда булыр] имеш, ләкин рәи вирмәк хакына малик улмак сыйфаты илә дәгел, бәлки истифсар [сорап белү, тулы аңлатуны сорау] хаҗәт улыр исә, маддәләре бәян итмәк мөшавәрәт [киңәшләшү] вирә белмәк сыйфаты илә.

«Корылтай» исемле әсәрендә мөхтәрәм Риза әфәнде әйтә: «Корылтай мәҗлесендә мөмкин кадәр хазир улып, олуг-кечек шәйләрнең һәрберен өстендә язып тормак һәвәсендә улмыш исәм дә, собраниедә мәшгулиять [эшчәнлек] көннәре улдыкыннан, хазир улмак мөмкин улмады. Буның илә бәрабәр, гаять җөзьи иң әүфак шәйләр хакында кат-кат мөзакәрәләре, кояш кеби ачык гыйбарәләре дә тәҗаһел кылып [белмәмешкә салышып], истифсарлары күңелләре рәхәтсезлек авырлык вирдекләренә күрә, байтак мәҗлесләре үз арзум илә тәрк итәр идем. Фәкать мохтәлитъ һәйәт мәҗлесләре корылтай мәҗлесләренең тәмам хилафына иде: күңелемдә бөек бер нәшат [шатлык, сөенеч] пәйда итте. Һәр никадәр гадәтем хилафына уларак бөтен төннәрне ул раддә лязим килмеш исә дә; нә тәнемдә, нә рухымда һичбер рәхәтсезлек әсәре хис итмәс идем. Билгакес [киресенчә], сохбәтләрнең сузылмасын мөзакәрәләрең, узанмасын гыйбта итәр [берәүдәге яхшы якларны күреп үзендә дә шуны булдырырга теләр, кызыгыр] идем. Бу раддә сөальләр, җаваплар гаять мохтәсар [кыска] сурәттә кәчер, һичкем тарафыннан бер шәй истифсар ителмәксезен сәгатьләр узар иде. Мохтәлитъ һәйәт мәҗлесләренә мөфти хәзрәтләренең тәклифе [көчләп кушуы] илә һәр никадәр арзум хилафына уларак кердем исә дә, бөек истифадәләр итеп [файдаланып], камил хошнуд [шат, канәгать] улып чыктым. Һәм дә ляихәмдә бәгъзе маддәләрнең хаталарын да тасхих иттем [төзәттем, дөресләдем]. Мәсәлән, 35 нче маддәдә «Казыйларны Сенат тәсдыйк итәр» сүзем кеби. Мәэмүрләрне [чиновникларны] тәсдыйк итмәктә Сенатның

һичбер дәхеле [катнашы] булынмас имеш, аңладым».

«Корылтай» исемле әсәрендә галимнәрнең мәҗлесләрен интикад [тәнкыйть] юлында мөхтәрәм Риза әфәнде хәзрәтләре димеш:

«Корылтай мәҗлесләрендә хазир улмыш хәзрәтләрнең әксәре мөфти җәнапләренең дәгъвәты илә хазир улмышлар исә дә, бәгъзеләре дәгъвәтлы дәгел иде. Дәгъвәт кылынмыш хәзрәтләрнең дә бер кыйсеме бәгъзе бәһанәләр [сылтау, сәбәпләр] күстереп хазир улмады. Шул илә ки, корылтай мәҗлесләре дә дәгъвәтлылар илә дәгъвәтсызлардан мохтәлитъ димәк җаиз [дөрес, яраклы] иде. Буны язмак бер җәһәттән мөнасиб дәгел исә дә, дигәр бер җәһәттән гаять мөһим бер ноктадыр. Бинаән галәйһи укучыларны хәбәрдар итмәк лязимдер. Зарфадан мөрәккәб [кушылган, бергә җыелган] бер җәмгыятьтә: «Корылтай һәйәте собрание тарихында иң беренче гүзәл һәйәт гад кылына [исәпләнә] белерме? Шул бапта фикереңез ничәдер?» – сөаленә мохатиб [эндәшүче, сүз алып сөйләүче] улдым. Шул сөальгә һич тәфәккер итмәй [фикерләмичә, уйламыйча]: «Һәр никадәр әгъзалары арасында гаять бөек, мөстәгыйд [сәләтле, булдыклы] затлар вар исә дә, занымa күрә [минемчә], иң гали һәйәт дәгел иде, буннан да гүзәл һәйәт дәгъвәт кылына булыр иде», дия җавап вирмеш идем. Гаҗәлә [ашыгычлык, тизлек] исә дә җавабым тугры иде. Дөрест, корылтай эчендә бөтен фикерләрен ихлас һәм иҗтиһад илә эш юлында сарыф итүче әфәнделәр вар иде, ләкин бөтен арзулары эш чуалтмак, зиһеннәрне саташтырмак, мөзакәрәләрне истикамәттән [дөрес юлдан] чыгарып арага ялгыз магаләтъ [ялгыш, хата] төшермәктән гыйбарәт затлар да вар иде. Ул илә адәмнәр илә мөһим мәсьәләләрне мөзакәрә кылып хәл итмәк түгел, бәлки көтүче ялламак та авыр улыр, дия берничә хәзрәт тәәссеф лисаны илә бер кач дәфга сөйләде. Озын мөзакәрәләр соңында тавыш вирдерелеп карар галямәтләре язылдыктан соңра «Мин әле аңламый калдым, нә иде?» диюче адәмнәр дә күрелер. Хәтта бер аралык, мәҗлестә садырат [рәислек] иткән зат: «Хәзрәтләр! Мөзакәрәләрне ихлас илә, дикъкать илә тыңлавыңызны рәҗа кылам! Әгәр дә аңламый калучы адәмнәр булса, тавыш вирдерүдән мөкаддәм игълан итсеннәр иде. Тавыш вирдерелеп, карар кабул кылындыктан соң һичкем сүзе мәсмугъ улмас [ишетелмәс]». «Бу илә мәҗлесләрдә бу илә сүзләрне һәркем үзе белмәк лязим исә дә, нә чара, аякка калкып, мәҗлес рәисе сыйфаты илә ихтар итәргә мәҗбүр улдым», – диде. Бер адәм гомумгә мөтәгалликъ [бәйле, мөнасәбәтле] мәҗлесләрдә кабул кылынмак шәрәфенә наил улмыш исә, әгәр дә тавыш вирмәк хакына да малик улыр исә, гаять инсаф, камил игътибар үзрә вазифаларын ифа итмәк лязим улыр. Мәҗлестә я бөтен көчеңне сарыф итеп хезмәт ит, яхуд башкаларның хезмәтләренә дә манигъ [тоткарлаучы] улмамык өчен истигъфа ит [хезмәттән азат ител] тә, чык, кит. Юкса, эшчеләр арасына кереп тә, эшләренә ма-

нигъ улып тормак гакыл вә инсаф шәригатенә керү җаиз дәгелдер. Буны тәнзыймат [тәртипкә салу] язучылар да кабул итмәсләр, тупрак казучылар да тәхәммел итмәсләр [түзмәсләр, чыдамаслар]». Мөхтәрәм Риза әфәнденең сүзләре бу рәддә тәмам улды.

Корылтай мәҗлесләрендә мөзакәрә кылынмыш мөтәгаддид [күпсанлы] ляихәләрне югарыда яздык. Ул ляихәләрдән интихаб кылынып [сайлап алынып] хәзрәтләр тарафыннан имзаланып мөфти хәзрәтләренә, соңра мохтәлитъ һәйәт ислахына вирелмеш ляихәне дә зикер иттек. Бөек галәбәлек [өстенлек, җиңү] арасында аз мөддәт эчендә ул җирдән, бу җирдән алмак ысулы илә язылмыш маддәләрнең ислах кылыначак җәһәтләре, шөбһә юк, гаять күп улыр.

Мохтәлитъ һәйәтнең сәбатлы [үзгәрмәүчән, даими], җиддиятьле иҗтиһады илә ислах кылынмыш тәртип кылынмыш, русча язылмыш ляихә маддәләренең тәрҗемәләрен «Уфа ляихәсе» исеме илә бән бу рәддә нәкыль идәем.

Инсаф фәрманына инкыяд итеп игътираф итмәк безгә лязимдер: Уфада корылтай мәҗлесләре дә, мохтәлитъ һәйәте мәҗлесләре дә безем иҗтимагый хәрәкәтләремезнең башы, бәрәкәтле бисмилласы, куәтле әсасы иде. Уфа ляихәсе соң тугмыш ляихәләрнең гакыллы анасы иде. Бән буны игътираф идәрем. Буның илә бәрабәр Уфа ляихәсенең мәәхәзен [чыганагын] дә бәлки тәгаен идәрем. Иншалла.

## Уфа ляихәсе

### I
### Мөселманнарның хокук динияләре

1. Русия дәүләтендә төп законнарның куәте илә тәэкид [раслау, ныгыту] һәм тәсдыйк кылынмыш хокук әсасы илә бәркәсендә [кәгазендә] Русия мөселманнары камил хокуклы граждан улмак сыйфаты илә һәрбер мәдәни хокукта асыл руслар илә тәмам бәрабәр улып, үзләренең диннәрендә дини эшләрен әда [үтәү] хосусларында һәр җирдә һәр вакыт там тарлык кылынмас, тәхдид улынмас [чикләнмәс]. Хәят динияләре һәрвакыт һәр хосуста шәригате исламия хөкемнәренә һәр җәһәт илә муафыйк улыр.

(1 нче том, 1 нче кыйсемдә 42–45 маддәләр. 11 нче томда 1 маддә. Төп законнарның 1906 сәнә нәшерендә, 86 нчы маддә. 1905 сәнә октябрь 17 манифесты, 1904 сәнә декабрь 12 указы, 1906 апрель 17 дә министрлар комиссиясе тәсдыйк итмеш низамнар).

2. Шәригате исламия инсанның ялгыз иманына, ялгыз гыйбадәтенә мәхсур [чикләнгән] калмаеп, бөтен ихтыярый гамәлләрен, иҗтимагый хәятнең бөтен җәһәтләрен ихата итәр, һәммәсе хосусында үзенең тәгълиматларын бәян итәр. Хокук диния мәдәни хокукларның әксәрен шамилдер [күбесен эченә алган]. Буңа күрә, хөррияте диния әсасы илә бәрабәр Русия мөселманнарына закон куште илә тәэкид кылынып гали әт-тәфзыйл [артыклык] бәян кылыначак шул

хокукларны да үзләренең ихтыярларына тәслим итмәк лязим улыр: 1) дини гамәлләрне, рухани хаҗәтләрне, шәргый рөсүмнәрне [салым, налогларны] һәр җирдә һәрвакыт һәрбер тарикъ [ысул, метод] илә бәян итмәк хакы, 2) мөселманнарның дини, иҗтимагый эшләрен идарә итмәк өчен, шәригате исламия әсасларына муафыйк тарызда [файдалы тәртиптә] тәртип кылынмыш рухани идарәләрне, руханиларны тәэсис итмәк, 3) мәсҗедләрен, гыйбадәтханәләрен үз ихтыярлары илә бина итмәк, 4) шәригате исламия рухына һәр җәһәт илә муафыйк ысулда үзләренең балаларын тәрбия итмәк, 5) үзләренә махсус каберстаннарга һәр җирдә малик улмак, 6) һәм голүме диния, һәм мәгариф гомумия тәгълим итеп, ислам балаларын дини-милли рухта тәрбия итмәк өчен ибтидаи, урта, бөек мәктәп-мәдрәсәләр ачмак; һәр җирдә һәрберендә үз лисаннарында тәгълим итмәк, 7) рухани, дини максатлар намына сәрмаялар тәшкил итмәк, мәнкуль [күчерелгән] гайре мәнкуль милекләргә малик улмак; ул сәрмаяларны, ул милекләрне үз ихтыярлары илә идарә итмәк, 8) мәхәллә кеби, мөтәвәллилек кеби халык идарәләре хозурында һәр җәһәте үзләренең ихтыярларында улмак шарты илә әукаф тәэсис итмәк, 9) мирас кеби гаилә мәсьәләләре кеби мөселманнарның ялгыз үзара мөгамәләләренә гаид һәммә эшләрне һәр хосуста шәригате исламия хөкемнәрен муафыйк ысул әүзәрендә һәр җәһәт илә тәнзыйм итмәк [тәртипкә салган].

## II
## Рухани идарәләре

3. Мөселманнарның өмуре динияләренә [дини эшләренә] өч дәрәҗә рухани идарәләр нәзарәт [идарә] итәр: а) собрание, мәхкәмә шәргыя намында баш идарә, мәркәз идарә; б) вилаять мәҗлесләре, в) мәхәллә руханилары.

4. Баш идарә Уфада улыр. Кырым һәм Закавказие мөселманнарыннан башкалары һәммәсе Уфа идарәсенә табигъ улыр [буйсыныр]. Даирәсенә дахил [әйләнә-тирәсенә кергән] бөтен мөселманнарның бөтен дини эшләренә Уфа собраниесе баш идарә улыр.

5. Баш идарә ике шөгъбәдән мөрәккәб улып; рәис, алты казый, бер секретарь, архивариус, юрисконсульт, канцелярия хадимнәреннән тәшкил кылыныр.

6. Вилаять мәҗлесләре мәхәлләләр хисабы илә игътибар кылыначак районнарда тәэсис кылыныр. Һәр районда 100 мәхәллә һәм зиядә ула булыр. Районнарны тәшкил итәр икән, киңлек, халык күплек, юл уңайлык җәһәтләре, ягъни мәҗлесләрнең вазифаларын хезмәтләрен асатлаштырачак я авырлаштырачак хәлләр хисапка алыныр.

7. Вилаять мәҗлесләре дә баш идарә кеби бер һәйәт көллиядән гыйбарәт улып; вилаять казыйсы рәис, мәхәлләләр ихтыяры илә мөдәррисләрдән, хатиплардән сайланмыш ике әгъза, канцелярия мәэмүрләре: бер кяргәзар, берничә катипләрдән тәшкил кылыныр.

8. Мәхәллә руханилары – җамигъ хозурында, мәхәлләләрнең һәрберенә үзенә махсус рухани-

лардан гыйбарәттер. Мәхәллә эксәрият илә бер карья җәмәгате улып, руханилары ләәкалле бер имам, бер мөәзин улыр.

9. Һәр мәхәллә үзенең тәшкиле дәкыйкасында җәмәгать арасыннан мөтәвәллилек өчен инабәтле өч адәм интихаб итеп, мәҗлес васитасы илә баш идарә тәсдыйкына тәкъдим итәр.

Мөтәвәллилек мәсҗед, мәктәп, мәдрәсә вәкыфларын идарә итеп; мәктәпнең, мәсҗеднең руханиларның җәмәгать тарафыннан илтизам кылынмыш нәфәкаларын тәэмин итәр.

Мөтәвәллилек иске мәхәлләләрнең дә һәрберендә, әлбәттә, тәэсис кылыныр.

## III
## Рухани идарәләрнең хокуклары, вазифалары

10. Мөселманнарның рухани идарәләре дәүләт идарәләре кыйтарында [рәтендә], мәркәз һәм вилаять идарәләренә закон куәте илә виреләчәк хокукларның, имтиязларның һәрбере илә истифадә итәр.

(Законнар мәҗәлләсендә 2 нче томда вилаять идарәләре хакында низамнар).

11. Баш идарә – собрание һәммә дини мәсьәләләрне шәригате исламия хөкемнәренә муафыйк кылмак шарты илә, катгый һәм ниһая сурәттә хәл итәр. Үзе бөек вилаятьләрнең надзорына табигъ улмак җәһәтендә биля васита я хөкемран Сенатка, я дахилия назаратына табигъ улыр. Шул табгыят ялгыз ихтисаб [хисап бирү, отчет бирү] юлы илә улып, рәһбәрлек [җитәкчелек] тарикы илә улмас.

12. Собрание, баш идарә улмак сыйфаты илә бәрабәр, һәммә мөселманнарның баш мәхкәмәләредер. Үзенә табигъ руханиларның, рухани идарәләрнең һәммәсенә риясәт итәр, рәһбәрлек итәр; вазифаларын, хезмәтләрен ифа итмәмәкләре хосусларында ихтисаб итәр; косурлары булыныр исә, мәсьүлиятькә [җаваплылыкка] дәгъвәт итәр; мөнасиб җәзаларын да тәгаен итәр. Карарларын, хөкемнәрен үзенә табигъ органнар васитасы илә яхуд вилаят, уезд, волость администрацияләре куәте илә тәнфиз итәр [өстенә йөкләнгән вазифаларын үтәр]. Әгәр дә собрание карары, низами мәхкәмәләрнең карарлары кабилиятеннән улып, мәсәлән: мал түләмәк, мал кайтармак кеби эшләрне адәмнәрнең беренә илзам кеби хөкемнәрдән гыйбарәт улыр исә, бу илә сурәтләрдә ике тарафның бере разый улмаса, собрание һәрберенә карарнамә виреп, тәнфиз иттермәк өчен низами мәхкәмәгә мөрәҗәгать итәр.

13. Вилаять мәҗлесләре дә һәйәт көллиядән гыйбарәт улып, урта идарә улмак сыйфаты илә дә баш идарәгә биля васита табигъ улып, үз даирәсенә дахил мәхәлләләргә руханиларына биля фасла нәзарәт итәр. Урта мәхкәмә улмак сыйфаты илә мәхәллә руханиларының карарларыннан хәлләреннән хәрәкәтләрдән халыкның шикаятьләре хосусларында истинаф мәхкәмәсе улыр.

14. Вилаять мәҗлесләренең һичбер карары ниһая улмас, наразый тараф һәрбер хосуста баш идарәгә шикаять итә булыр. Идарәи милкия эшләрендә (ягъни административный эшләрдә),

идарәи малия (ягъни хозяйственный эшләрдә), вәкыфларга нәзарәт тәдбирләрендә, вәкыф я мәхәллә мөтәвәллиләрен ихтисаб хосусларында, мәктәп-мәдрәсәләрдә тәгълим-тәрбия вазифаларында вилаять мәҗлесләренең рәиләре, карарлары булыныр исә, тәнфиздән мөкаддәм, собрание мәхкәмәсенә, нәзыйрына тәкъдим итәрләр.

Вилаять мәҗлесләре һәрбер хосуста баш идарә тәгълиматына муафыйк хәрәкәт кылып, үзенең карарларын тәнфиз җәһәтләрендә баш идарә хокукларына, вазифаларына малик улыр.

15. Вилаять мәҗлесләре, дәүләт идарәләре кыйтарына дахил улып, рухани-дини һәм дә тәгълим-тәрбия эшләрен идарә хосусларында уезд идарәләренә мөсави улыр. Хөкүмәт идарәләренә, вилаять идарәләренә ялгыз собрание васитасы илә мөрәҗәгать итә булыр. Җәбрән [ирексезләп, көчләп] тәнфиз итмәк хаҗәт сурәтләрдә вилаять мәҗлесләре үзләренең карарларын собрание нәзыйрына тәкъдим итәр. Уезд, волость, карья начальстволары илә вилаять мәҗлесләре биля васита мөгамәлә итәр, мәҗлеснең мәшруг таләбәләрен тәнфиз җәһәтләрендә ул начальство мөсагадә (содействие) итәр. Ләкин идарәсе үзенә тиеш хезмәтләрне мәҗлес гражданский властьларның һичберенә тәклиф итмәс.

16. Баш имам мәхәлләдә рухани идарә улмак сыйфаты илә, җәмәгатьнең рухани-дини бөтен хаҗәтләрен әда итәр. Гыйбадәтләре, дини рөсүмнәре, хаҗәтләре әда хосусларында имам мөстәкыйль улыр, һәм дә җәмәгатьнең рухани хакимнәре улып; собрание, вилаять мәҗлесе, мөфти, казый тәгълиматы илә хәрәкәт итәр. Идарә хокуклары җәһәтендә мәхәллә руханилары, карья идарәләре дәрәҗәсендә улыр.

17. Мөселманнарның рухани идарәләренең һәммәсендә һәр хосуста лисан төрки улыр. Рухани идарәләренең мөһерләре һәм рус һәм төрки лисаннарда язылыр.

## IV
## Рухани идарәләренең нәзыйрына гаид эшләр

18. Түбәндә бәян кылыначак эшләрне биля истигъмаль үз ихтыярлары илә идарә итмәк хокукы – мөселманнарның рухани идарәләренә махсус улыр:

а) гыйбадәтләр тәртибе, гомумият илә сөннәт динияләр,

б) рухани хаҗәтләре ифа итмәк,

в) шәригате исламия хөкемнәренә муафыйк никахларны гакыд итмәк [сүз бирешү], хаҗәт улыр исә, талак икънаг итмәк [ризаландыру] хокуклары; шәригате исламия хөкемнәренә һичбер җәһәт илә тәхдид [чикләү] булынмамык шарт илә;

**Кайд** [беркетү, теркәү]: шул көнге закон статьяларында һәм дә редакционная комиссия проектларында вар тәхдидләрнең һәрбере алга кылыныр.

г) никах, талак, вилядәт, вафат хосусларын забыт [язып кую, теркәү] итмәк өчен метрика дәфтәрләре тотмак. Буңа гыйлавә [өстәмә, кушымта] духовный консистория уставының 265 нче статьясы илә Православный епархиальный ведом-

стволарга вирелмеш тәфтиш хакы мөселманнарның рухани идарәләренә дә виреләчәк[1];

д) гаилә низагларын фасыл итмәк (мәсәлән: мөһер, нәфәка, балалар нәфәкасы; никах хөрмәтенә, никах хокукларына ригая хосуслары), шәригате исламия ысулына муафыйк сурәттә мирас, васыять мәсьәләләрен хәл итмәк;

е) бар мәхәлләләргә нәзарәт итмәк, мәхәллә эшләренә тәртип вирмәк; яңа мәхәлләләрне ачмак, идарә итмәк; мәсҗедләргә, гыйбадәтханәләргә, каберстаннарга нәзарәт итмәк;

ж) руханиларга, рухани идарәләргә нәзарәт итмәк;

з) мәхәлләләргә руханиларны хәзерләмәк хосусларында иһтимам [кайгырту] итмәк, руханиларны имтихан итеп, мәнсабларына [хезмәт урыннарына] тәсдыйк итмәк;

и) руханиларның интихабларына нәзарәт итмәк, интихаб эшләрен тәфтиш итмәк;

к) мәктәп, мәдрәсә, мәсҗед биналарына мөсагадә итмәк, тәгъмир (төзәтү) эшләренә рөхсәт итмәк;

л) мөселманнарның дини, рухани хаҗәтләрен тәэмин намына сәрмаяләр тәдарек итмәк [хәзерләү, эзләп табу]; әһле исламның ваҗиб садакаларын, зәкятләрен, хәйратларын бәйтелмалда җәмигъ итеп, хифзы итеп, дини-милли хаҗәтләр юлына сарыф итмәк; әһле исламның вәкыфларын тәэсис кылып, хифзы итеп, идарә итеп тәгаен кылынмыш җәһәтләренә сарыф итмәк.

м) ислам балаларын динимилли рухта тәрбия вазифаларына иһтимам итмәк; ятимнәрне, ләкытларны (ташландык балаларны) тәрбия итмәк; шәригате исламия фәрманы илә фарыз кылынмыш мәҗбүри мәҗанән [түләүсез, буш] тәгълим гомуми вазифаларын фигълиятькә [тормышка] чыгармак өчен һәр җирдә һәр нәүг мәктәп-мәдрәсә ачмак, һәрберенә заманның мәкяннең [торган җирнең] хәленә күрә программ тәртип итмәк.

о) мөселманнарның низагларын солых юлы илә тәфтиш итмәк фасыл итмәк хокукы.

## V
## Баш идарәи рухания икътидарына гаид эшләр

19. Баш идарә – собрание үзенә гаид эшләрне мөхакәмә хосусында, өч һәйәттән гыйбарәт улыр, бере – гомуми һәйәт, дигәрләре – шөгъбә һәйәтләр.

Югары маддәдә бәян кылынмыш эшләрдән гомуми һәйәт икътидарына шул эшләр гаид улыр:

– гыйбадәт хосусларынамы, мөгамәлә бабларынамы да мөтәгалликъ гомуми мәсьәлә диниятләр, исламият гакыйдәләрен, тәгълимнәрен пакьлектә,

[1] Бер адәмнең вилядәте метрикә дәфтәренә кайд кылынмаеп калмыш исә, яхуд метрикәдә бер иштибаһ (шикләнү) булыныр исә, мәсәлән: көннәрдә, айларда тәфавет (аерма) кеби, яхуд үзенең я ата-анасының исемнәрендә башкалык кеби, яисә сөйләнеп мак шөбһәсе кеби сәбәпләрдән метрикәдә бер иштибаһ чыгар исә, метрикә дәфтәрен төзәтмәк, ата-анасыннан ул адәмнең нәсәбен мәгълүм мөгаен тариклар илә исбат итмәк хакы Духовный консистория уставының 265 нче статьясы илә Православный епархиальный ведомстволарга вирелмештер.

сафлыкта сакламак вазифалары, мөселманнарның гаилә хәятләрен, иҗтимагый хәлләрен исламият әдәпләренә, шәригать ысулларына тәүфыйк чаралары.

– Үзенә табигъ руханиларны, рухани идарәләрне ихтисаб эшләре, вазифаларында косурлары сабит улмыш руханиларны, рухани идарәләрне мәсъүлиять тәхетенә алмак ихтыяры.

– Гомуми һәйәт руханиларга шул җәзаларны тәгаен итә булыр: газел [урыннан төшерү], мувәкъкать [вакытлыча] газел, һәйәт хозурына дәгъвәт итеп тәлкыйн [төшендереп сөйләү, аңлату], гыйтаб [шелтә, орышу], тәнбиһ [кисәтү, искәртү].

– Мөдәррис, хатип, имам, мөгаллим, мөәзинлек дәрәҗәләренә имтихан итеп шәһадәтнамә виреп, һәрберен әһлиятенә күрә мөнасиб мәнсабларына тәсдыйк итмәк.

– Мөфти, казый, собрание әгъзаларын, мәҗлес рәисләрен, мәҗлес әгъзаларын интихаб эшләренә нәзарәт итмәк, бүленер исә шикаятьләрне тәфтиш итеп истинаф итмәк, интихаб кылынмыш кандидатларны тәсдыйк итмәк.

– Хөкүмәт я җәмәгать идарәләренең, мәэмүрләренең, хосусый адәмнәрнең мөһим мәсьәләләрдә таләпләренә, истифталарына җавап язмак, фәтва вирмәк, сәнәд [документ] вирмәк.

**Кайд:** китабе фикъһиядә ихтилафлы мәсьәләләр хакында собрание карары җиде әгъзадан гыйбарәт гомуми һәйәттә булынмак шарттыр.

– Үзләренең икътидарларына дахил эшләре мөхакәмә итәр икән, собрание шөгъбәләрендә ихтилаф чыгар исә, яхуд иштибаһ улыр исә, яисә шөгъбәләрнең карарларыннан ике тарафның бере разый улмас исә, ул илә эшләр гомуми һәйәт хозурында мөзакәрә кылыныр.

– Хөррият йортлары тәэсис итмәк гаризалары хакында кара вирмәк гомуми һәйәтнең вазифасыдыр. Ятим балаларны тәгълим-тәрбия өчен, картлык хасталык сәбәбе илә гаҗиз калмыш адәмнәрне, хезмәттән гаҗиз улып истигъфа итмеш руханиларны, тол хатыннарын, гаиләләрен һәм дә фәкыйрьлектә вафат улмыш руханиларның гаиләләрен тәрбия, тәэмин өчен чаралар тәдбир итмәк хосуслары да гомуми һәйәтнең вазифасыдыр.

– Мәктәп-мәдрәсәләрне идарә итеп ихтисаб итмәк хосусларында нәзарәт галия гомуми һәйәтнең икътидарына махсустыр.

– Гомуми һәйәт мәгърифәте илә тәртип кылынмыш программ юлында, рухани идарәләрнең яһәфтәлек, я айлык органнарын нәшер итмәк.

## VI
## Баш идарә шөгъбәләренең эшләре

20. Баш идарә собраниедә ике шөгъбә улыр.

21. Әүвәлге шөгъбә мөдәррис, хатип, имам, мөгаллим, мөәзин дәрәҗәләренә имтихан итеп, әһлиятьлеләренә шәһадәт вирер.

22. Яңа мәхәлләләрне ачмак, иске мәхәлләләрне тәкъсим итмәк, мәсҗедләрне бина итмәк, төзәтмәк хосусларына мөсагадә вирмәк, мәхәллә каберстаннарына нәзарәт итмәк әүвәлге шөгъбә вазифасыдыр.

23. Мәктәп-мәдрәсәләр һәммәсе собрание шөгъбәләре арасында улыр. Буңа күрә шөгъбәләргә шул вазифалар мөтәрәттиб [тәртипләнгән] улыр:

– мөселманнар хаҗәт кадәр һәр нәүг мәктәп, мәдрәсәләр тәэсис итеп, нәфәкаларын тәэмин хосусларында чаралар тәдбирләр итмәк;

Мәктәп-мәдрәсәләргә нәзарәт итмәк һәр җәһәт илә:

а) мәктәп-мәдрәсәләрне тәэсис итеп, нәфәкаларын тәэмин итмәк өчен махсус сәрмаялар тәшкил итмәк, дәүләт хәзинәсеннән хисса [өлеш, пай] алмак юлы илә, мөселманнарның хосусый хәйратларын хифзы итмәк [саклау], сарыфларын нәзарәт итәмәк;

б) мәктәп-мәдрәсә сәрмаяларын ихтыяҗларына күрә мәктәп-мәдрәсәләргә тигез тәүзигъ итмәк [тарату, бүлеп бирү];

в) мәктәп-мәдрәсәләрдә тәгълим-тәрбия ысулларының ислахына сәгый итмәк [бирелеп эш артыннан йөрү];

г) дәрес китапларын интихаб итеп тәгаен итмәк, мөфид китапларны тәэлиф итеп нәшер итмәк чараларын күрмәк, мәктәп-мәдрәсәләр өчен тәгълим әсбаблары хәзерләмәк;

д) мәктәп-мәдрәсәләрдә сыйххия [сәламәтлекне саклау] җәһәтләренә иһтимам итмәк;

е) шәкертләрнең, мөгаллимнәрнең истикамәтләренә нәзарәт итмәк, әсбаб мәгыйшәтләрен тәэмин итеп тормышларын гүзәлләштермәк;

ж) мәктәп-мәдрәсә сыйныфларын тәмам итмеш таләбәләрне имтихан итеп әһлиятләренә күрә шәһадәтнамәләр вирмәк өчен имтихан комиссияләре тәшкил итмәк.

24. Хәйрат җәһәтләренә тәгаен кылынмыш вәкыфларны, мәнкуль, гайре мәнкуль милекләрне ваҗиб садакалардан, хосусый иганәләрдән, ихсаннардан тупланмыш малларны хифзы итеп, тәүфир итеп [күбәйтеп, арттырып], тәгаен кылынмыш җәһәтләренә сарыф итмәк шөгъбәләрнең вазифасыдыр:

– бу илә милекләрнең махсус дәфтәрләрдә бөтен тәгаен кылынмыш җәһәтләрен күстәреп, мөфассал каимәләрен [баганаларын] – реестрларын тотмак;

– бу илә милекләрне кабул итмәк өчен дахилия назараты васитасы илә, хаҗәт улыр исә, рөхсәт шаһанә алмак;

– һибә [бүләк, буш бирү] васыять кеби ихсан сурәтләрендә милекнең рухани идарәләр тасрифына интикалый [күчереп урнаштыру] хосусында закон нәзарында могтәбәр рәсми вәсика [нигезле дәлил, документ] милкияләр гакыд иттермәк [сүз бирешү], ул вәсика милкияләрне иһтимам илә хифзы итмәк;

– ул милекләрне рухани идарәсе васитасы илә хифзы итмәк файдаларын җәмгъ итеп [җыеп, туплап] җәһәтләренә сарыф итмәк;

– бу илә милекләр мөтәвәллиләр яхуд рухани идарәләр кулында булыныр исә, сарыф дәхел җәһәтләрендә ул мөтәвәллиләрне, ул идарәләрне ихтисаб итмәк;

– шул милекләргә гаид мәхкәмә дәгъвалары хакында имин вәкилләр, наибләр [урынбасарлар]

икамәт итмәк [бер урында тору, яшәү];

– зәкят һәм ихсаннардан тупланмыш сәрмаяларны идарә итмәк.

1. Метрикә дәфтәрләрен хәзерләмәк, мәхәллә руханиларына тәүзигъ итмәк, кайтмыш нөсхәләрен архивта сакламак, дөрестлекләренә иһтимам итмәк, метрикә дәфтәрләре хакында имамнарны ихтисаб итмәк, икенче нөсхәләренең үзенә мөтәгалликъ вәсикалар илә тупланмыш мөбәллигълар [тапшырылган эшне җиренә җиткереп эшләүчеләр] илә бәрабәр вакытлы игадә [кире бирү, кайтару] кылынмакларына иһтимам итмәк.

2. Сайланмыш мөтәвәллиләрне тәсдыйк итмәк, мәхәллә мөтәвәллиләрен ихтисаб итмәк.

3. Икенче шөгъбә икътидарына шул эшләр гаид улыр:

– никах-талак низагларын, шикаятьләрен фасыл итмәк, гаилә хокукларына, вазифаларына даир дәгъваларны хәл итмәк;

– никахны я тәсдыйк, я фәсех итмәк;

– ирләрнең талакларын тәсдыйк итмәк, зарурәт сурәтләрендә талак икагъ итмәк;

– лиган [бер-береңә ләгънәт әйтешү] кеби, гыйнниңлек [ирлек куәте булмаган] кеби гозерләр [сылтау, сәбәпләр] сурәтендә яхуд озын мөддәт мәфкудиять [югалып тору], гаиблек [юкка чыгу] кеби гозерләрнең сөбүте [чынлыгы, шиксез барлыкка килүе] сурәтендә, яхуд нәфәкадан [алименттан] баш тартмак сурәтендә хатыннарның таләбе илә тәфрикъ итмәк [аеру].

**Кайд:** шул фикърәдән [аерым бүлек, пункт] бәян кылынмыш гозерләргә күрә тәфрикъ имамнарның, мәҗлесләрнең икътидарыннан тыш улып, баш собрание васитасы илә шөгъбәләргә вирелер.

– талак соңында никах хокукларына даир дәгъваларны фасыл итмәк. Мәсәлән: талак соңында хиссана мәсьәләләре, балаларның нәфәкаларына даир дәгъвалар; талак соңында милек хокукларына, мөһер, нәфәка кеби мал дәгъваларына даир низаглар.

4. Шәригате исламия ысулларына муафыйк сурәттә мирас хиссаларын мәхәкъкак [ачык, хаклыгы ачылган, шөбһәсез] варислары арасында тәкъсим итеп хиссаларының сәнәдләрен вирмәк.

5. Мәгълүм ата-анадан балаларның нәсәб мәсьәләләрен исбат итмәк.

## VII
## Вилаять мәҗлесләре. Хокуклары, вазифалары

6. Мәхәллә руханиларына вилаять мәҗлесләре нәзарәт итәр, һәммә вазифаларын үз вакытларында әда итеп, җәмәгать бөтен хаҗәте динияләрен кәмале илә ифа итмәк хосусларында.

7. Лязим урыннарда мәсҗедләр бина итеп, нәфәкаларын тәэмин итмәк, иске мәсҗедләрне тәгъмир итмәк, яңа мәхәлләләр тәэсис итмәк, хаҗәт улыр исә иске мәхәлләләрне тәкъсим итмәк, җәмәгатьләрне мәхәлләләргә тигез тәүзигъ итмәк, мәхәлләләрдә әдәби, дини хәятнең интизамына иһтимам итмәк, мәхәллә руханилары илә җәмә-

гатьнең гүзәл мөгамәләләренә сәгый итмәк.

8. Мәхәлләләргә руханилар тәгаен итмәк һәм дә мәсҗед бина иттермәк хосусында вилаять мәҗлесләре: мөзакәрә өчен җәмәгатне күмәләргә (сохудларга) дәгъвәт итә булыр; күмәләрдә җәмәгатьнең иттифакы илә кабул кылынмыш карар мәҗлес тасрифына вирелер; мәҗлес һәйәте ул карарны һәр җәһәт илә мөзакәрә итеп, вилаять я область правлениеләренең гыймарәт [төзелеш] шөгъбәләренә мәсҗеднең фараз кылынмыш планнарын тәкъдим итеп, гакыйбәт [соң, ахыр, нәтиҗә] баш идарә собрание нәзыйрына тәслим итәр; мәхәллә руханиларын интихаб хосусында җәмәгатьнең интихабына да бөтен мәгълүмат лязимия тупладыктан соң вилаять мәҗлесләре, собрание кулына тәслим итәр; мәҗлесләрнең, гыйбадәтханәләрнең, каберстаннарның мәгъмүрлыкларына [төзекләндерелүенә], пакьлекләренә вилаять мәҗлесләре иһтимам итәр. Мәхәллә руханиларының я җәмәгать шул хосуста косурлары, мөсаһәләләре [әһәмият бирмәүләре] вар исә, вилаят мәҗлесләре вәгазь юлы илә тәнбиһ [кисәтү, искәртү] итәр; хаҗәт улыр исә, гражданский властьларга да мөрәҗәгать итә булыр.

9. Үз районнарында булыныр мәктәп-мәдрәсәләргә вилаят мәҗлесләре һәр җәһәт илә нәзарәт итәр, лязим җирләрдә мәктәп-мәдрәсә тәэсис итеп, нәфәкаларын тәэмин итмәк юлында сәгый итәр, мәктәп-мәдрәсәләрдә дәресләрнең интизамына матлуб сурәттә дәвамына һәрвакыт иһтимам итәр, гүзәл мөгаллимнәрне, моктәдир мөдәррисләрне мәктәп-мәдрәсәләргә хәзер итәр; мөгаллимнәрнең, мөдәррисләрнең истикамәтләренә нәзарәт итеп, шәкертләрнең дә сыйххия җәһәтләренә, әдәпләренә һәрвакыт нәзар итәр; мәктәп-мәдрәсәләр, мөгаллим-мөдәррисләр, шәкертләр хакында мөфассал [тулы, җентекле] мәгълүматны собрание нәзыйрына тәкъдим итеп, собрание иршады [юлга салуы, указаниесе, инструкциясе] илә һәрвакыт хәрәкәт итәр.

10. Мәктәп-мәдрәсә, мәсҗед, мәхәллә, тәрбия йортлары кеби җәһәтләргә вәкыф кылынмыш мәнкуль, гайре мәнкуль милекләрне идарә хакында вилаять мәҗлесләренең вазифалары, хокуклары собрание вазифалары, хокукы кадәрдер. Ул милекләрнең һәрбере хакында мөфассал регистрлар – рәсми дәфтәрләр тотып, хифзы итеп, галләләрен [керемнәрен] тәгаен кылынмыш җәһәтләренә тугрылык илә, иманәт илә сарыф итмәк хосусларына там иһтимам илә нәзарәт итәр. Ул милекләрнең сарфияты [чыгымнары], галләләре хакында собрание нәзыйрына мөфассал мәгълүмат тәкъдим итеп; мөтәвәллиләрнең, назарларның хәрәкәтләре һәрбер косурлары хакында биля тәэхир [кичектермичә] собрание идарәсенә хәбәр виреп торыр. Әүкаф идарәсе хосусларында собрание тарафыннан виреләчәк әмерләрне, тәгълимнәрне тәмамы илә ифа итәр.

11. Вилаять мәҗлесләре мәхәллә мөтәвәллиләрен мәхәллә эшләре хакында, мәхәллә милекләре хакында нәзарәт итеп

ихтисаб итәрләр. Мәхәллә руханилары илә мөтәвәллиләре арасында бер шәй чыгар исә, вилаять мәҗлесләре үз ихтыярлары илә мөдахәлә [катышу, арага керү] итмәеп, һәр дәфгада собрание ишарәсе илә хәрәкәт итәрләр.

12. Вилаят мәҗлесләре руханиларның мәхәлләдә һәрвакыт хозурлары хосусларында нәзарәт итәр, мәхәлләләрнең озын мөддәт руханиларсыз калмамыклары хакында да иһтимам итәр. Мәхәллә руханиларына зарурәт икътизасы илә ике һәфтәдән артык мөсамәхә [игътибарсызлык] хаҗәт улыр исә, бер айдан зиядә улмамык шарты илә вилаять мәҗлесләре мөсамәхә вирә булыр, бер айдан зиядә улыр исә, собраниедән изен [рөхсәт] таләп итәр.

13. Метрикә дәфтәрләре тотмак, сәнәд кәгазьләре вирмәк; вилядәт, вафат, никах, талак кеби ифа кылынмыш эшләрнең һәрберен үзләренең сәгатьләрендә язмак мәхәллә руханиларының вазифалары исә дә, мәхәллә руханиларын шул вазифалары хосусларында вилаять мәҗлесләре ихтисаб итә белерләр, мөсаһәләләре вар исә, тәнбиһ итәрләр; косурлары чыгар исә, тәдарек [хәзерләү, эзләп табу] итәрләр. Шул вазифаларында руханиларның косурлары яхуд хыянәтләре хакында мәгълүмат җәмгъ итеп үзләренең мөляхәзәләре илә бәрабәр собрание нәзыйрына тәкъдим итәрләр.

14. Мөфти сайламак мәсьәләсендә вилаять мәҗлесләренең иштиракы шул тарика улыр: собраниедән интихаб сәгате хакында хәбәр алдыктан соң, вилаять мәҗлесе мәхәллә идарәләренә вәкилләр сайламак хакында хәбәр вирер; вәкилләрнең мөгаен көндә иҗтимагълары өчен бер мәркәз тәгаен итәр; мәҗлес үз тарафыннан бер я ике әгъза күндерер; вәкилләрнең вәкиллек шәһадәтләрен тәфтиш итәр; дәгъвәт кылынмыш вәкилләрнең өченнән ля әкалле ике кыйсеме хәзер улыр исә, интихаб съездын ачар; бер рәис интихаб иттереп, ябык ысудла сайлаучыларны интихаб итәрләр. Рәи вәкиллек гадәде игътибар илә улмаеп, мәхәлләләрнең гадәде игътибары илә улыр.

15. Никах, талак хокукларына мөтәрәттиб [төзелгән, тәртипкә салынган] мал низаглары хосусында, варислык хокуклары, тәрикә [үлгән кешедән калган мал, мирас] тәкъсимнәре хосусларында вилаять мәҗлесләре урта дәрәҗә мәхкәмә улыр. Буңа күрә шул мәсьәләләрнең һәммәсе башта мәхәллә руханилары хозурында тәфтиш кылыныр: талак мәсьәләләре хатын мәхәлләсендә, варислык хокуклары мирас мәхәлләсендә тәфтиш кылыныр.

16. Бу югарыда 39 нчы маддә бәян кылынмыш мәсьәләләр мәхәллә руханилары хозурында тәфтиш кылынып, фәтвалары тәгаен кылындыктан соң вилаять мәҗлесләренә тәкъдим кылыныр, мәсьәләләрне яңадан тәхкыйк итмәк өчен. Ике тарафның бере мәхәллә карарларыннан шикаять итәр исә, тәфтиш соңында вилаят мәҗлесләре үзләренең карарларын ике тарафның һәрберенә игълам итәр. Мәсьәләләрнең яңадан тәфтиш өчен вилаят ьмәҗлесләре, лязим улыр

исә, ике тарафның шаһитларын, мәхәллә руханиларын дәгъвәт итә белер. Мәхәллә руханиларының карарлары шәригате исламия ысулларына муафыйк чыгар исә, вилаять мәҗлесләре тәсдыйк итәр; мохалиф [охшашмаган] чыгар исә, яхуд хыянәтләре заһир улыр исә, вилаять мәҗлесләре ул мәсьәләләрне бөтен мәгълүматы илә бәрабәр собрание нәзыйрына тәкъдим итәр.

17. Икенче дәфга тәфтиш кылындыктан соң, мәҗлеснең карары ике тарафның һәрберен разый итмәс исә, наразый тараф бер ай эчендә мәсьәләне собрание нәзыйрына тәкъдим итә белер. Бер айдан соң карар куәте шәргыя кәсеп итеп нафиз [эчкә керә торган] улыр да, шикаять хакъкый сакыт [юкка чыгучы] улыр.

18. Куәте шәргыя кәсеп итмеш карарны тәнфиз [үтәү] хосусында мәҗлес собрание кеби хәрәкәт итәр: мәҗлес үзенең карарын мәхәллә руханиларына игълам итәр; мәхәллә руханилары ул карарларны метрикә дәфтәрләренә кайд итәрләр, ике тарафның һәрберенә сәнәд кәгазе вирерләр вә волость я карья правлениеләренә дә хәбәр вирерләр. Ике тараф таләп итәр исә, карарның копияләрен дә вирерләр. Ике тарафның бере үз ихтыяры илә карарны ифа итмәс исә, гражданский власть мөсагадәсенә мөрәҗәгать кылына булыр.

19. Никах хөрмәтенә, гаилә адәпләренә тәгадиләре [рәнҗетүләре, хаксызлык итүләре] хосусларында зәүҗләрнең [хатынның иренең] шикаятьләре, вәлиләренә [опекуннарына] балаларның итагатьсезлекләре [буйсынмаулары], дини мәхкәмә улмак сыйфаты илә мәҗлестә каралыр. Ләкин зәүҗләр, вәлиләр шикаять итмәдекчә бу илә эшләр һичбер вакыт тәфтиш кылынмас. Шикаять вакыйг [чын] улыр исә, буның илә иктифа [канәгатьләнү] итәрләр. Әгәр дә ялгыз вәгазь матлуб файдаи тәэмин итмәс исә, яхуд ике тарафның берендә җинаять мәхкәмәләренә гаид гөнаһ булыныр исә тәфтишнең бөтен нәтиҗәләре мәхәлли прокурорның ихтыярына тәслим кылыныр.

## VIII
## Мәхәллә руханияларының вазифалары, хокуклары, икътидарлары

20. Мәхәлләдә рухани идарә баш имамнан гыйбарәт улып, шул вазифаларны ифа итәр: 1) мәсҗедләрдә гыйбадәтләрне әда итәр, 2) мөселманнарны җәмәгать намазларына гадәтләндереп, адәпле истикамәтле хәят юлларына иршад итеп, үз эшләрендә иҗтиһад рухларын мөселманнарның һәрберенә тәлкыйн итеп [төшендереп сөйләп, аңлатып], ислам адәпләрен, шәригатьнең хөкемнәрен, дәүләтнең кануннарын, низамнарын ригая итмәк [кайгырту, карау] вазифаларына мөселманнарны гадәтләндерер, 3) метрикә дәфтәрләрен тотып хифзы итәр, метрикә шәһадәтләрен вирер, рухани идарәләрне тәэмин өчен тәгаен кылынмыш виргүләрне алып мөгаен вәгъдәләрдә мәхәлләне тәслим итәр; 4) вилядәт хадисәләрен иһтимам илә

забыт итәр, яңа тумыш балаларга исем вireп метрикә дәфтәренә кайд итәр; 5) мәетләрне шәригать тәгълименә мөнасиб сурәттә ихтирам илә дәфен итеп, вафат хадисәләрен иһтимам илә забыт итәр, метрикә дәфтәренә кайд итәр; 6) шәригате исламия хөкемнәренә һәр җәһәт илә муафыйк сурәттә никахларны гакыд итеп, ике тарафның мокавәләләрен [килешү, сүз бирешүләрен], шорутларын тәфсыйлат илә метрикә дәфтәрендә кайд итәр. Никах хосусларында һәм шәригатьнең хөкемнәрен һәм законның низамнарын ригая итмәк руханиларга, әлбәттә, лязимдер. Я шәригать, я закон нәзарында мәмнугъ [тыелган] никахларны гакыд итмәк җаиз улмас. Мәсәлән: ике тарафтан беренең яше тулмаса, яхуд ризасы катгый сурәт илә мәгълүм улмаса, яхуд рухани хаста исә; 7) талак хадисәләрен иһтимам илә забыт итеп, метрикә дәфтәренә кайд итмәк; 8) гозер шәргый сабит улыр исә, хатынның таләбе илә талак икагъ итмәк.

**Кайд:** югарыда 27 маддәдә 4 нче фикърәдә [аерым бүлек, пунктта] бәян кылынмыш гозерләр хисабы илә тәфрикъ хакы ялгыз баш идарә собрание икътидарына махсус улып мәҗлесләрнең, имамнарның икътидарларыннан хариҗдыр [тышкы, чыгучыдыр].

9. Никах гакыдларына мөтәрәттиб [төзелгән, тәртипкә салынган] бөтен таләпләрне, талак хосусларына мөтәрәттиб бөтен дәгъваларны, шикаятьләрне башта тәфтиш итмәк мәхәллә руханиларының вазифаларыдыр. Шул хосусларда шәригате исламия хөкемнәренә һәр җәһәт илә муафыйк карарларын мәхәллә руханилары ике тарафның һәрберенә игълам итеп, биля тәэхир мәҗлес нәзыйрына тәкъдим итәр. Ике тарафның береннән мәхәллә руханиларына шикаять вирелсә, үзенең карары илә бәрабәр наразый тарафның шикаяте дә бер һәфтә эчендә мәҗлес нәзыйрына гарыз кылыныр.

10. Шул хосусларда мәхәллә руханиларының карарлары муафыйк улып, бер ай эчендә ике тарафның береннән шикаять тәкъдим кылынмаса нафиз улыр. Ләкин гыйддәт [ирсез калган хатынның икенче иргә бармый торырга тиешле булган вакыты] хисабы карарның әүвәлге дәкыйкасыннан игътибар кылыныр.

11. Бер ай эчендә заһир улмаса вилаять мәҗлесе дә имамның карарын тәбдил [үзгәртү, алмаштыру] кылмаса, имамның карары тәнфиз кылыныр. Әгәр дә вилаять мәҗлесе имамның карарын тәбдил итәчәк улыр исә, гыйддәтнең инкыйзасына [срогы бетүгә] кадәр хәбәр вирмәк зарур улыр.

12. Балалар әүзәрендә вилаять хокукларына, балаларны тәрбия вазифаларына, хатыннарның нәфәкаларына, мөһерләренә, милекләренә, мирас хокукларына, тәкъсим тәрикә [үлгән кешенең мирасын бүлү] хосусларына даир дәгъвалар, низаглар; талак я вафат соңында чыгар исә, ике тарафның мөрәҗәгатенә күрә яхуд идарәләрнең, мәэмүрләрнең таләпләренә күрә, мәхәллә руханилары ул дәгъваларны, гаризаларны тәфтиш итеп, үзләренең мөляхәзәләрен, фәтваләрен

вирерләр. Ләкин мәҗлеснең хваласы булынмадыкча яхуд дәгъваи дөхеле вар бөтен адәмнәрнең таләпләре мәгълүм улмадыкча, мәхәллә руханилары үзләренең карарларын вирмәсләр.

13. Мәсҗедләрне сакламак, пакьләмәк, нурламак, якмак; каберстаннарны да пакьлектә тотмак кеби хосусларда мәхәллә руханилары мөтәвәллиләргә мөрәҗәгать итәр, мәшруг таләпләрен мөтәвәллиләр ифа итмәс исә, мәхәллә руханилары кәйфияти [бер вакыйганың ничек булу сурәте] вилаять мәҗлесләренә бәян итәр.

## IX
## Собрание даирәсендә руханиларның дәрәҗәләре

21. Собрание даирәсендә руханилар мәхәллә руханилары илә бөек дәрәҗә руханилардан гыйбарәт улыр. Руханиларның бөек дәрәҗәләре: мәҗлестә рәис казый, собрание әгъзасы – казый, мөдәррис, хатип. Мәхәллә руханилары: мөгаллим, имам, мөәзин.

22. Фәрман шаһанә [махсус боерык] илә тәсдыйк кылынмыш улмак сыйфаты илә, мөфти ислам руханиларының һәм дәүләт дәрәҗәләренең иң бөекләреннән алып, аның һәм бөек хөкүмәт идарәләренең игътимадын [ышанычын, таянычын] хаиз [җыйган, эченә алган] улыр.

23. Шул сыйфат илә һәм дә милләт тарафыннан сайланмыш улмак шәрәф илә мөфти милләтнең рухани рәисе һәм дә хөкүмәт хозурында ислам вәкиле улып, император хәзрәтләренең хозур шаһанәләрендә мөселманнарның хаҗәтләренә дини мәслихәтләренә биля васита тәрҗеман әүвәлә белмәк шәрәфенә наил улыр.

24. Мөфти собраниедә баш рәис улып, дәүләтнең мәркәз идарәләрендә баш рәислек хокукларына, имтиязларына, вазифаларына малик улыр.

25. Буңа гыйлавә, мөфти үзе шул хокукларны да, вазифаларны да хаиз улыр:

а) заман сәвекъ итмеш [алга этәргән, сөргән] иҗтимагый хәят мәсьәләләреннән мөһимнәрен мөзакәрә кылып, шәригате исламия ысулларына тәүфикъ итмәк [туры китерү] өчен иҗтимаг мөэтәмәрине [җыелыш, киңәшмәне] ля экалле [иң кимендә] һәр өч сәнәдә бер дәфга дәгъвәт итмәк;

б) мәсҗедләрдә гыйбадәтханәләрдә җомга әдасенә изен [рөхсәт] вирмәк;

в) иҗтиһад итеп, үзләренең вазифаларын кәмал илә ифа итүче руханиларны император әхсаннәренә гарыз итмәк;

г) һәм мөлки [хөкүмәтнеке] мәктәпләрнең, һәм хәрби мәктәпләрнең һәрберенә дин, лисан мөгаллимнәре тәгаен итмәк;

д) вилаятьләрдә, өязләрдә, шәһәрләрдә 10 000 кадәр мөселман булыныр исә, шәһәр думаларына, земство собраниеләренә ислам руханиларыннан вәкилләр тәгаен итмәк;

е) собрание казыйларын сайламак өчен вакыт тәгаен итмәк;

50. Мөфти милләт ихтыяры илә сайланып, дахилия назыйры васитасы илә [эчке эшләр министры ярдәме белән] гарыз кылынмыш кандидатлар арасыннан император хәзрәтләренең идарә шаһанәсе илә тәгаен кылыныр.

Мөфти тугыз сәнә мөддәт илә сайланыр.

51. Интихаб тәртибе:

1) вафат улмак яхуд истигъфа [хезмәттән чыгарылган] итмәк сәбәб илә яки мөфти сайламак сәгате холүл [килеп җиткән] итәр исә, дахилия назыйрының мөсагадәсе илә собрание Уфада интихаб вакыты тәгаен итәр. Ул вакыттан өч ай мөкаддәм собрание вилаять мәҗлесләренә хәбәр бирер. Мәхәллә җәмәгатьләренә мәгълүм итмәк өчен вилаят мәҗлесләре мәхәллә руханиларына хәбәр бирерләр.

2) һәр мәхәллә халкының санына күрә я бер, я ике, я өч вәкил интихаб итәр. Мәҗлес тарафыннан тәгаен кылынмыш җирдә вакытта мәхәллә вәкилләре тупланып, үз араларыннан район вәкилләре интихаб итәрләр.

3) мәхәллә вәкилләре тәгаен кылынмыш җирдә тупландыктан соң үзләренең вәкиллек шәһадәтләрен мәҗлес рәисенә я әгъзасына гарыз итәрләр. Районда бар мәхәлләләрнең ике сөлесе [өчтән бере] вәкил күндермеш исә, съезд каим улып [бар булып торучы], казый вәкилләр съездын ачар, арадан бер рәис интихаб иттерер. Соңра шарлар илә ябык ысулда бере руханидан, бере зыялыдан улмак үзрә ике адәм сайланып һәрберен берәр кандидат интихаб кылыныр.

4) мәхәлләләр вәкилләренең иҗтимаг итәчәк җирләрен, сәгатьләрен тәгаен итеп вилаять мәҗлесләре ул җирнең начальникларына хәбәр итәрләр; ихтыяҗ йөз күстерер исә, мөсагадә итәрләр.

5) съездда сайланмыш район вәкилләренә рәислек мәҗлес әгъзаларының начальникның имзасы илә шәһадәтнамә бирелер, мөфти интихабына хәзер улмак өчен.

6) мәхәллә вәкилләре съездның һәммә эшләрен интихаб кәгазьләрен мәҗлес собрание ихтыярына тәслим итәр; бунлар исә, протестларны да, шикаятьләрне дә гыйлавә итәр.

7) район вәкилләре тәгаен кылынмыш көндә Уфа собраниесенә тупландыктан соң, шәһадәтнамәләрен собрание кулына вирерләр; хәзер улмыш вәкилләрнең хисабы алыныр; дәгъвәт кылынмыш сайлаучыларның ике сөлесе килмеш исә, съезд каим улды хисап кылынмыш; дахилия назыйрының вәкиле, Уфа губернаторы, суд прокуроры һәм дә халык хозурында Коръән кәрим укылдыкыннан соң, мөфти наибе [урынбасары] интихаб съездын ачар. Секретарь – хәзер улмыш район вәкилләренең исемнәрен укыр, соңра съезд өчен бер рәис, өч шәрик, ике секретарь сайланып эш башланыр.

8) съезд иң элек район вәкилләренең шәһадәтнамәләрен тәфтиш итәр. Бар исә, протестларны, шикаятьләрне тәдкыйк итәр [җентекләп тикшерер]. Соңра посолларга язып вирмәк тарикы илә кандидатлар тәгаен кылыныр; посолларда күстерелмеш кандидатлар арасыннан әксәрият нәүбәте илә мөфтилек мәнсабына ля әкалле өч кандидат шар ысулы илә сайланыр. Интихаб шарларын иң күп казанмыш өч адәм кандидат хисап кылыныр. Бер фарыз, арадан бере кабул итмәс исә, нәүбәттәгеләрнең бере хәләф [урынбасар] улыр.

9) съездның бөтен хезмәтләре дахилия назыйрына тәкъдим кылыныр.

## X
## Казыйлар

52. Собрание әгъзалары, мәҗлес рәисләре «казый» лакабы [кушаматы] илә тәсмия кылынып, мансабларында [хезмәт урыннарында] вазифалары илә мәшгуль икән, шул ләкабның хокукларын да, имтиязларын да, вазифаларын хаиз улмас.

## XI
## Собрание әгъзалары

53. Милләт тарафыннан алты сәнә мөддәт илә сайланмыш әгъзалар мөфти васитасы илә тәкъдим кылынып, дахилия назыйры тарафыннан тәсдыйк кылыныр.

54. Бөтен собрание даирәсе әгъзалары сайламак хосусында алты кыйсем игътибар кылыныр. Һәрбер кыйсем үз нәүбәтендә бер әгъза интихаб итәр.

55. Мөәзиннәрдән магада [башка, бүтән] руханиларның һәрбере кандидат ула булыр.

56. Әксәрият казанмыш өч кандидат мөфти тәсдыйкына тәкъдим кылыныр. Бере тәсдыйк кылындыктан соң, дигәрләре нәүбәттә кандидат улып калыр.

**Кайд:** кандидатларның тавышлары бәрабәр улыр исә, нәүбәт корга [шобага] илә тәгаен кылыныр.

## XII
## Мәҗлес рәисләре

57. Вилаять мәҗлесләренең рәисләре вилаятьнең бөтен мөселманнары тарафыннан алты сәнә мөддәт илә сайланыр.

58. Интихабның җире, вакыты мөфти мәгърифәте илә тәгаен кылыныр.

59. Рәисләре – интихаб низамы, мөфтиләре интихаб низамы кебидер. Ләкин мәхәллә вәкилләре мәҗлес рәисләрен биля васита интихаб итәрләр.

## XIII
## Мөдәррисләр

60. Мәдрәсә бар һәрбер җирдә мөдәррисләр мәхәллә руханилары кеби интихаб кылыныр.

## XIV
## Мәхәллә руханилары

61. Мәхәллә руханилары – хатип, имам, мөәзиндер. Хатип һәм имам – мәктәптә, мөгаллим – мәдрәсәдә мөдәррис ула булыр. Мәхәллә руханиларының һәрбере җәмәгать тарафынна сайланып, собрание тарафыннан тәсдыйк кылыныр.

62. Интихаб мәхәлләдә әксәрият илә булыр. Яше егермедән ашагы түгел бөтен ирләр ике сөлесе хәзер улыр исә, интихаб каим булыр. Кандидат я халык тарафыннан, я мәҗлес тарафыннан яхуд сайланучыларның үзләре тарафыннан тәкъдим кылыныр.

63. Һәммә яхуд ля әкалле ике сөлүс җәмәгатьнең таләпләре хакында мәҗлес рәисе я әгъзасы риясәте тәхетендә интихаб кәгазе тәртип кылыныр; карьяларда сельский староста, станицаларда атаман, шәһәрләрдә полиция чиновнигы хозурында улыр. Интихаб кәгазе, сайланмыш кандидатның бөтен документлары илә бәрабәр, мәҗлес васитасы илә собрание назыйрына тәкъдим өчен, мәҗлес рәисенә я әгъзасына тәслим кылыныр.

64. Шул тарика тәртип кылынмыш интихаб кәгазе волость

старшиналары, уезд, шәһәр правлениеләре кеби гражданский властьларның тәфтишләреннән югары улыр. Шикаятьләр булыныр исә, я мәҗлес, я собрание тәфтишенә күндерелер.

65. Руханиларның мәнсабларына кандидат була алмас: 1) хөкем астында калмыш, яхуд хокукларыннан мәхрүм кылынмыш адәм, 2) әҗнәби тәбәгасы [чит ил кешесе], 3) имтиханнан шәһадәтнамәсе юк адәм.

## XV
## Рухани идарәләрдә эш тәртибе

66. Собрание һәйәте көллисе – мөфти я наибе риясәте тәхетендә бөтен әгъзалардан, бер секретарьдан гыйбарәт улыр.

67. Шөгъбәләрнең һәйәте – өч әгъзадан гыйбарәт улып, бере – һәйәте көллия тәгаене илә рәис улыр. Секретарь – могавиннәренең бере, һәйәте көллия тарафыннан шөгъбәдә секретарьлык вазифаларына тәгаен кылыныр.

68. Һәйәтләрнең һәрберендә һәр мәсьәлә әксәрияте илә хәл кылыныр.

69. Һәйәте көллия тарафыннан тәгаен кылынмыш әгъзаларыннан беренең нәзарәте тәхетендә [идарәсе астында] архивариус архив эшләрен идарә итәр.

70. Һәр нәуг шәһадәтнамәләр, сәнәдләр [документлар] һәм дә башка идарәләргә, мәэмүрләргә күндереләчәк һәммә кәгазьләр, әлбәттә, русча улыр. Үзенә табигъ [буйсынучы] идарәләргә, руханиларга һәм дә гади адәмнәргә күндереләчәк язулар, кәгазьләр, гаризалар һәм русча, һәм мөселманча ула булыр.

**Кайд:** рухани идарәләрнең карарларына сәнәд улмак үзрә нәкыль кылыначак риваятьләр һәм төрки, һәм гарәби ула булыр, лязим улыр исә, русча тәрҗемәсе дә язылыр.

71. Вилаять мәҗлесләренә гаид эшләр мәҗлестә ике әгъза, секретарьлык вазифаларын әда кылучы бер кяргәр [хезмәтче] хозурында әксәрият илә хәл кылыныр.

## XVI
## Собрание назаратына табигъ мөәссәсәләр. Вәкыфлар

72. Әүкаф [вәкыфлар] – мәктәпләргә, мәдрәсәләргә, мәсҗедләргә, руханиларга; гаҗизләрнең, хасталарның, мәҗнүннәрнең, ятимнәрнең тәрбияләренә гомумият илә хәйрат максатларының беренә тәгаен кылынмыш мәнкуль [күчерелгән] я гайре мәнкуль [күчми торган] милекләрдән гыйбарәттер. Әүкаф – мотлак ула булыр, яхуд вакыйф [вәкыф бирүче] ихтыяр илә җәһәте тәгаен кылынмыш, могаен ула булыр. Әүкафның һәрберендә вакыйфның ихтыяры, әлбәттә, ригая кылыныр. Вакыйф үзенең вәкыфларына мөтәвәлли каим тәгаен итә булыр.

73. Вәкыф собрание нәзарәтенә алына булыр, әгәр дә вәкыфның җәһәте шәригате исламия ысулларына муафыйк улыр исә.

74. Җәһәте тәгаен кылынмамыш мотлак вәкыфларның һәммәсе биля васита собрание нәзарәтендә улыр. Җәһәте тәгаен кылынмыш вәкыфлар собрание органнардарәсендә собрание ихтисабы тәхетендә вәкыф шарт-

ларына муафыйк сурәттә идарә кылыныр.

75. Вәкыфларны хәйрат юлына ихсаннары кабул итмәк, идарә итмәк, сәрмаяларын, вәсикаларын сакламак, вәкыф милекләренә регистрлар тотмак, үзләрен сакламак; файдаларын, галләләрен [керемнәрен] җәһәтләренә сарыф итмәк хосусларында собрание 24 нче маддә бәянына муафыйк гамәл итәр.

76. Вәкыфларны закон нәзарение мөгтәбәр институт иттереп, рәсмиләштермәк юлларын садәләштерү хакында собрание сәгый итәр.

77. Шәригате исламия фәрманы илә фарыз кылынмыш зәкят һәм хәйрат садакаларын собрание интизам әүзәрендә идарә итәр.

## XVII
## Мәхәллә мөтәвәллиләре

78. Җәмәгать иттифакы илә җәмәгатьнең үзе арасыннан сайланмыш өч әгъзадан гыйбарәт улыр. Мөтәвәллилек бөтен мәхәллә вәкиле улмак сыйфаты илә хокук сахибы бер шәхсияте шәргыя улып, законда һәм дә шул маддәләрдә бәян кылынмыш хокукларның һәммәсе илә истифадә итәр.

79. Мөтәвәллиләр мәхәллә адәмнәреннән сайланып собрание тарафыннан тәсдыйк кылыныр.

80. Мәхәллә мөтәвәллиләре мәсҗедләрнең, мәктәпләрнең, мәдрәсәләрнең пакьлекләренә, мәгъмүрлекләренә [төзекләндерелгәнлегенә]; каберстанның төзеклегенә, нәзафәтенә, тәртибенә нәзарәт итеп, шул хакта лязим улачак тәдбирләрне күрер, мәшруг микъдарда [шәригать кушкан чамада] мал сарыф итәр.

81. Мөтәвәллилек мәсҗеднең, мәктәпнең вәкыфларын да иң мөфид юлда идарә итәр. Мөмкин кадәр иң зиядә файда алмак чараларын күрер, тәгаен кылынмыш җәһәтләренә файдаларын иң әманәтле юлда сарыф итәр, шул хакта мөфассал хисап дәфтәре тотар, хисап дәфтәрләре собрание тарафыннан вирелер. Мөтәвәллилек һәр сәнәдә бер дәфга хисап дәфтәрен бөтен вәсикалары илә бәрабәр собрание тәфтишенә тәслим итәр.

**Кайд:** вәкыфларның тәгаен кылынмыш мөтәвәллиләр мөтәвәллилектә, әлбәттә, әгъза булыр.

82. Мәхәллә хаҗәтләренә, мәхәлләдә булыныр хәйрат мөәссәсәләре намына виреләчәк ихсаннарны [ярдәмнәрне], садакаларны мөтәвәллилек кабул итәр; лязим улыр исә, могаен көннәрдә хәрат максаты намына халыктан ихтыярый ихсаннарын җәмгы итәр [җыер, туплар]; руханиларның нәфәкалары өчен, мәсҗеднең, мәктәпнең тәгъмире яхуд бинасы өчен лязим ула булачак мәбләгъ [сумма, акча күләме] җәмәгать ризасы илә тәгаен кылындыктан соң һәр адәмнең хәссасына төшәчәк микъдары мөтәвәллилек җәмәгатьтән туплар.

83. Дәхел, хәреҗ җәһәтләрен мөфассал күстермәк үзрә, мөтәвәллилек хисабы – мәҗлеснең мөһере илә тәкъвия [ныгыту] кылынмыш махсус дәфтәрләрдә кайд кылыныр. Мөтәвәллилек мәҗлеснең ихтисабы [хисап бирүе, отчет бирүе] тәхетендә улып, һәр сәнә мәхәллә җәмәгате хозурында да хисап вирер.

## XVIII
## Мәктәп, мәдрәсә

84. Рухани идарәләренең нәзарәтләренә табигъ мәктәп-мәдрәсәләр вилаят мәҗлесләренең мөсагадәсе илә мөтәвәллилек тарафыннан яхуд һиммәтле адәмнәр тарафыннан тәэсис кылына булыр. Бер мәхәлләдә берничә мәктәп-мәдрәсә ачмак мәмнүгъ улмас [тыелмас].

85. Мәктәп-мәдрәсәләрнең тәгълим-тәрбия җәһәтләре, собрание һәм мәҗлеснең рәһбәрлеге саясында; мөгаллимнәргә, мөдәррисләргә әманәт кылыныр. Әмма идарәи хариҗия җәһәтләре мәхәллә мөтәвәллилеге әманәтендә улыр. Мәктәп-мәдрәсә хосусы бер адәмнең я җәмгыятьнең һиммәте илә тәэсис кылынып, мөтәвәллилек вазифаларын мөәссисләрнең үзләре илтизам итәр исә, мөгаллимнәр һәйәте илә мәхәллә мөтәвәллилеге идарәдә иштирак итә булыр.

## XIX
## Мәсҗедләр, гыйбадәтханәләр

86. Гыйбадәт хәрәмнәре улмак шәрәф илә мәсҗедләрнең, гыйбадәтханәләрнең хөрмәтләре, кодсиятьләре һәр нәүг ихтирамсызлыктан мәхфузиятьләре – әсасы канун куәте илә химая кылыныр.

87. Лязим җирләрдә мәсҗед бинасына мөсагадә мәҗлес васитасы илә собрание тарафыннан вирелер. Мәсҗедтә ихтыяҗлары хакында җәмәгать бер иттифак кәгазе тәртип итәр.

88. Гыйбадәтханәләрнең мәсҗедләргә башкалыгы җомга әда кылынмамык ноксан иләдер. Мак өчен хосусый мөсагадә лязим улмас.

89. Мәсҗед бинасы илә мәшгуль җирләр һичбер сурәт илә изаләи [бетерү, юк итү] кабил улмас. Бер адәм үзенең җиренә мәсҗед бина итәр исә, җир ул адәмнең милекеннән чыгар; мәүкуф [вәкыф ителгән] улып җәмәгатьнең милеке улыр.

90. Мәсҗедне пакьлектә, төзеклектә тотмак, җәмәгатьнең вәкиле улмак сыйфаты илә, мөтәвәллиләрнең вазифасы улыр.

---

1905 сәнә апрель 10–15 ләрдә корылтай мәҗлесләрендә хәзрәтләр тарафыннан кабул кылынып, апрель 18 нән май 3 кә кадәр мохтәлитъ [катыш] һәйәте мәгърифәте илә ислах һәм тәрҗемә кылынмыш туксан маддәдән гыйбарәт ляихә тәрҗемәсе шулдыр (112 сәхифәдән 136 сәхифәгә кадәр).

Корылтай мәҗлесләре бәркәсендә Русия мөселманнары арасына бере дигәренең тәмам кылынып нәшер кылынды.

Ул ляихәләрнең бере – Уфа волостьлары тарафыннан сайланып, дахилия назыйрының мөсагадәсе илә Уфада тупланмыш башкорт вәкилләренең 1905 сәнә июнь 22, 23, 25 көннәрендә мәхдүм Мөхәммәтшакир әфәнде Тукай җәнапләренең риясәтендәге съездларда кабул кылынмыш ляихәдер.

«Губернское совещание» исеме илә, Уфада өч көн дәвам итмеш ул җәмгыятьтә имамнардан, старшиналардан, писарьлардан гыйбарәт йөз егермедән зиядә вәкил хәзер иде.

«Мохтәлитъ һәйәт» мәгърифәте илә иҗтиһад илә хәзерләнмеш гүзәл ляихә ул җәмгыятьнең дә бөтен мөзакәрәләренәш

улса кирәк. Гаять җөзьи тәгъйир [үзгәртү, алмаштыру] соңында җәмгыять ляихәсе бөтен маддәләре илә гайн гыйбарәсе илә (әүвәлге редакциясе илә) кабул итеп, үз тарафыннан янә 23 маддә зиядә итмеш. Әүвәлге маддәләргә гыйлавә сурәт илә ул маддәләрне дә түбәндә яздым:

91. Карьяларда бәгъзе адәмнәр эчеп-исереп әдәпсезлек итәләр, рәхәтсезлек вирәләр. Буңа күрә ул илә хәрифләрне [буш, кадерсез кешеләрне] буш өйләрдә өч көн хәбес итмәк хакы карья имамнарына вирелсә иде.

92. Голүме диния чит мәмләкәтләрдә тәхсил итмеш адәмнәргә мәктәп-мәдрәсәләрдә мөгаллимлек, мөдәррислек хокукы вирелсә иде.

93. Русча белмәк имамнарга шарт кылынмаса иде.

94. Мөселманнарга үз телләрендә авыл иялеге мәктәпләре ачылса иде.

95. Шәригате исламия хөкеме илә хинзир [дуңгыз] ите, мае, шурпасы катган тәхрим кылынмыш улдыкларына күрә, һәр җирдә үзенә махсус аш өстәле вирелсә иде.

96. Миссионерларның юлсыз, әдәпсез хәрәкәтләре, урынсыз фетнәләре мөселманнарга соң дәрәҗә рәхәтсезлек вирдекләренә күрә, мөселманнар арасында тезгенсез хәрәкәтләрдән, закон нәзарында мәсьүлиять [закон карашында җаваплылык] тәһдиде илә [куркытып кисәтү] миссионерлар мәнгы [тыю, туктату, рөхсәт бирмәү] кылынса иде.

97. Соң заманнарда башкорт карьяларында эчү бәласы бигүк куәтле таралды; эчү шомлыгында карья харап улып, һәр җирдә һәрвакыт фетнәләр күбәйде. Буңа күрә мөселман карьяларында аракы, пиво кеби мөскират [исерткечләр] лавкалары, әлбәттә, ябылса иде.

98. Мөселманнарга фәхешханәләр ачмак, хатын-кызларына фахишәлек итмәк катгый сурәттә мәнгы кылынса иде.

99. Мөселман карьяларында җомга, бәйрәм көннәрендә базар ачылмаса иде.

100. Җомга, бәйрәм көннәрендә мәхкәмәләргә дәгъвәт кылынмак, хезмәт итмәк мөселманнарга улмаса иде.

101. Рус бәйрәмнәрендә мөселманнарның магазәләрен, дөкяннәрен [кибетләрен] ачмак рөхсәт улса иде.

102. Мөселман балаларын рус мәктәпләренә кабул итмәк өчен дини мәгълүматтан, укудан, язудан шәһадәтнамә шарт кылынса иде.

103. Мөселманнар бөтен виргуләрен, салымнарын, алымнарын һәр җирдә русларга бәрабәр түләсәләр дә, мөселман уездларында, земский собраниеләрдә мөселман вәкилләренә закон урын вирмәмештер. Шул җәһәттән мөселманнарга тарлык вирүче закон маддәләре нәсех [алмаштыру, үзгәртү] кылынып, земство собраниеләренә гласныйлар сайламак хокукы мөселманнарга да вирелсә иде. Буңа магада [башка, бүтән], мөселман өязләрендә земство собраниесендә булынып исә, бере, әлбәттә, мөселман улачак; дүрт әгъза вар исә, ике мөселман улачак.

104. Мөселманнары аз өязләрдә мөселманнарның мәслихәтләрен күзәтмәк өчен земство собраниеләренә уезд ахунды яхуд

имамы хазир улмак [шунда булу] мөсагадә кылынса иде.

105. Әгәр дә император хәзрәтләре халык хаҗәтләрен мөзакәрә өчен собрание тәэсис иттерер исә, ислам вәкилләре дә дәгъвәт кылынса иде.

106. Җир сатылганда яхуд иҗарәгә вирелгәндә җәмәгать адәмнәре соңра якын-тирә мөселманнары алында тотылса иде.

107. Үзләренең бөтен җирләрен сатып, башка адәмнәрнең сатылмаган буш җирләре илә хаксыз, юлсыз файдаланып торучы гаиләләр бар. Буңа күрә үзләренең буш җирләрен сатмаган гасабә [кабилә] башкортларның бөтен өлешләре бер урында булынып вирелсә иде.

108. Башкортларның һәрберенә, гасабәләренә дә, типтәренә дә, мишәренә дә запас җирдән киселеп җир арттырылса иде.

109. Җир иялегенә [җир биләүгә] яхшы интизам вирү өчен башкорт җирләре җан башына бүленеп вирелсә иде, һәр алты сәнәдә бер кат җир бүленеп торса иде.

110. Башкорт урманнарын сакламак казна алыннан алынып, гасаб үзләренә тапшырылса иде.

111. Иген игүдән башка һөнәрләре юклыгына күрә, кахтылык [яңгырсызлык, корылык], ачлык сәнәләрендә бу тарафның халкы соң дәрәҗә фәкыйрьлек зәхмәтләрен чигәләр. Буңа күрә земство хисабына һөнәр мәктәпләре ачмак соң дәрәҗәдә зарурдыр.

112. Үзләренең җирләрен гасабә башкортлардан сатып алганлыкларына күрә, яңа башкортлар җирләренең бәһаләрен түләүдән азат кылынса иде.

113. Мөфти гомерлек сайланса иде. Әгәр дә вазифаларына әһлиятьсезлеге [эшне булдыра алмаулыгы] соңра сабит улыр исә, халыкның нисфе [яртысы] шикаять иттектә, газел [урыннан төшерү, хезмәттән чыгару] кылынса иде.

Корылтайда хәзрәтләр тарафыннан кабул кылынып, мохтәлитъ һәйәт мәгърифәте илә ислах һәм тәрҗемә кылынмыш ислахат ляихәсе – 1905 сәнә июнь 22, 23, 25 көннәрендә башкортлар съездында мөзакәрә кылынып, 23 маддәне гыйлавә итдектән соң, 120 дән зиядә вәкил тарафыннан кабул кылынды, имзаланды. Ике ляихәдә тәфавет [аерма] юк иде. Корылтай ляихәсе дә, башкортларның ляихәсе дә 1905 сәнәдә табгы кылынды. Бере дигәренең тәмам нөсхәседер, ягъни корылтай ляихәсе башкортлар съездында хәрфиян [хәрефкә хәреф] кабул кылынмыштыр.

Соңра Йосыф әфәнде Акчура җәнапләре ул ляихәләрне бераз тәгъдил итеп, бераз тәгъйир итте: вилаят ахундлары низамы бәдәлендә вилаят мәҗлесләре низамын язды; бәяннамәсе илә бәрабәр Оренбургта, 1908 сәнәдә табгы кылынды. Бәнем тәрҗемәм шул нөсхәдәндер, «яшел нөсхә»дәндер.

*Текстны гарәп имласыннан кирилл алфавитына күчереп, сүзлекне һәм аңлатмаларны Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә хезмәткәре* ***Шәрәфиева Рәисә Гамир*** *кызы әзерләде*

УДК 811.512.145´271

***Н.В. Максимов***

# СӨЙЛӘМ КАЛЫБЫ:<br>ХӘРӘКӘТНЕ БЕЛДЕРҮЧЕ СҮЗЛӘР

В статье рассматривается технология обучения татарскому языку как неродному. Обосновывается целесообразность обучения языку на синтаксической основе. Выделение синтагматической модели речи в качестве основы обучения неродной речи позволяет акцентировать внимание обучаемого на алгоритме построения словосочетаний и предложений. Опора на алгоритмы помогает обучающемуся варьировать стабильными синтаксическими конструкциями в процессе создания текста-основы и выстраивания диалогов.

**Ключевые слова**: вопросительные слова, ответные слова, глаголы движения, словосочетание, предложение, модель речи, синтаксис разговорной речи, монолог – рассказ первого лица; диалог первого и второго лица; диалог первого, второго, третьего лица.

Һәр телнең сүзлек байлыгында мөһим урынны теге яисә бу хәрәкәтне белдерүче сүзләр (*чыга, бара, килә, керә, менә төшә, кайта һ.б.*) алып тора. Әлеге сүзләр сөйләмдә катнашучы кешеләрнең яшәү рәвеше, аларның җәмгыятьтә тоткан урыны, кылган эш-гамәлләре белән бәйле бик күп төшенчәләрне, кешеләр арасында була торган үзара мөнәсәбәтләрне бергә бәйләүче һәм туплаучы үзәк вазифасын башкара.

Башка телләрдәге кебек татар телендә дә юнәлешле хәрәкәтне белдерүче бу сүзләр төркеменә сөйләмдә, нигездә, *кайчан*? *кая*? *кем белән*? *кайда*? *нәрсәдә*? *ничек*? *нигә*? *нишләргә*? кебек сорау сүзләргә җавап бирүче сүзләр һәм синтетик яки аналитик төрдәге иярчен җөмләләр төркеме ияреп килә. Җөмлә кисәкләренең логик-грамматик бүленеше ягыннан караганда, без аларны түбәндәгечә атыйбыз:

| **Кем?** | **Сорау сүзләр** | **Җавап сүзләр** | **Җавап җөмләләр** | **Нишли?** |
|---|---|---|---|---|
| **1<br>Мин** | **Кайчан?** | кайткач<br>теләгәндә<br>чыкканда<br>чакырганда<br>менгәч | әнием кайткач<br>энем теләгәндә<br>апам чыкканда<br>дустым чакырганда<br>башкалар менгәч<br>син төшкәч<br>дәресләр тәмамлангач | **нишлим?**<br>барам<br>чыгам<br>керәм<br>менәм<br>төшәм<br>кайтам |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **2<br>Син** | | төшкәч<br>тәмамлангач | әниең кайткач<br>энең теләгәндә<br>апаң чыкканда<br>дустың чакырганда<br>башкалар менгәч<br>мин төшкәч<br>дәресләр тәмамлангач | **нишлисең?**<br>барасың?<br>барасыңмы?<br>чыгасың?<br>чыгасыңмы<br>керәсең?<br>керәсеңме?<br>менәсең?<br>менәсеңме?<br>төшәсең?<br>төшәсеңме?<br>кайтасың?<br>кайтасыңмы? |

Юнәлешле хәрәкәтне белдерүче сүзләр, татар телендә барлык формада – **нишлә**, юклык формасында **нишләмә** сүзенә нигезләнеп, сөйләмдә катнашучы затларны белдерүче сүзләр белән затта һәм санда яраклашып, сорау сүз формасын ала һәм, гадәттә, сөйләмдә антоним мәгънәле парлар буларак кулланыла: раслау яки инкарь итү мәгънәсен белдерә.

***Бару*** – кемнеңдер (I яки II, яки III затның) яки нәрсәнеңдер кайсыдыр бер объектка карата юнәлеше булган хәрәкәт. Хәрәкәт һәрвакыт башлану ноктасыннан (*кайдан*?) бер яки берничә эзлекле тукталыш ноктасына (*кая*?) юнәлешендә башкарыла. Хәрәкәтнең төп башлану һәм тәмамлану ноктасы – без яшәгән урын (йорт, авыл, квартира, шәһәр һ.б.). Калганнары – хәрәкәт уңаенда вакытлыча ясалган тукталышлар (төрле объектлар, мәсәлән: балалар бакчасы, мәктәп, кибет, театр, бассейн, ашханә һ.б.) гына.

Сөйләм калыбында сөйләүченең (I затның) бару һәм кайту юнәлешендәге хәрәкәте турында монолог-хикәясен, I һәм II затның кара-каршы сөйләшен (I диалогны), I һәм II затның III зат турындагы әңгәмәсен (2 нче диалогны) һәр очрак өчен калыпта – сөйләм синтаксисында түбәндәгечә биреп булыр иде:

<table>
<tr><th>Кем?<br>кем</th><th>Кайдан?<br>откуда</th><th>Кая?<br>куда</th><th>Нишли?<br>что делает</th><th>Нишләми?<br>что не делает</th></tr>
<tr><td>1<br>Мин</td><td rowspan="3">өйдән<br>мәктәптән<br>түгәрәктән<br>кибеттән<br>эштән<br><br>парктан<br>шугалактан<br>концерттан<br>кунактан<br><br>бакчадан<br>кинотеатрдан<br><br>спектакльдән<br>китапханәдән<br>ашханәдән<br><br>урманнан</td><td rowspan="3">мәктәпкә<br>өйгә<br>кибеткә<br>түгәрәккә<br>кибеткә<br>эшкә<br><br>паркка<br>шугалакка<br>концертка<br>кунакка<br><br>бакчага<br>кинотеатрга<br><br>спектакльгә<br>китапханәгә<br>ашханәгә<br><br>урманга</td><td>барам<br>кайтам</td><td>бармыйм<br>кайтмыйм</td></tr>
<tr><td>2<br>Син</td><td>барасың?<br>барасыңмы?<br><br>кайтасың?<br>кайтасыңмы?<br><br>бар<br>кайт</td><td>бармыйсың?<br>бармыйсыңмы?<br><br>кайтмыйсың?<br>кайтмыйсыңмы?<br><br>барма<br>кайтма</td></tr>
<tr><td>3<br>Ул<br><br>Әнием<br><br>Әниең<br><br>Әнисе</td><td>бара?<br>барамы?<br><br>кайта?<br>кайтамы?<br><br>барсын<br>кайтсын</td><td>бармый?<br>бармыймы?<br><br>кайтмый?<br>кайтмыймы?<br><br>бармасын<br>кайтмасын</td></tr>
</table>

Сөйләүче бер көндә хәрәкәт белән бәйле эшлисе эшен вакыт ягыннан берничә өлешкә бүләргә мөмкин: 1) кайсыдыр көннең билгеле бер вакытында (*иртән, көндез, кичен* яки *төшкә кадәр, төштән соң* һ.б.) каядыр яки кайларгадыр бара; 2) берничә җиргә барса, ул аны билгеле бер эзлеклелектә (*хәзер, иң элек, башта, аннан соң* һ.б.) кебек сүзләр ярдәмендә башкара; 3) шул көндә башкарасы яки башкарган эшенең төгәл яки якынча вакытын сәгатьләрдә (*сәгать 1 гә, сәгать 1 гә кадәр, сәгать 1 дә, сәгать 1 дән соң* һ.б.); 4) атна эчендәге көн исемнәрендә (*дүшәмбедә, сишәмбедә, пәнҗешәмбедә, җомгада, шимбәдә, ял көнендә*); 5) айның кайсы көнендә (*берендә, унберендә, егерме берендә; алтысында, уналтысында, егерме алтысында* һ.б.); 6) ай исемнәрендә (*гыйнварда яки гыйнвар аенда, февральдә яки февраль аенда* һ.б.); 7) ел исәбен күрсәткән саннарда (*2000 нче елга кадәр, 2010 нчы елда, 2017 нче елдан соң* һ.б.); 8) синтетик иярчен җөмләләрдә (*әни кайткач, вакытым булса, әбием килсә* һ.б.); 9) хәл фигыль формаларында (*теләгәч, теләгәндә* һ.б.); 10) ел фасылларын белдерүче рәвешләрдә (*кышын* яки *кыш көннәрендә, язын* яки *яз көннәрендә, җәен* яки *җәй көннәрендә, көзен* яки *көз көннәрендә* һ.б.); 11) *шул вакытта, шуннан соң, шундук, аңа кадәр, аннан соң* кебек сүзләр ярдәмендә. Укучыга, үзлегеннән татар телен өйрәнүчегә һәм телгә өйрәтүчегә җиңелрәк булсын өчен,

сөйләм калыбында без *кайчан*? соравына җавап бирүче сүзләрнең һәм иярчен җөмләләрнең берничәсен генә – көндәлек сөйләмдә иң еш кабатланганнарын гына кулланабыз:

<table>
<tr><th>Кем?</th><th>Кайчан?</th><th>Кайдан?</th><th>Кая?</th><th>Нишли?</th></tr>
<tr><td>1<br>Мин</td><td rowspan="3">бүген<br>иртәгә<br><br>иртән<br>көндез<br>кичен<br><br>башта<br>аннары<br><br>сәгать<br>1 гә кадәр<br>1 гә<br>1 дән соң<br><br>мәктәпкә<br>кадәр<br><br>мәктәптән<br>соң</td><td rowspan="3">өйдән<br>мәктәптән<br>түгәрәктән<br>кибеттән<br>эштән<br><br>парктан<br>шугалактан<br>концерттан<br>кунактан<br><br>бакчадан<br>кинотеатрдан<br><br>спектакльдән<br>китапханәдән<br>ашханәдән<br><br>урманнан</td><td rowspan="3">мәктәпкә<br>түгәрәккә<br>кибеткә<br>эшкә<br><br>паркка<br>шугалакка<br>концертка<br>кунакка<br><br>бакчага<br>кинога<br><br>спектакльгә<br>китапханәгә<br>ашханәгә<br><br>урманга</td><td>барам</td></tr>
<tr><td>2<br>Син</td><td>барасың?<br>барасыңмы?<br><br>бар</td></tr>
<tr><td>3<br>Ул<br><br>Әнием<br>Әниең<br>Әнисе</td><td>бара?<br>барамы?<br><br>барсын</td></tr>
</table>

Кая да булса барганда яки кайтканда, кеше *ялгызы* гына (үзе генә) яки бер үк вакытта *кем беләндер* булырга мөмкин. Сөйләшүдә катнашучы затларга карата кулланганда, I зат – сөйләүче үзенә карата – *ялгызым*, ягъни *үзем генә* дигән, II затка карата – *ялгызың*, ягъни *үзең генә* дигән, III затка карата *ялгызы*, ягъни *үзе генә* дигән аныклаулы мәгънәле сүз формаларын кулланырга мөмкин.

Кеше бер яки берничә юлдашы (туганы яки туганнары, дусты яки дуслары, танышы яки танышлары, танышы булган яки таныш булмаганнар) белән дә бергә *бер үк вакытта* кая да булса барырга яки кайтырга – килгән якка кире хәрәкәт итәргә мөмкин. Укучыга, үзлегеннән татар телен өйрәнүчегә һәм телгә өйрәтүчегә җиңелрәк булсын өчен, сөйләм калыбында без *кем белән*? соравына җавап бирүче сүзләрнең кан кардәшлек ягыннан туганлык мөнәсәбәтен белдергәннәрен генә кулланабыз. Алар, *кем белән*? соравына җавап буларак, сөйләмдә катнашучы һәр зат (*мин, син, ул*) ничек таләп итсә, шул формада гына, ягъни яраштырылып кулланыла:

<table>
<tr><th>Кем?</th><th>Кайдан?</th><th>Кая?</th><th>Кем белән?</th><th>Нишли?</th><th>Нишләми?</th></tr>
<tr><td>1<br>**Мин**<br><br>үзем<br>үзем генә</td><td rowspan="3">өйдән<br>мәктәптән<br>түгәрәктән<br>кибеттән<br>эштән<br><br>парктан<br>шугалактан<br>концерттан<br>кунактан<br><br>бакчадан<br>кинотеатрдан<br><br>спектакльдән<br>китапханәдән<br>ашханәдән<br><br>урманнан</td><td rowspan="3">мәктәпкә<br>өйгә<br>кибеткә<br>түгәрәккә<br>кибеткә<br>эшкә<br><br>паркка<br>шугалакка<br>концертка<br>кунакка<br><br>бакчага<br>кинотеатрга<br><br>спектакльгә<br>китапханәгә<br>ашханәгә<br><br>урманга</td><td>әнием<br>әтием<br>әбием<br>абыем<br>апам<br>бабам<br>энем<br>дустым<br>**белән**</td><td>барам<br>кайтам</td><td>бармыйм<br>кайтмыйм</td></tr>
<tr><td>2<br>**Син**<br><br>үзең<br>үзең генә</td><td>әниең<br>әтиең<br>әбиең<br>абыең<br>апаң<br>бабаң<br>энең<br>дустың<br>**белән**</td><td>барасың?<br>барасыңмы?<br><br>кайтасың?<br>кайтасыңмы?<br><br>бар<br>кайт</td><td>бармыйсың?<br>бармыйсыңмы?<br><br>кайтмыйсың?<br>кайтмыйсыңмы?<br><br>барма<br>кайтма</td></tr>
<tr><td>3<br>**Ул**<br><br>**Әнием**<br>**Әниең**<br>**Әнисе**<br><br>үзе<br>үзе генә</td><td>әнисе<br>әтисе<br>әбисе<br>абыйсы<br>апасы<br>бабасы<br>энесе<br>дусты<br>**белән**</td><td>бара?<br>барамы?<br><br>кайта?<br>кайтамы?<br><br>барсын<br>кайтсын</td><td>бармый?<br>бармыймы?<br><br>кайтмый?<br>кайтмыймы?<br><br>бармасын<br>кайтмаын</td></tr>
</table>

Хәрәкәт *җәяү*, ягъни аяклар ярдәмендә физик хәрәкәт ясап – атлап яки кешеләрне бер урыннан икенче урынга үзйөрешле күчерү чарасын – электр яки су, яки һава транспортын – механик көчләрне, яки төрле җайланмаларны кулланып та башкарыла. Бу очракта сөйләм калыбында *ничек*? яки *ни рәвешле*? сорау сүзләргә җавап буларак, физик көч кулланып башкарылган хәрәкәтнең башкарылу рәвеше күрсәтелә:

<table>
<tr><th>Кем?</th><th>Кайдан?</th><th>Кая?</th><th>Нәрсәдә?</th><th>Ничек?</th><th>Нишли?</th></tr>
<tr><td>1<br>Мин</td><td rowspan="3">өйдән<br>мәктәптән<br>түгәрәктән<br>кибеттән<br>эштән<br>парктан<br>шугалактан<br>концерттан<br>кунактан<br>бакчадан<br>кинотеатрдан<br>спектакльдән<br>китапханәдән<br>ашханәдән<br>урманнан<br>Мәскәүдән<br>Казаннан</td><td rowspan="3">мәктәпкә<br>өйгә<br>кибеткә<br>түгәрәккә<br>эшкә<br><br>паркка<br>шугалакка<br>концертка<br>кунакка<br><br>бакчага<br>кинотеатрга<br><br>спектакльгә<br>китапханәгә<br>ашханәгә<br><br>урманга<br>Мәскәүгә<br><br>Казанга</td><td rowspan="3">автобуста<br>троллейбуста<br>велосипедта<br>самолётта<br>пароходта<br>атта<br><br>трамвайда<br>таксида<br>машинада<br>поездда<br>метеорда<br>электричкада<br><br>көймәдә</td><td rowspan="3">җәяү<br>тиз-тиз<br>ашыгып<br>ашыкмыйча<br><br>утырып<br><br>йоклап<br><br>басып<br><br>укып<br><br>сөйләшеп</td><td>барам<br>кайтам</td></tr>
<tr><td>2<br>Син</td><td>барасың?<br>барасыңмы?<br><br>кайтасың?<br>кайтасыңмы?<br><br>бар<br>кайт</td></tr>
<tr><td>3<br>Ул<br><br>Әнием<br><br>Әниең<br><br>Әнисе</td><td>бара?<br>барамы?<br><br>кайта?<br>кайтамы?<br><br>барсын<br>кайтсын</td></tr>
</table>

**Хәрәкәт** ул – үз өстеңә алып, кайсы да булса *максатны* үтәү өчен башкарыла торган процесс та; ягъни бару һәм кайту һәрвакыт, сөйләмдә катнашучы затларның теләгенә һәм максатына ярашлы итеп, алдан план корып башкарыла. Хәрәкәт белән бәйле максатлар исә берничә төрле булырга мөмкин. Максатның үтәлешенә юнәлтелгән хәрәкәт сөйләм калыбында, беренче очракта, *нишләргә*? яки *нишләр* ***өчен***? яки *нишләргә* ***дип***? сорау сүзләренә җавап сүзләр формасында кулланыла. Бу очракта сөйләмдә катнашучы затларның хәрәкәт юнәлеше сайланган максатка ярашлы төргә әверелә, ягъни бер төрдән икенче төргә күчешле хәрәкәт формасын ала:

| **Кем?** | **Кая?** | **Нәрсәдә?** | **Нишләр өчен?** | **Нишләргә дип?** | **Нишли?** |
|---|---|---|---|---|---|
| **1 Мин** | тауга | чанада чаңгыда | шуар | шуарга | барам |
| **2 Син** | паркка<br>ипподромга | велосипедта чаңгыда<br>атта | йөрер | йөрергә | барасың? барасыңмы? бар |
| **3 Ул<br>Әнием Әниең Әнисе** | автодромга<br>шугалакка<br>бассейнга күлгә | машинада<br>конькида тимераякта<br>көймәдә | йөзәр **өчен** | йөзәргә **дип** | бара? барамы? барсын<br>кайта? кайтамы? кайтсын |

Икенче очракта исә, хәрәкәт юнәлеше сөйләм калыбында, беренчедән, аерым конструкция ясап, *нәрсәгә*? дигән сорау сүзгә җавап бирүче предметларга карата кулланыла; икенчедән, мәгънәсе ягыннан максатны белдерүче *нишләр **өчен***? һәм *нишләргә **дип***? кебек сорау сүзләргә җавап биргән процессны белдерүче сүзләргә карата кулланыла:

| **Кем?** | **Кая?** | **Нәрсәгә?** | **Нәрсә?** | **Нишләр өчен?** | **Нишләргә дип?** | **Нишли?** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1 Мин** | мәктәпкә кибеткә китапханәгә<br>ашханәгә | ашамлыкка китапка | ашамлык китап<br>ризык чәй | укыр алыр<br>ашар эчәр | укырга алырга<br>ашарга эчәргә | барам бараммы? |
| **2 Син** | филармониягә кинотеатрга театрга | концертка кинога спектакльгә | концерт кино спектакль | карар | карарга | барасың? барасыңмы? бар |
| **3 Ул<br>Әнием<br>Әниең<br>Әнисе** | урманга бакчага<br>елгага | ялга җиләккә<br>балыкка эшкә | җиләк су балык эш | ял итәр җыяр сибәр тотар эшләр **өчен** | ял итәргә җыярга сибәргә тотарга эшләргә **дип** | бара? барамы?<br>барсын кайтсын |

Юнәлешле хәрәкәт яки процесс булсын өчен, кайчакта аны барлыкка китерә яки туктата алырлык *сәбәп* булырга тиеш. Хәрәкәт яки процесс башлансын яки тәмамлансын өчен, сәбәпләр бер яки берничә булырга мөмкин. Сөйләм калыбында алар *нигә*? *ни сәбәпле*? *нәрсә аркасында*? кебек сорау сүзләргә синоним яки антоним мәгънәле җавап сүзләр яки аерымланган компонентлар формасында бирелә:

<table>
<tr><th>Кем?</th><th>Кайчан?</th><th>Кая?</th><th>Нигә?</th><th>Ни сәбәпле?</th><th>Нишли?</th></tr>
<tr><td>1<br>Мин</td><td rowspan="3">авырганда<br><br>авырып<br>киткәндә<br><br>авырмаганда<br><br>теләгәндә<br>теләгем<br>булмаганда<br><br>теләгең<br>булмаганда<br><br>теләге<br>булганда<br><br>теләмәгәндә</td><td rowspan="3">мәктәпкә<br>кибеткә<br>китапханәгә<br><br>ашханәгә<br><br>филармониягә<br>кинотеатрга<br>театрга<br><br>урманга<br>бакчага<br><br>елгага</td><td rowspan="3">авырганга<br><br>авыргач<br><br>теләгәнгә</td><td rowspan="3">авыру<br><br>авырып<br>китү<br><br>сәбәпле<br>аркасында</td><td>барам<br>бармыйм<br>бараммы?</td></tr>
<tr><td>2<br>Син</td><td>барасың?<br>барасыңмы?<br><br>бар<br>барма</td></tr>
<tr><td>3<br>Ул<br><br>Әнием<br>Әнием<br>Әнисе</td><td>бара?<br>барамы?<br><br>барсын<br>бармасын<br><br>кайтсын<br>кайтмасын</td></tr>
</table>

Татар телен өйрәнүче, аеруча аны өйрәтүче өчен сөйләм калыбының без карап үткән таләпләрен үтәү зур әһәмияткә ия. Алар телне үзләштерүне җиңеләйтә һәм бу процессны тизләтергә ярдәм итә.

**Әдәбият**

*Закиев М.З.* Татарская грамматика. Казань: Таткнигоиздат, 1995. Том 3: Синтаксис. 576 б.

*Максимов Н.В.* Словосочетания как основа обучения неродному языку // Вестник КГТУ. 2013. Т. 16, № 7. С. 325–328.

*Максимов Н.В.* Телгә өйрәтү технологиясе (Технология обучения неродному языку) // Фәнни Татарстан. 2014. № 3. С. 106–112.

*Максимов Н.В.* Сөйләм калыбы ул – сөйләмгә өйрәтүнең нигезе. (Модель речи это – основа обучения разговорной речи) // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы: материалы региональной научно-практической конференции, посвящённой 190-летию со дня рождения Каюма Насыри. Казань, 2015. С. 139–147.

*Максимов Н.В.* Технология обучения татарскому языку на основе моделей речи (на русском и татарском языках). Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 255 с.

*Максимов Н.В.* Сөйләшергә өйрәтү формуласы. (Формула обучения речи). Казан: Мәгариф. Татар теле. 2016. № 1. 42 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Хәтер, 2001. 432 б.

***Максимов Николай Валентинович,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*татар теле һәм татар телен укыту кафедрасы доценты*

УДК 373.3:39

*З.Ф. Вәлиева*

# МӘКТӘПТӘ МИЛЛИ ТӘРБИЯ БИРҮНЕҢ НӘЗАРИ ҺӘМ ГАМӘЛИ НИГЕЗЛӘРЕ

Статья посвящена изучению внедрения элементов этнопедагогики в образовательный процесс. Автор рассматривает этнопедагогику как гарант межэтнической стабильности, национального подъема и духовного возрождения. Также автор отмечает, что этнопедагогика выступает как стабилизирующий фактор, противодействующий процессам размывания духовности, культуры, обеспечивающий культурную идентификацию, закладывающую духовные основы личности.

**Ключевые слова:** народная культура, народная педагогика, национальная школа, нравственное сознание, этническое воспитание, этнопедагогика.

Хәзерге заман белем бирү системасында этник үзаңлылык һәм үзтөрлелек исәпкә алынмаса, белем бирүне тулы хокуклы дип атап булмый. Россия Федерациясе кебек күп этнослардан торган илдә этнопедагогикага өстенлек бирелә. Хәзерге тормыш шартларында этнопедагогика милләтара тотрыклылыкны, милли күтәрелешне һәм милли үсешне яшәтүче көч булып формалаша. Этнопедагогика милли мәдәниятне, милли аңны тигезләп торучы фактор буларак та карала.

Милли мәктәпләрне этнопедагогикага нигезләнеп кенә төзеп була. Милли тәрбия культурасы башка культураларның төп нигезен тәшкил итә.

Этнопедагогика тәрбия шартларына фәнни карашны, социаль һәм педагогик процессларга анализ ясауны, милли мәдәни традицияләрне үзара бәйләүне, үзара хәрәкәткә китерүне, үзара тәэсир итүне күзаллый. Этнопедагогика, педагогика фәненең бер өлеше буларак, халыкчан (этник) тәрбиянең үзенчәлекләрен өйрәнә. Г.Н. Волков (бу терминны ул 1972 елда безнең илдә тел әйләнешенә кертә) [Раншбург, б. 72], этнопедагогиканың предметы булып милләтләрнең яки халыкларның нәсел педагогик культурасы, этник социаль акылы, үзенчәлекләре тора, дип билгели.

Безнең көннәр әдәбиятында педагогика фәне буенча бер-берсенә мәгънәләре белән якын торган ике термин яши: «этнопедагогика» һәм «халык педагогикасы». Халык педагогикасы – конкрет этник төркемнең тәрбия алымнарын, традицияләрен өйрәнү ул [Лысикова, 112 б.]. Этнопедагогика – гомумиләштерелгән атама, төрле халыкларның тәрбия алымнарын, традицияләрен чагыштырып анализлау.

Халык педагогикасында конкрет этник төркемнең тәрбия алымнарын, традицияләрен

бер буыннан икенчесенә тапшыру мөһим урын алып тора. Бу процесс никадәр тыгызрак бәйләнгән һәм никадәр тирәндәрәк ятса, өлкән буын өчен яшь буынны тәрбияләү шулкадәр җиңелрәк була. Г.Н. Волков халык әйтемнәреннән бик яхшы фикер таба: «Әгәр син өлкән буынны хөрмәтли белмисең икән, балаларга булган мәхәббәтең турында сөйләп тә торма» [Бердникова, б. 105].

Халык педагогикасының иң мөһим һәм иң яхшы эшләүче үзенчәлекләреннән берсе – халык тормышы белән бәйләнештә булуы. Бу аның тормышка яраклашу индексы.

Кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны өчен мөһим булган җаваплылык, намуслылык, түземлелек, мәхәббәт, кеше кайгысын уртаклаша белү кебек әхлак категорияләрен берләштергән, халык традицияләренә таяну – уңай психологик мохит тудыра, бу, үз чиратында, үсеп килүче яшь буынны тәрбияләүдә әһәмиятле чараларның берсе булып тора. Кеше тәрбияләүдә барысы да актив катнаша: өлкәннәр дә, кечкенәләр дә, социаль мохит тә. Халык педагогикасының нигезен халыкның эчке культурасы, тәрбия алымнары, традицияләре, милли гореф-гадәтләре, социаль-этник нормалар тәшкил итә [Богданова, б. 89].

Халык педагогикасында халыкның зирәклеге, зиһен байлыгы күзәтелә һәм алар төрле тәрбия алымнарына йогынты ясый:

– мәкальләр – этика кагыйдәләренә;

– табышмаклар – акыл зирәклегенә;

– җырлар – эстетик зәвыклылыкка; патриотлыкка;

– әкиятләр – барысына да.

Этнопедагогика – халык педагогикасын өйрәнүче, аның традицияләренә нигезләнгән тәрбия культурасын, иктисади, рухи, социаль һәм башка җәмгыять күренешләре үсешен ачуга корылган фән ул.

Акамедик Г.Н. Волков халык педагогикасына мондый характеристика биргән: «Кеше хәтереннән башка традицияләр юк, тәрбиядән башка әхлаклылык юк, әхлаклылыктан башка шәхес юк, шәхестән башка, тарихи бердәмлек буларак, халык юк» [Курган, б. 245]. Россия Федерациясенең социаль-икътисади, социаль-мәдәни өлкәләрендә барган кардиналь үзгәрешләр шартларында, халыкта милли үзаңлылык, үз халкыңның тарихи тамырлары белән кызыксыну кебек тенденцияләр үсеше күзәтелә.

Рус этнографы М. Залыбин XIX гасырның соңгы чирегендә үк болай дип яза: «...уку йортларында укытучыларыбыз... безнең бабаларыбызның тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, әкиятләре, булган хәлләр, ышанулар, җырлар турында бик аз сөйлиләр, ә бит аларда гасырлар буенча килгән халыкның характеры, гореф-гадәтләре чагылыш таба [Бессчетнова, б. 57].

Этник педагогика үзенең тамырлары белән ерак гасырларга барып тоташа, үзендә бик күп буыннарның тәҗрибәсен саклый, ләкин ул киләчәккә дә мөрәҗәгать итә, чөнки ул этномәдәни тәҗрибәне хәзерге заман буынының тормышын оештыруда

куллана, аларны үз халкының иң яхшы традицияләрендә тәрбияли.

Шулай итеп, балаларга этномәдәни тәрбия бирү, халыкның педагогик зирәклегенә таянып, түбәндәге юнәлешләрдә алып барыла:

– укыту процессына этномәдәният буенча тормышкөнкүрешнең кыйммәтле мәгънәви юнәлешләрен кертү;

– төрле дидактик чаралар куллану;

– шәхеснең активлыгын югары дәрәҗәдә үстерү өчен яңа алымнар кертү.

Этномәдәниятнең прогрессив тәҗрибәләрен бала тәрбияләүдә актив куллану идеяләрне һәм практик тәҗрибәләрне оста куллану гына түгел, ә белем бирүне заман таләпләренә туры китереп алга таба үстерү, баету, ягъни гуманлылыкны, белем бирү процессының активлыгын, шәхесне рухи-әхлакый үстерү һәм тәрбияләү, шулай ук патриотик рух, милләтара аралаша белү культуралары тәрбияләү. Шәхес үстерүдә этник мәдәниятнең роле турында Россия һәм чит ил галимнәренең нәзари яктан да, гамәли яктан да бай тәҗрибәсе тупланган. А.Б. Григорян үзенең тикшеренүләрендә традицион мәдәниятнең яшүсмерләрнең әхлакый үсүендә, тәртибендә нинди роль уйнавын, милли традицияләрнең әхлак тәрбиясенең югарылыгына йогынты ясавын өйрәнә. Этнопедагогик факторларны, алымнарны, методларны мәктәптә һәм гаиләдә әхлак тәрбиясе бирүдә куллану мөһим икәнен дәлилли. Н.Ф. Сагояков исә үс хезмәтләрендә яшүсмерләрнең шәхси сыйфатларының нинди дәрәҗәдә булуына диагностика ясарга мөмкинлек бирә торган гуманлы аңлылык һәм тәртип нормалары критерийларын төзи. Д.С. Брызгалов үзенең тикшеренүләрендә этнопедагогиканың хезмәткә мәхәббәт тәрбияләүдә роле зур икәнен ача: милли хезмәт культурасын уен процессында, иҗади хезмәт барышында үзләштерү алымнарын эшкәртә: милли-региональ компонентны хезмәт тәрбиясендә куллану методларын кертә [Васильева, б. 167].

Т.Н. Бакланова, Н.М. Сокольникова шәхес буларак кеше үсешен милли традицион культура нигезенә таянып үстерү буенча белем бирү программаларын төзиләр. Л.А. Безбородова үзенең хезмәтләрендә мәктәптә музыка укыту методикасына укучының рухи яктан культуралы үсешенә йогынты ясауга әһәмият бирә. Л.А. Рапацкая мәктәптә милли сәнгать культурасын өйрәтүнең нәзари һәм методик нигезен төзүдә үзеннән зур өлеш кертә. Тикшеренүләрнең нигезен Россия психологлары һәм педагоглары А.В. Запорожина, А.Н. Леонтьева хезмәтләре тәшкил итә, шулай ук аларда Б.В. Зейгарник, А.Г. Асламова, Л.И. Божовичларның әйдәп баручы нәзари кануннары файдалына [Каиров…, б. 99].

Бүген мәктәп алдында катлаулы мәсьәлә тора: культуралы, һәрвакыт үзгәреп торучы чынбарлык алдында үз урынын таба белүче иҗади шәхес тәрбияләү; үсеп килүче буынны

тәрбияләү һәм үстерүнең әхлак нигезләрен халык чыганакларыннан табып файдалана белү. Безнең бурыч – белем турында язылган закон нигезендә шәхесне бөтен яклап та культуралы итеп, заманга яраклашкан итеп үстерү. Укытучылар туган телгә, бабаларыбыз тарихына, мәдәнияткә сак караш турында онытмасыннар иде.

Традицион халык мәдәнияте нигезендә этномәдәни белем бирү кече яшьтәге мәктәп баласында милләтара дуслыкны ныгыта, күпмилләтле җәмгыятьтә яшәргә, бүтән милләтләрнең мәдәниятенә, милли гореф-гадәтләренә сак һәм түземле булырга, яшәү кануннарын төгәл үтәргә өйрәтә.

Хәзерге көндә этномәдәни компонент укыту-тәрбия процессында мөһим фактор булып тора. Бу процессны мин үз эшчәнлегемдә түбәндәге принципларга таянып оештырам:

1. Патриотлылык.

Укыту һәм тәрбияне тарихи чыганакларга, халыкның гореф-гадәтләренә таянып алып бару. Бу үз Ватанына хөрмәт, мәхәббәт һәм тугрылык, киләчәккә ышаныч принциплары нигезендә тормышка ашырыла.

2. Тарихчанлык принцибы.

Гуманитар фәннәр тарихи чыганакларга нигезләнә. Башка фәннәрне өйрәнүне дә тарихи чыганакларга таянып оештыру.

3. Укыту-тәрбия бирү принцибы.

Укыту предметларына төп максатка караган кебек түгел, ә укучыларның шәхесен тәрбияләүгә кулланма итеп карау.

Дәресләрдә халык педагогикасын куллану яшь буынга тәрбия бирүдә мөһим фактик материал булып тора. Бала тәрбияләүдә халык педагогикасының поэзиясен куллану да киң урын алып тора, чөнки аның гади һәм образлы әсәрләре балалар күңеленә тиз үтеп керә һәм, үз чиратында, бала күңелендә яхшылыкны, игелеклелекне, гаделлекне аңлауга этәргеч тудыра, яхшыдан яманны аерырга өйрәтә. Шулай ук балаларның фантазиясен тагын да үстерергә, тагын да баетырга ярдәм итә, бала күңелендә иҗатка омтылыш уята. Мәсәлән, балаларның үзләренә дә иҗат итеп карарга – шигырь язарга бирем бирелә. Дәресләрдә халык педагогикасын кулланганда, халык авыз иҗатының бер жанрына гына өстенлек биреп булмый, чөнки аларның барысы да педагогик кыйммәткә ия, барлык төр жанрларда да халыкның зирәклеге, тапкырлыгы ачык чагылыш таба.

Яшь буынга әхлак тәрбиясе бирү буенча да халык педагогикасында халыкның күп гасырлык тәҗрибәсе тупланган. Бу уңай тәҗрибә хәзерге көндә дә актуаль һәм тәрбия процессында мөһим роль уйный. Мәсәлән, халык әкиятләре кешене тапкырлыкка, зирәклеккә, түземлелеккә һәм нинди генә авырлыклар, сынаулар алдында да югалып калмыйча, кеше булып калырга өйрәтә. Аларда һәрвакыт начарлыкны яхшылык җиңә, дөреслек тантана итә.

Халык педагогикасын математика дәресләренең телдән исәпләү этабында да кулланып була.

Мәсәлән, санау-исәпләүгә корылган табышмаклар куллану. Бу табышмаклар математик хисаплауга, логик фикерләүгә һәм бала аңын үстерүгә, шулай ук хәтерне ныгытуга ярдәм итә. Мәсьәләләр чишкәндә, сирәк кенә булса да, мәсьәлә эчтәлеге буенча балалар төрле уен кораллары, балалар уеннарының исемнәре белән дә танышалар.

Төрле уеннар вакытында санамышлар куллану, уен кагыйдәләрен истә калдыру исә баланың хәтерен яхшыртуда һәм хәтер ныклыгын үстерүдә уңай нәтиҗә бирә. Шулай ук таныпбелүгә корылган уеннар, кабатлау күнегүләре, укуга аңлы караш үстерү ысуллары да киң кулланыла.

Башлангыч сыйныф мәктәп дәреслекләрендә дә этнопедагогика элементлары киң чагылыш тапкан. Мәсәлән, гуманитар фәннәр дәресләрендә балалар төрле милләт әкиятләре, мәкальәйтемнәре, табышмаклары, сынамышлары, тизәйткечләре белән танышалар. Бу бигрәк тә әдәби уку, татар теле, рус теле, сынлы сәнгать, әйләнә-тирә дөнья дәреслекләрендә ачык чагылыш алган. Балалар, төрле милләт халык авыз иҗаты белән танышып кына калмыйлар, ә аларны чагыштыралар, анализлыйлар, охшаш әсәрләрне табалар.

Халык педагогикасы элементлары әйләнә-тирә дөнья дәресләрендә дә киң кулланылыш таба. Бу, үз чиратында, мәктәп баласына табигать күренешләрен, табигатьтәге үзгәрешләрнең кеше тормышына һәм хезмәтенә ничек йогынты ясавын яхшырак аңларга ярдәм итә. Сынамыш, мәкаль, әйтем, әкият, төрле легендалар кебек халык педагогикасы элементлары биологик төшенчәләрне тулырак үзләштерергә дә ярдәм итә. Мәсәлән, халык сынамышларын күзәтергә дип бирелгән биремнәр укучыларның күзәтүчәнлеген, игътибарлылыгын, тирә-юньгә мәхәббәтен үстерергә этәргеч булып тора. «Хайваннарның күптөрлелеге» темасын өйрәнгәндә без, Татарстан территориясендә яшәүче хайваннар белән беррәттән, анда үсүче үсемлекләрнең аерым төрләрен дә өйрәнәбез. Таныпбелү эшчәнлеген үстерү максатыннан, халык күзәтүләренә нигезләнеп куелган үсемлек исеменең килеп чыгышы турында легендалар тәкъдим ителә, укучылар болар турында кызыксынып укыйлар һәм үзләренә дә легендалар чыгарырга бирем бирелә.

«Тарих битләреннән» темасын өйрәнгәндә, без тагын халык хәтеренә мөрәҗәгать итәбез. Милли геройлар, халыкның ирек өчен көрәшү тарихы балаларны һәрвакыт кызыксындыра. Бу темаларны өйрәнү балаларны әдәби укуга, әдәби китаплар кулланырга, ил тарихындагы мөһим фактларны эзләргә өйрәтә. Бу теманы өйрәнгәндә, эти-әниләрнең ярдәме бик зарур, чөнки һәр ата-ана баласын үз нәселе, гаилә тарихы, гаилә традицияләре белән таныштырырга тиеш.

Сынлы сәнгать дәресләрендә этнопедагогикага (мәсәлән: милли әкият образлары, халык календаре билгеләре һәм символлары, төрле халыкларның милли киеме, «Минем Татарстаным»,

төрле халыкларның бизәк төшерү һәм орнамент үрнәкләре һ.б.га) мөрәҗәгать итәбез. Балалар, рәсем ясап кына калмыйча, нәзари белемнәр дә алалар: әйтик, милли әкият образлары белән танышалар, әкиятләргә иллюстрацияләр төшерәләр; кайсы орнамент нинди мәгънәгә ия булуын ачыклыйлар; аерым төр киемне кайчан, нинди очракта кияргә кирәклеген билгелиләр; бәйрәм табынын әзерләргә өйрәнәләр.

Этнопедагогиканы тормышка ашыруда шулай ук сыйныфтан тыш чаралар да мөһим урын алып тора. Мәсәлән, Сөмбелә, Яңа ел, Карга боткасы, Әниләр бәйрәме, Нәүруз бәйрәмнәре белән танышалар. Бәйрәмнәр әти-әниләр, әби-бабайлар ярдәме белән оештырыла. Өлкән буын вәкилләре балаларга теге яки бу милли бәйрәмне ничек уздырырга, нинди милли ризыклар әзерләргә икәнен аңлата, шулай ук төрле милли уеннар өйрәнергә ярдәм итә.

Шулай итеп, мәктәп тормышында, бигрәк тә башлангыч сыйныфларда, эпнопедагогиканы куллану тулысынча тормышка ашырыла һәм ул уңай нәтиҗәләр дә бирә. Педагогик эшчәнлекне һөнәр итеп сайлаган кешегә халык педагогикасын, аның гореф-гадәтләрен белү бик кирәкле фактор. Эше нәтиҗәле булсын өчен, һәр укытучыга тәрбиянең максатын һәм бурычларын ачык белү мөһим. Бары шул очракта гына аның укыту-тәрбия өлкәсендә тиешле дәрәҗәдә максатка омтылуы, югары нәтиҗәләргә ирешүе күзәтеләчәк.

**Әдәбият**

*Бердникова В., Ткаченко И.* Масленица // Воспитание школьников. 2007. № 1. 167 с.

*Бессчетнова О.В.* Культура и образование: формы и методы взаимодействия: учеб. пособие для преподавателей и студентов вузов, учителей школ, работников культуры. Саратов: Научная книга, 2009. 136 с.

*Богданова О.С., Калинин О.Д.* Содержание и методика этических бесед с младшими школьниками. М.: Просвещение, 1982. 160 с.

*Васильева З.Н.* Нравственное воспитание учащихся в учебной деятельности. М.: Просвещение, 1978. 235 с.

*Каиров И.А., Богданова О.С.* Нравственное развитие младших школьников в процессе воспитания. М.: Просвещение, 1979. 189 с.

*Курган Г.И.* Процесс усвоения нравственных принципов и обеспечение моральности поведения. М.: Педагогика, 1980. 319 с.

*Лысикова Н.П.* Народная культура: генезис и традиции. Саратов: Изд-во ТППСО; Триумф, 2006. 245 с.

*Раншбург Й.* Формирование и развитие морали. М.: Айрис-пресс, 1983. 189 с.

***Вәлиева Зөләйха Фәрит кызы,***
*Яр Чаллы шәһәре 45 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы*

УДК 512.145=316.647

*З.К. Нургалиева, Э.Р. Яруллина*

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРДА ТОЛЕРАНТЛЫК ХИСЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘҮ

В статье говорится о том, что толерантность участников образовательной системы в многонациональной школе – одна из самых важнейших условий для нормального развития учащихся. Поэтому уже в начальных классах важно научить детей уважать других. Важно объяснить, что представители другой национальности, расы и религии не хуже и не лучше, а только разные. Уроки татарского языка и литературы дают на это множество возможностей: знакомство с разными обычаями и традициями, чтение произведений писателей разных народов в переводе; на уроках можно проводить групповые работы, где ученики могут помогать друг другу, слушать остальных и т.д. Формирование толерантности должно быть разносторонним и вестись в разных направлениях.

**Ключевые слова:** уроки татарского язык и литературы, толерантность, начальное образование, многонациональный, групповые работы, воспитание разносторонней личности.

Татарстан – күпмилләтле, төрле дин вәкилләре яшәгән Республика, шул исәптән Казан шәһәре дә шундый ук. Шуңа күрә мәктәпләрдә бер сыйныфта төрле милләттән булган, төрле дингә ышанучы укучылар укый. Кешелек дөньясы яңадан-яңа технологияләр, катлаулы роботлар уйлап тапса да, төрле раса, милләт, дин ваәкилләре арасында идеаль татулык булдыру схемасын төзи алмый. Милли һәм дини сугышлар, төрле милләт, дин, мәдәният кешеләре арасындагы үзара бер-береңне хөрмәт итмәү, террор очраклары турында да еш ишетергә туры килә. Бу фактның җәмгыятьтә нинди дәрәҗәдә кискен торуын Россия президенты В.В. Путин тарафыннан кабул ителгән, милли экстремизмга каршы тору чараларын күздә тоткан «Яшь буынны толерантлык рухында тәрбияләү» программасы да исбатлап тора. Менә шуңа күрә дә укучыларны кече яшьтән үк башкаларны хөрмәт итәргә, башкаларның фикере белән килешмәгәндә дә, үз-үзләрен тыныч тотарга өйрәтергә, ягъни аларда толерантлык хисләре тәрбияләргә кирәк.

«Толерантлык (латин теленнән *tolerantia* – түземлелек, сабырлык, кабул итү, авырлыкны ихтыярый рәвештә кичерү) – социологик термин, дөньяны башкача кабул итүгә, яшәү рәвеше алып баруга, башка төрле тәртип һәм йолаларга түземлелек. Толерантлык битарафлыкка тиң түгел. Шулай ук башкаларның тормыш-яшәү рәвешен кабул итү дә булмый, аның мәгънәсе – башкаларга үз карашлары белән яшәү хокукы бирүдә» [Википедия].

Укучылар белән эшләү тәҗрибәсе күрсәткәнчә, еш кына укучылар башка милләт, диндә булган укучыларга тискәре мөнәсәбәттә булалар. Аеруча алар

беренче сыйныфтан ук бергә булмасалар.

Укучыларга башка мәдәниятнең үзләренекеннән начаррак та, яхшырак та булмавын, бары тик төрле генә булуларын аңлатырга кирәк. Башка милләт, дин, ил йолалары һәм үзенчәлекләре белән танышканда, алар, иң беренче чиратта, укытучының аларга тигез хөрмәт белән каравын сизәргә тиешләр.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләре – төрле милләттән булган укучыларда толерантлык хисләре тәрбияләү өчен уңай вакыт, чөнки бу вакытта татарлар гына түгел, рус һәм башка милләтләр дә татар мәдәнияте, сәнгате, тормыш-көнкүреше белән таныша. Укытучының иң беренче бурычы – башкаларның фикерен тыңлый белергә, килешкән очракта да, килешмәгәндә дә сыйныфташыңа карата яхшы мөгамәләне сакларга, үз-үзеңне тыныч тотарга өйрәтү. Шулай ук биремне башкарганда бер-берсенә ярдәм итү, уку кирәк-яраклары белән бүлешү дә – толерант шәхес барлыкка килү өчен беренче шартлар. Төрле милләт вәкилләре укыган сыйныфта татулык урнаштырганнан соң, төрле милләт йолалары, гореф-гадәтләре белән дә таныштырырга мөмкин.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә рус мәктәпләре өчен программаларга киемнәр, бәйрәмнәр, ашамлыклар темалары кертелгән. Әлеге темаларны үткәндә укытучы, татар теле дәресләре булуга карамастан, сыйныфтагы милләтләрнең һәркайсы турында да азмы-күпме мәгълүмат бирергә һәм һәрберсенең матур, күркәм якларына игътибар итәргә тиеш. Мәсәлән, «Бәйрәмнәр» темасын өйрәнгәндә Сабантуй, Питрау, Май чабу, Сөмбелә, Хеллоуин кебек танылган бәйрәмнәр турында искә алынса яхшы. Шулай ук алар турында укучыларның үзләреннән дә сөйләтергә мөмкин. Бәйрәмнәр темасын өйрәнеп бетергәч, сыйныфта төрле халыкларның бәйрәм элементларын кертеп, кечкенә генә җырлы-уенлы бәйрәм дә үткәреп була. Билгеле, аны оештыру укытучыдан шактый зур әзерлек таләп итә һәм мондый чараларны бары тик үз эшенә бирелгәннәр генә башкарырга алыначак. Әлеге төр дәрес татар телендә өйрәнелгән лексиканы кабатлау өчен генә түгел, ә укучылар арасында татулыкны ныгыту, дусларны тагын да арттыру өчен дә нәтиҗәле булачак.

Бәйрәм вакытында укучылар бик теләп бер-берсе белән аралашалар, уеннар уйныйлар һәм аннан соң да озак вакытлар бер-берсе белән хисләрен, фикерләрен бүлешәләр, озак вакытлар уңай кичерешләр белән йөриләр.

Әлеге бәйрәмне параллель сыйныфларда укучы берничә төркемдә дә оештырып була. Бу – укучыларның аралашу даирәсен тагын да киңәйтә, ә укытучыларга бергә әзерләнергә, яңа идеяләр табарга мөмкинлек тудыра.

«Киемнәр», «Ашамлыклар» темасын үткәндә дә укучылар күпмедер дәрәҗәдә чагыштырып, төрле мәдәниятләрнең традицияләре турында белем туплыйлар. Казан яки Татарстаныбыз турында сөйләшкән вакытта да анда күп милләтләрнең дус һәм

тату булып яшәүләренә игътибар итәргә, мәчет һәм чиркәүләр, башка дини оешмалар, «Халыклар дуслыгы йорты» турында мәгълүмат бирергә кирәк.

«Киемнәр» темасын өйрәнгәндә зуррак сыйныфларда укучыларны төрле милләт киемнәрен киендереп кунакка чакырырга мөмкин, чөнки хәзерге вакытта мәктәпләрдә төрле иҗади түгәрәкләр эшләп килә һәм милли киемнәрне табу кыенлык тудырмый. Бу укучылар әлеге милли киемнәр белән таныштыралар, шул милләтнең берәр осталыгын күрсәтәләр. Кече яшьтәге укучылар бик кызыксынучан һәм дәресләргә төрле әкият геройларының һәм башка кунакларның килүен бик яраталар.

Татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре арасында рус һәм татар телләрен, милләтләр дуслыгын күрсәткәннәре дә бик күп. Димәк, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә төрле күнегүләр, биремнәр әзерләгәндә аларны уңышлы кулланырга була. Мисал өчен, иң гади һәм җиңел шигырь текстын укытучылар дәрес башында башлангыч сыйныфларда исәнләшү төре буларак кулланалар:

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.

Бу ысул да билгеле бер дәрәҗәдә толерантлык сыйфатларын үстерүгә ярдәм итә.

Татар әдәбияты, әдәби уку дәресләрендә төрле халыкларның тәрҗемә әсәрләре белән танышуга да урын бирү әһәмиятле, бу – укытучының һәркемнең шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алуын күрсәтә, укучыларда төрле халыкларга карата соклану хисләре тудырырга булыша.

Алдарак билгеләп үткәнчә, толерантлык – башкаларның фикерләрен тыңлый белүдән башлана. Бу уңайдан татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә төрле фикер алышулар, дискуссияләр, проектлар методын тормышка ашыру ярдәм итә. Моннан тыш, укучыларны төркемнәргә бүлеп, төрле уеннар уйнатканда яки биремнәр башкару да уңышлы эш төрләреннән санала. Болай эшләгәндә укучы үз фикерен курыкмый әйтергә, башкаларны тыңлый белергә өйрәнә.

Яшь буында толерантлык формалаштыру күпкырлы булырга һәм төрле юнәлешләрдә алып барылырга тиеш. Башкаларга карата толерантлык хисе – бигрәк тә дини төрлелек буенча – авырдан формалаша. Дини карашлар төрлелеге буенча башкаларныкы чит, начар әйбер итеп карала. Әнә шул «чит» дигән төшенчәне «башка» дигән төшенчәгә алмаштырырга кирәк. Иң гади мисал: ай яки тәре формасындагы кулоннар тагу ул – шакмаклы яки сызыклы күлмәк кигән кебек кенә һәм ул кеше читкә кагылуга сәбәп була алмый. Моны укучыларга аңлату бик катлаулы әлбәттә. Шуңа күрә төрле милләт вәкилләре укыган сыйныфларда укытучы дини, милли темага караган фикерләргә аеруча сак булырга, укучыларның тәртибенә, үзара мөнәсәбәтенә бик игътибарлы булырга тиеш.

«Кошлар кебек һавада очарга, балык кебек су астында йөзәргә өйрәнгәч, хәзер безгә бер генә нәрсә җитми: кеше кебек җирдә яшәргә өйрәнү», – дип яза Б. Шоу. Чыннан да, хәзерге җәмгыятьтә кешеләр арасында бер-берсенә карата битарафлык яки тупаслык, мәрхәмәтсезлек белән еш очрашабыз. Кайчагында урамда барганда ярдәм сорап мөрәҗәгать итүләрен дә ишетмәүчеләр, ишетмәмешкә салышучылар күп. Кимчелекле кешеләргә, кыяфәтләре буенча аерылып торучыларга, башка дин, милләт, мәдәният вәкилләренә мыскыллап караучыла да аз түгел. Милли һәм дини низаглар турында да еш ишетәбез. Шуңа күрә балаларны кече яшьтән толерантлы шәхес итеп тәрбияләүгә зур әһәмият бирергә һәм бу эшкә һәркем, шул исәптән татар теле һәм әдәбияты укытучылары да үзләреннән өлеш кертергә тиешләр.

Әдәбият

*Битянова М.* Радужный камень: Игра на развитие толерантности для уч-ся 3–4 классов / М. Битянова, И. Вачков // География, 2002. № 35. С. 14–18.

*Җәләлиев Ш.Ш.* Милли тәрбия нигезләре: татар урта гомуми белем бирү мәктәпләре, педагогия колледжлары, училищелары өчен уку ярдәмлеге. Казан: Мәгариф, 2003. 149 б.

*Мирнова Е.О.* Развитие толерантности в раннем и дошкольном детстве // Возрастные особенности формирования толерантности. Труды по социологии образования. Т. 8. Вып. 14 / под ред. В.С. Собкина. М.: Центр социологии образования РАО, 2003. 208 с.

*Риэрдон Б. Э.* Толерантность – дорога к миру. М.: Бонфи, 2001. 304 с.

*Шишова Т.* Лечение сказкой // Сельская школа. 2004. № 2. С 104–107.

*Хуҗиәхмәтов Ә.Н.* Педагогика: педагогик уку йортлары, көллиятләр, гимназияләр, лицейлар өчен уку әсбабы. Казан: Матбугат йорты, 1998. 504 б.

*Шаймарданов Р.Х., Сибгатуллин Р.Г.* Татарская народная педагогика. Казань: Дом печати, 2000. 392 с.

https: // ru. wikipedia. Org / wiki

***Нургалиева Зөһрә Камил кызы,***
*Казан шәһәре 121 нче лицееның*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*zuhra-fanzil@mail.ru*

***Яруллина Эльза Равил кызы,***
*Казан шәһәре 121 нче лицееның*
*башлангыч сыйныфлар укытучысы*
*ravilevna3008@yandex.ru*

УДК 314.7

***Я.М. Дәүләтшина,***
***Л.К. Мөхәммәтҗанова,***
***Р.Р. Хизбуллина***

# СӘЛӘТЛЕ ЯШЬЛӘР ҺӘМ МИГРАЦИЯ
## *(эмпирик тикшеренү нәтиҗәләре)*

Талантливая молодежь – это молодые люди, имеющие способности, высокую степень одаренности. Необходимо создать условия для успешной социализации и эффективной самореализации талантливой молодежи, детей. Целью данной статьи является представление результатов авторского исследования по определению основных направлений и причин потенциальной миграции талантливой молодежи Республики Татарстан. Реализация исследовательских задач была достигнута посредством методологического анализа и эмпирической проверки особенностей и причин миграции талантливой молодежи. Использованы данные авторского опроса, сравнительный анализ смежных исследований талантливой молодежи Республики Татарстан. Результаты исследования демонстрируют наличие заинтересованности молодых талантливых людей в поиске работы как в рамках родного региона, так и за его пределами. Основные причины миграции заключаются в поисках более интересных и современных программ обучения, привлекательной заработной платы, возможностей саморазвития. Ограничением миграционных потоков молодежи выступают в первую очередь психологические причины, наличие родственных связей, наличие жилья.

**Ключевые слова:** талантливая молодежь, миграция, молодежь, трудоустройство, социологическое исследование, талант

Һәр дәүләтнең миграция сәясәте беренче чиратта саннарга таянырга тиеш, чөнки ничә кеше күчеп китүен белми торып миграциянең максатын, юнәлешләрен, миграция агымын көйләү буенча эш күләмен, кирәкле чыгымнарны дәлилләп һәм әлеге адымнар нинди нәтиҗәгә китерүен белеп булмый.

Хәзер Россиядә, Татарстан Республикасында балалар һәм яшүсмерләрнең интеллектуаль-иҗади мөмкинлекләрен ачуга шактый игътибар бирелә. Сәләтле яшьләргә дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтү буенча норматив актлар, максатчан программалар да эшләп килә, сәләтле балаларны, яшьләрне барлау, яклау һәм аларның сәләтләрен тагы да үстерүгә юнәлдерелгән төрле чаралар, конкурслар уздырыла.

Дәүләт инновацион яктан уңышлы үссен өчен сәләтле яшьләр һәм белгечләр кирәк. Татарстан Республикасында сәләтле яшьләрнең күп булуы әлеге мәсьәләнең актуаль булуын һәм алар белән эшләүне яхшырту кирәклеген күрсәтә. Дәүләт, әти-әниләр һәм укытучылар сәләтле балалар һәм яшьләрнең аерым ихтыяҗларын исәпкә

алып, алар белән эшләүнең нечкәлекләрен белергә тиеш

Л. Гудков, Б. Дубин, Н. Зоркая, И. Воробьева, А. Кологривов, В. Сарксян, Г. Кошарная, Н. Корж, Е. Данилова, Е. Щанина һәм башка галимнәрнең теоретик һәм методик хезмәтләре яшьләр социаль-демографик төркеменең тормыш юлында килеп туган проблемаларын өйрәнүгә багышланган.

Татарстан Республикасы хөкүмәте һәм РГНФ тарафыннан хупланган «Татарстан Республикасындагы сәләтле яшьләрнең проблемалары һәм үсеш перспективасы» (№ 16-13-16008) фәнни проекты кысаларында социологик тикшеренү үткәрелде һәм сәләтле яшьләрнең төбәктән күчеп китү сәбәпләре һәм китү юнәлешләре тикшерелде.

Социологик тикшеренү 14–35 яшьтәгеләр арасында (n=600 кеше) репрезентатив сайлау ысулы белән Татарстан Республикасының дүрт муниципаль районында үткәрелде. Тикшеренү төрле конкурсларда, олимпиадаларда, конференцияләрдә һәм башка төрле бәйгеләрдә җиңүче, лауреат булган яшьләр арасында уздырылды. Сәләтле яшьләрнең фикерен белү анкета сорауларына җавап алу методы һәм Интернет челтәре ярдәмендә алып барылды.

Респондентларның фикерен анализлау сәләтле яшьләрне бүген борчыган түбәндәгене мәсьәләләрне күрсәтте (1 нче рәсем):

1. Дөнья вазгыяте – 32%
2. Шәхси проблемалар – 39%
3. Эшсезлек – 17%
4. Карьера үсеше – 22%
5. Шәхси үсеш өчен мөмкинлек – 28%
6. Өстенлекле югары уку йортына керү – 16%
7. Белгечлек буенча эш эзләү – 31%
8. Фәнни-тикшеренү проектларын финанслау проблемасы – 3%




1 нче рәс. Сәләтле яшьләрне бүген борчыган мәсьәләләр, сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы

9. Торак сатып алуга бәйле авырлыклар – 22%

10. Фәнни конференцияләрдә/семинарларда/симпозиумнарда катнашу өчен финанс табу проблемасы – 3%

11. Башкалар – 4%.

Тикшеренү процессында хәзерге яшьләрне аеруча белгечлек буенча эш табу, шәхси үсеш өчен мөмкинлек һәм карьера буенча күтәрелү проблемалары борчуы күзәтелгәнгә күрә, аларга теләгән белгечлек/һөнәр буенча Татарстанда эшкә урнашу перспективасына кагылышлы сорау бирелде. Сораштырылганнарның яртысыннан артыгы (58% ы), теләгән белгечлек/һөнәр буенча Татарстанда урнаша алам, дип нык ышаныч белдерә, 9% ы Татарстанда һөнәр буенча эш табу авыр, дип уйлый, яшьләрнең 18% ы, андый эш булып та анда урнашу авыр, ди, тагын 18% ы андый эш булып та анда урнашып буламы-юкмы икәнлеген белмиләр. Респондентларның 5% ы үз вариант җавапларын тәкъдим иттеләр (2 нче рәсем).

Алынган мәгълүматлар буенча, сәләтле яшьләрнең 54% Татарстан Республикасының башкаласы – Казанда урнашкан югары уку йортларына өстенлек бирә. 12 % Татарстанның башка шәһәрләрендә урнашкан уку йортларын сайлый һәм калган җаваплар Мәскәү, Санкт-Петербург һәм чит ил югары уку йортларына туры килә (3 нче рәсем).

Респондентларның җаваплары нисбәтеннән, аларның ни сәбәпле башка регионнарда урнашкан уку йортларын сайлавы кызыксындыра. Түбәндә респондентларның Татарстаннан читтә булган югары уку йортларына өстенлек бирүенең сәбәпләрен күрсәтүче җаваплары китерелә (4 нче рәсем):

1. Заманчарак һәм кызыклырак укыту программалары – 31%.

2. Әлеге югары уку йортын тәмамлагач эшкә урнашу мөмкинлеге зур – 27%.

3. Анда укуы абруйлырак, мәртәбәлерәк – 20%.

4. Башка вариантлар – 10%.

Хезмәт миграциясенең төп сәбәбе итеп, югары хезмәт хакын санаган респондетлар – 29% ны, карьера буенча күтәрелергә мөмкинлек булуын санаучылар – 21% ны һәм кызыклы эш кысаларында үзеңнең проект, идеяләреңне тормышка ашыра алу мөмкинлеге булуын санаучылар 17% ны тәшкир итә. Сораштырылылган яшьләрнең башка җаваплары 5 нче рәсемдә китерелгән.

Хезмәт миграциясен үзләре өчен мөмкин түгел, дип санаучы һәм Татарстан Республикасында эшкә калырга теләүче респондентлар түбәндәге сәбәпләрне китерәләр: 33% ы – «монда минем туганнарым, дусларым бар», 18% ы – яшәү өчен торак бар (6 нчы рәсем).

Сораштырылган яшьләрнең 44% ы «яхшы перспектива, һөнәри үсеш өчен мөмкинлекләр бар» дип исәпли, шуңа күрә Татарстанда эшкә урнашу перспективасына югары бәя бирә, әмма респондентларның 27% ы хезмәт хакының җитәрлек күләмдә булмавына борчылуын белдерә һәм шәхси үсеш буенча кайбер чикләүләр бар дип саный (7 нче, 8 нче рәсемнәр).




2 нче рәс. Яшьләрнең теләгән белгечлеге/һөнәре буенча Татарстанда эшкә урнашу мөмкинлеге (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




3 нче рәс. Респондентларның «Кайда урнашкан уку йортларына өстенлек бирдегез/бирәчәксез» дигән сораугa җавапларның бүленеше (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




4 нче рәс. Башка регионнарда урнашкан югары уку йортларын сайлау сәбәпләре (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




5 нче рәс. Россиянең башка шәһәрләренә яки чит илләргә күчеп китүнең сәбәпләре (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




6 нче рәс. Башка шәһәрләргә, чит илләргә китмәүнең сәбәпләре (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




7 нче рәс. Татарстанда эшләү перспективасын бәяләү (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)




8 нче рәс. Татарстанда һөнәри үсеш өчен мөмкинлекләр чикләнү сәбәпләре (сораштырылган респондентларның % лардагы чагылышы)

Автор тикшеренүе материаллары, сораштыру нәтиҗәләре 2013 елда Татарстан Республикасындагы яшьләрнең тормыш концепциясе темасы буенча социологик тикшеренү үткәргән Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе белгечләре мәгълүматлары белән аваздаш. Яшьләр уку стратегиясе формалаштырганда белем бирү сыйфаты турында гына уйламый, ә әти-әниләренең фикеренә дә карый һәм өйгә якынрак уку йортларын сайлый. Төрле конкурсларда, олимпиадаларда, конференцияләрдә һәм башка бәйгеләрдә җиңүче, лауреат булган яшьләрнең күбесе үзенең укуын Татарстаннан читтә дәвам итәргә тели, сәбәбе – индивидуаль карьерада шәхси үсеш мөмкинлеге булуы [Тюрин].

Тикшеренү нәтиҗәләре буенча шуны әйтергә була: сәләтле яшьләр туган төбәгендә яисә аннан читтә үзенә эш табуга кызыксыну барлыгын күрсәтә. Миграциянең төп сәбәбе булып тагын да кызыклырак һәм заманчарак белем бирү программасы эзләү, югары хезмәт хакы, шәхси үсеш өчен мөмкинлек барлыгы тора. Миграцияне туктатучы фактор булып беренче чиратта психологик сәбәпләр тора; монда туганлык мөнәсәбәтләре яки торак мәсьәләсе дә җитди роль уйный.

Эмпирик тикшеренү кысаларында ачыкланганча, сәләтле яшьләрнең миграциясе белән бәйле проблемаларны хәл итү өчен регионда яшьләр өчен уңай социаль шартлар тудыру һәм үз-үзләренең ачу мөмкинлеге бирү, яшьләрнең хезмәт потенциалын сыйфатлы үстерү, аны дәүләт инновацион үсешендә актив файдалану зарур.

Россия Федерациясенең әйдәп баручы регионы буларак Татарстанда сәләтле яшьләрнең шәхси үсеше өчен тормышның төрле өлкәләрендә шартлар тудырылган. Татарстан Республикасының бу өлкәдәге өстенлеген тагын да арттыру сәләтле балалар һәм яшьләр өчен даими рәвештә интеллектуаль, иҗади, спорт чаралары уздыру һәм бизнес-элита формалаштыру белән бәйле.

## Әдәбият

*Воробьева И., Кологривов А.* Что им дома не сидится // Прямые инвестиции. 2011. № 8 (112). С. 12–16.

*Гудков Л.Д., Дубин Б.В., Зоркая Н.А.* Молодежь России. М.: Московская школа политических исследований, 2011. 96 с.

*Сарксян В.Б.* Пермский край: опыт противодействия интеллектуальной миграции молодежи // Российское предпринимательство. 2012. № 17 (215). С. 44–50.

*Кошарная Г.Б., Корж Н.В.* Ценностные предпочтения студенческой молодежи в сфере труда // Известия высших учебных заведений. поволжский регион. Общественные науки. 2010. № 2. С. 64–73.

*Данилова Е.А., Щанина Е.В.* Молодежь в региональном социуме: теоретический аспект // Известия высших учебных заведений. Поволжский регион. Общественные науки. 2010. № 1. С. 62–69.

*Тюрин А.* Татарстан станет самым привлекательным регионом для талантливой молодежи. URL: https://kazanfirst.ru/article/227463

***Дәүләтшина Язгөлем Мөбәракша кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*КДЭУның чит телләр кафедрасы доценты,*
*e-mail: yazgul_ahmetova@mail.ru*

***Мөхәммәтҗанова Лилия Касыйм кызы,***
*биология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФАнең фәнни-оештыру бүлеге баш белгече,*
*e-mail: muhametzyanoval@mail.ru*

***Хизбуллина Радмила Радик кызы,***
*социология фәннәре кандидаты,*
*КДЭУның сәясәт һәм хокук социологиясе кафедрасы доценты,*
*e-mail: mine_post@inbox.ru*

*Гали Рәхим*

# КӨРӘШ ҖЫРЛАРЫ

В ноябре 2017 года писателю, литературоведу Гали Рахиму исполнилось бы 125 лет. В истории татарской литературы, науки и культуры имя Гали Рахима занимает особое место. Его научные труды в свое время были опубликованы во многих газетах и журналах, но сейчас они являются библиографической редкостью и мало кому известны.

Предлагаемая критическая статья Г. Рахима посвящена анализу сборника стихов советских поэтов «Көрәш җырлары», который был приурочен к десятилетию со дня смерти великого татарского писателя-поэта Габдуллы Тукая. Рецензия была опубликована 1 мая 1923 года в газете «Безнең байрак». В статье Г. Рахим коротко останавливается на содержании сборника, дает краткую характеристику послереволюционной татарской поэзии. Как отмечает критик, сборник включает в себя произведения около пятидесяти татарских поэтов, таких как Ф. Бурнаш, Х. Такташ, М. Гафури, Н. Думави и многих других.Также без внимания рецензента не остается и художественное оформление сборника.

**Ключевые слова:** Гали Рахим, татарская литература, татарская поэзия, татарская периодическая печать, рецензия, Фатхи Бурнаш, сборник стихов, Г. Тукай.

Тукайның вафатына ун ел тулу мөнәсәбәте белән Татарстан дәүләт нәшрияты «Көрәш җырлары» исеме астында зур гына бер шигырь мәҗмугасы бастырып чыгарды. Фәтхи иптәш Бурнаш тарафыннан җыелып, тәртип ителгән 240 битле бу мәҗмугада кырык бишләп татар шагыйрьләренең әсәрләре җыелган һәм кәгазенең, һәм техника вә эшләнешенең яхшы вә нәфислеге җәһәтеннән бу китап соңгы биш ел эчендә чыккан һәммә татар китапларыннан алда тора. Мондый нәфис рәвештә басылган китаплар бездә революциягә кадәр дә бик сирәк чыга торган иде.

Дәүләт нәшриятенең китапларның тышкы гүзәллекләренә игътибар итә башлавы алкышланырга тиешле хәлләрдәндер.

Исеменнән үк күренеп торганча, бу мәҗмуга башлыча революция һәм аның белән бергә килгән яңа тормыш әмәлләрен үзләрендә гакес [капма-каршы] иттерә торган шигырьләргә багышлана. Монда әсәрләреннән нәмунәләр алынган шагыйрьләрнең күбрәге соңгы бишьеллык инкыйлаб дәверендә баш күтәреп, татар әдәбияты мәйданына чыккан яшь шагыйрьләр булганы шикелле, мәҗмугага дәрҗ ителгән [кертелгән] шигырьләрнең бөтенесе дияргә мөмкин шул дәвердә туган әсәрләрдер.

Мәҗмугага дәрҗ ителгән шигырьләр шагыйрь Фәтхи Бурнаш тарафыннан зур бер муаффәкыять [уңыш] һәм әдәби зәвыкъ белән сайланып җыелган. Әсәрнең мөкаддимәсеннән күрелгәнчә, Фәтхи иптәш берничә елдан бирле яңа татар шигъри әдәбиятын тәгъкыйб итеп [күзәтеп] килеп, бөтен моңар кадәр чыгып килгән аерым

шигырь мәҗмугаларыннан һәм гәзит вә журнал битләрендә дәрҗ ителә килгән шагыйрьләрнең кулында асралган шигырьләрне җыеп, бу мәҗмуганы тутыра килгән. Биш ел дәвамында матбугат мәйданына бик күп булып чыккан шигырь материалыннан ул хакыйкән «шигырь» исемен күтәрергә мөстәхикъ [лаеклы] булган иң гүзәл нәмунәләрне туплаган да, шуннан бу җыентык килеп чыккан. Дәрвакыйг [чыннан да] мәҗмуганы башыннан ахырына кадәр актарып чыкканда, анда бер генә дә начар, татсыз һәм нәфасәт [гүзәллек] тойгысын рәнҗетерлек әйбергә очрамый. Киресенчә, аны укып чыккан һәрбер әдәбият сөюче дә татар шигыренең соңгы елларда никадәр алга атлаганын, ничаклы яңа гүзәллекләр кәшеф иткәнен [ачуын] күрү зур бер ифтихар [горурлык] вә канәгатьлек хисе уятадыр.

Мәҗмуга Бурнаш шигырьләре белән башланып китеп, Бабич, Исәнбәт, Сәмави, Кәрим Әмири, Зәйнәб Бәширова, Һади Такташ шикелле яңа татар шигыренең иң зур терәкләреннән берсе булган шагыйрьләргә аерым-аерым урыннар багышланып, соңгы бүлемдә исә кызыл матбугатта азмы-күпме исемнәре күренеп узган яшь һәм карт шагыйрьләрнең шигырьләреннән бер ничәшәр нәмунә алынган. Бу соңгы кыйсемдә яңа гына каләмнәрен сыный башлаган байтак яшь шагыйрьләр белән бергә Фәрид Ибраһимов, Сөнгати, Гыйффәт шикелле революция алдыннанрак кына мәйданга чыккан шагыйрьләрнең дә, шулай ук Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Зариф Бәшири, Сәгыйть Сүнчәләй, Вакыйф Җәлал шикелле күптәннән танылган «карт» шагыйрьләрнең әсәрләре дә алынган. Аларның да, әлбәттә, күбрәк инкыйлабтан соңгы һәм инкыйлаб рухы белән сугарылган әйберләре кергән. Әсәрне актарганда «карт» шагыйрьләргә «яшьләр»гә караганда азрак игътибар ителү күзгә бәрелә. Бу, ихтимал, мәҗмугада бигрәк тә яшь вә яңа көчләрне күрсәтеп, аларга бер «осмотр» ясау күздә тотылганга шулай эшләнгәндер.

Яңа татар шагыйрьләренең шигырьләрен шушы рәвештә аерым бер мәҗмуга ясап чыгару кирәкле һәм вакытлы эшме, дигән сөяльгә, шиксез, бу эш бик вакытлы һәм кирәк иде, дип җавап бирергә туры килә. Әдәби тәнкыйть, үз әдипләребезнең әсәрләрен чыккан берен тикшереп, тәнкыйть күзе аркылы үткәреп, аларга кыйммәт биреп бару бездә еллык-еллыктан ук бик начар куелган иде. Без үзебезнең нәфис әдәбиятыбызга, җинаять дәрәҗәсендә аз игътибар итә идек.

Азмы-күпме тәнкыйть кувәсенә малик [көченә ия] булган язучыларыбыз булуга карамый, безнең татар матбугатында, татар әдәбиятында зур бер хадисә [вакыйга, күренеш] тәшкил итәрлек әсәрләр дә һичбер тавышсызтынсыз, сәкен белән уздырылып җибәрелә иде.

Яңа язучылар баш күтәрәләр, иске язучыларның зур-зур әсәрләре мәйданга чыга, әмма татар вакытлы матбугатында шулар турысында күбесенчә ләм-мим

дип бер сүз әйтүче булмый. Революциягә кадәр дә бу тәэсефле [үкенечле] хәл шул рәвешчә дәвам итте, революциядән соң да эшләр үзгәрмәде, моны бары тик тәнкыйтьчеләребезнең ялкаулыгына гына хәмел итәргә [юрарга] мөмкин. Һәрхәлдә үзен мәдәни милләтләр рәтенә кертергә тырыша торган бер халык өчен бу гафу ителмәслек бер кимчелектер. Бу бетәргә тиеш; тәнкыйтьчеләребезгә үзләренең тик ятудан күгәреп беткән каләмнәрен яңа, ялтыравыклы каләмнәргә алмаштырып, татар укучы гаммәсенә көн вә көн чыгып барган татар әдәбиятына чын бәһа кую юлында юлбашчылык итә башларга бик вакыт инде.

Соңгы бишьеллык революция дәвере безнең татар әдәбиятына байтак яңалыклар багышлады. Нәфис әдәбиятның нәсер кыйсеме шактый торгынлыкка очраса да, бу бабта да беркадәр яңа рух белән эшләнгән әсәрләр мәйданга килде. Шигырь бабында исә эш башкачарак. Татар әдәбиятының соңгы бишьеллык дәвере безгә шактый озын шагыйрьләр төзмәсе бирде; бер туктаусыз көлтә-көлтә шигырьләр матбугат дөньясына атыла торды. Дөрес, бу дәвердә язылган көйле парчаларның зур бер кыйсеме чын нәфис әдәбият вә шигърият ноктасыннан караганда әһәмиятсез, көйләп язылган агитация вә фикер сату белән тулган әйберләр иде. Ләкин шулар арасында бик күп кенә хакыйки энҗеләр дә чыкты. Һәр көнге матбугат сәхифәләрен тутырган бик күп көйле әсәрләр арасында бу чын энҗеләр кайсы кая, кайсы кая кысылып калып, көндәлек укучының күңелендә тулы бер тәэсир калдырмыйлар иде. Затән [нигездә] бу гади бер эш. Киң әдәбиятлы бер халыкның әдәбияты һичбер вакыт коры җәүһәрләрдән генә гыйбарәт булмый. Затән әдәбият һәрвакытта агитация белән бергә багланып бара. Бу хәл безнең соңгы дәвер әдәбиятыбыз өчен генә хас булган әйбер түгел; фикерләр галәянга [ташуга] килгән, тормыш тулкынланган һәрбер дәвердә бу шулай була. 1905 нче ел революциясе дәверендәге татар әдәбиятында да без нәкъ шундый ук хәлне күрдек. Ул вакытта да безнең матбугат сәхифәләрен тутырган шигырьләрнең йөздә туксаны агитация, фикер сатудан гыйбарәт була иде. Әмма шул ук дәвер безнең әдәбиятыбызга Тукайның үлмәс әсәрләрен бирде.

«Көрәш җырлары» да менә соңгы дәвер татар шигыренең хөласасен [иң яхшысын], аның энҗеләрен бер җөпкә төзеп, бер тәртипкә куеп, бер көллият [бөтен] хәлендә безнең күз алдыбызга куя. Аның әһәмияте вә кирәклеге дә шунда. Инде революция башланганга биш ел тулгач, яңа татар матбугаты үзенең бишьеллык бәйрәмен итеп ятканда, безгә татар шигыренең бишьеллык гомереннән дә үз үзебезгә хисап биреп карарга вакыт иде. Менә шушы хисап бирү юлында татар укучысына «Көрәш җырлары» мәҗмугасы зур булышлык итәчәк.

Гәрчә мәҗмуга «Көрәш җырлары» дип аталса да, ул баштанаяк революция хәрәкәте тудырган, көрәш рухы белән сугарылган

шигырьләр белән генә тутырылмаган. Анда инкыйлаб вә көрәш ялкыннары белән илһамланган, иреккә, сыйнфый көрәшкә, гражданнар сугышына, кызыл гаскәргә, эшкә вә эшчеләргә багышланган шигырьләрдән башка байтак кына халис [саф, чын] рухи лирика да юк түгел.

Җыючы яңа шагыйрьнең мондый әсәрләрен дә читкә какмыйча исабәт [дөрес] иткән. Киресенчә булганда, аның мәҗмугасы бер яклырак булып чыгар иде. Чөнки никадәр замана күтәренке рухлы көрәш вә иҗтимагый әмәлләр заманы булмасын, шагыйрь булган кеше аларга гына хәсыр кылынып [чолганып], үзенең эчке рухи галәмен бөтенләй онытып бетерә алмый. Без моны мәҗмуганың мөндәриҗәсеннән бик яхшы күрә алабыз. Шагыйрьләр никадәр канатланып көрәш вә инкыйлаб җырларын җырламасыннар, вакыт-вакыт алар үзләренең шәхси йөрәк галәмнәренә дә чумгалыйлар.

Шулай итеп, бу мәҗмуга үзенең галибән [күбрәк] «Көрәш җырлары» җыентыгы булу хассәсен [үзенчәлеген] югалтмастан, шул ук вакытта соңгы еллардагы татар шигырьләренең бөтен төп характерын, андагы бөтен идея, аһәң вә үзгәрешләрне тулы рәвештә бер күз карашы белән чуалган елларга имкян [мөмкинлек] бирә. Татар әдәбиятының соңгы дәверен өйрәнергә, аның хакында үзләрендә бер фикер төзәргә теләүчеләр өчен дә ул зур бер җиңеллек тудыра. Шуның өчен дә бөтен татар әдәбиятын сөючеләр бу мәҗмуганың чыгуын алкыш белән каршыларга тиешләр.

Мәҗмуганың мөндәриҗәсе белән танышканнан соң яңа татар шигыренең үзгәреш-эволюциясе хакында нинди фикергә килергә мөмкин?

Бу турыда озын, төпле вә әтрафлы мөляхәзәләрне [фикер йөртүләрне] башка бер вакытка һәм башка тәнкыйтьчеләргә калдырып торып, яңа татар шигыренең тышкы ягы хакында гына кыскача берничә сүз әйтеп узарга тиеш табам.

Эстетика (матурлыкны аңлау) тел вә өслүб ягыннан татар шигырендә, шөбһәсез, бер яңалык һәм яңаруга омтылу сизелә. Бу шигырьләрдә без татар теленең шомарганын, татар сүзенең вә җөмләсенең гүзәллек вә сыгылмалылык ягыннан бик күп алга атлаганлыгын күрәбез. Бер яктан, татар шигырь өслүбе чит телләр тәэсиреннән котылып саф халык теленә, авыл теленә, халык әдәбияты, халык җыры өслүбенә якынлашса, икенче яктан, яшь шагыйрьләр татар телендә яңадан яңа матурлык офыклары кәшеф итәләр [ачалар], гади татар сүзен шигърият вә тасвирчылыкның югары нокталарына ирештерәләр. Дәрдмәнд тарафыннан беренче маяклары кадалып, аннан соң Сүнчәләй, соңгырак заманда Бабичлар, Ченекәй (Сәмави)ләр, Бурнашлар тарафыннан эленеп алынган «аһәңле» өслүб соңгы дәвердә тәмам үсеп, үзенең кәмалына [тулылыгына] ирешә. Хәзер инде эстетика ягыннан татар шигыре үзенә өр яңа юллар тапкан; кайчандыр үз вакытында бик яңа тоелган һәм бик күп тәкълидчеләр [иярүчеләр] мәйданга китергән Тукай өслүбе һәм тарызы

ифадәсе [ысулы] хәзер инде иске вә тарихи бер нәрсә булып калган. Пушкин өслүбе хәзергә яңа урыс шагыйрьләре өслүбенә нисбәтән нинди урын тотса, Тукай өслүбе дә безнең яңа шагыйрьләр өслүбенә нисбәтән шуннан урын тота.

Чынлап та, ахрысы, урыслар алтмыш-җитмеш елда кичергән дәверне без ун елда үткәргәнбездер. «Керәш җырлары» мәҗмугасындагы шигырьләрне күздән кичерү укучыны менә шундый фикерләргә китерә.

Басмага әзерләде:
***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 7:378.1

***И.Ф. Лобашёва***

# КАЗАНДАГЫ АКАДЕМИК СӘНГАТЬ ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫН ЯБУ ТУРЫНДА

## *Тарихи һәм бүгенге заман параллельләре нигезендә аналитик күзәтү*

Обращаясь к современной ситуации с ликвидацией казанского филиала Московского государственного академического художественного института имени В.И. Сурикова, автор делает обзор процесса развития академического художественного образования в Казани, выявляет его фундаментальные исторические и современные взаимосвязи. Особо акцентируется историческое значение деятельности Академии художеств, а также инициативы ее казанских выпускников и местных властей как в прошлом, так и в настоящем. Фактически вместе с этой основной задачей в обзоре гораздо шире, на глубинном уровне рассматриваются современные проблемы художественного процесса в республике.

**Ключевые слова:** Академия художеств, МГАХИ имени В.И. Сурикова, филиал академического вуза, история академического художественного образования в Казани, учебный процесс, художественные выставки и форумы, проблемы художественного процесса в республике, проблема имиджа столичности.

Татарстанда һөнәри милли сәнгатькә нигез салучы Бакый Урманченың тууына 120 ел тулган көннәрдә, ирексездән, көндәлдә шундый сорау туа: репрессия газапларын кичергән, шөһрәт һәм танылу яулаган, өлкә сәнгатенә күпме көч куйган шәхес җирле сәнгать даирәсендәге бүгенге хәлләр турында, сәнгать белеме бирүнең хәзерге торышы хакында нәрсә әйтер иде микән? Җавап ачык кебек: Республика һәм шәһәр сәнгатенә катнашы булган һәркемне Казанда югары академик сәнгать белеме бирү сферасындагы котылгысыз хәлләр борчый. Рәссамның иҗади бөтенлеге һәм масштаблары аның осталыгы белән генә түгел, ә сәнгать киңлегендәге эшчәнлегенең колачы, авторның иҗади башлангычының тирәнлеге белән билгеләнә. Бакый Урманченың Татарстан тасвирый сәнгатенең төп юнәлешләре хакындагы уй-фикерләре, өметниятләре үз иҗаты киңлекләре белән генә чикләнми. Гаять оста иҗатчы, милли философ сәнгать турында фикер йөрткәндә аеруча Татарстанның этник сәнгатен күздә тота, Казанда, гомумән Татарстанда сәнгать белеме бирүгә һәм аны тагын да үстерүгә зур өлеш кертә.

Бүгенге көндә Мәскәүдәге В.И. Суриков исемендәге Сәнгать институты (МГАХИ) Казан филиалының хәле рәсми рәвештә өметсез санала, шуңа күрә андагы хәзерге вазгыять аеруча катлаулы, бу уку йортының барлык аспектларын да бер мәкаләдә

генә ачыклап бетерү мөмкин түгел. Бу язмада Казандагы академик сәнгать белеме бирүнең үсеш процессы һәм аның тарихы белән бүгенге элемтәләрен анализлау бурычы куелды, гәрчә бу югары уку йортын ябу факты алга килеп басса да. Автор өчен «без нинди яхшы» дип, андагы ирешелгән уңай нәтиҗәләрне бәян итү төп бурыч түгел билгеле, шулай да Институтның рәсми рәвештә ябылуында гаеплеләрне эзләү белән беррәттән, аның уңышлы якларына да тукталып үтәргә туры киләчәк. Мәгълүм булганча, бу фактны бер, ике яки өч кеше өстенә генә аударып калдыру дөрес түгел, чөнки мондый җитди эшне «җаваплы» берничә кеше генә булдыра алмас та иде, монда әлеге ситуациягә китереп җиткергән төрле хәлләрнең бергә тупланиуы да зур роль уйный.

Бүген Казанның, Республиканың, шулай ук бөтен илнең сәнгати тормышы язмышының барлык якларын да кабат-кабат ачыклау, Россиядә мәдәни һәм белем бирү процессында барлыкка килгән катлаулы шартларда аны саклап калу зарурлыгын ассызыклау мөһим. Бу мәсьәләне шулай күтәрергә кирәк ки, сәнгати даирәдәге дусларыбыз, бу өлкәне чит итүчеләр, гади кешеләр һәм сәнгатьтән ерак торучылар, гомумән, яшенә, статусына карамыйча, һәркем аңларлык булсын.

Казанда рәсем сәнгате буенча югары уку йорты елларын хәтергә төшергәндә, күңелдә, ирексездән, аның тарих белән янәшәлекләре яңара. Хәер, монда турыдан-туры аналогияләр булмаска да мөмкин, Әмма кисешү нокталары бар, һәм алар бик тиз табыла; шуңа күрә башта кайбер тарихи фактларга игътибар итик, күтәрелгән теманың мөһим моментларына басым ясап, аның чыганакларына тукталып үтик.

Казанда рәсем сәнгате буенча махсус белем бирүнең тарихы күптәнге һәм данлы. Күренекле шәхесләргә һәм якты вакыйгаларга бай бу уку йорты моннан 120 ел элек формалаша. Әлбәттә, монда мөһим урынны 1895 елда *Император сәнгать академиясен тәмамлаган җирле рәссамнар инициативасы белән* ачылган Казан сәнгать мәктәбе (КСМ) били. Шунысын да әйтергә кирәк, *бу башлангыч җирле хакимият тарафыннан киң яклау таба,* алар аның эшләп китүе һәм үсеше дәверендә даими ярдәм күрсәтәләр, бу хакта махсус чыганакларда әйтелә [Казанская художественная..., 2014, с. 6; Ключевская, 2009, с. 7–9]. Россиянең күренекле сәнгать осталары Н.И. Фешин, П.П. Беньков, Д.Д. Бурлюк, Б.И. Урманче, А.М. Родченко, П.А. Радимов шушы мәктәптә белем алалар, аннан озак еллар үзләре шунда укыталар. КСМ традицияләре Совет чорында Казан сәнгать училищесында лаеклы дәвам иттерелә, һәм алар әле дә уңышлы алып барыла.

Тагын шул фактка игътибар итик: Казан Россиянең Казан үрнәгендә сәнгать мәктәпләре оештырган шәһәрләрендәге иң яхшы академияләре сафында. Мәктәпнең өстенлеге тагын шунда – ул күчереп алу өчен үрнәк, урта звено академик сәнгать мәктәбенең эталоны. Аны тәмамлаучылар

академиядә укуларын дәвам итәләр. Академия, зур суммаларга төшереп, менә дигән уку бинасы төзетә, бай уку әсбаплары булдыра. Әлбәттә, ул төп игътибарны программ һәм методик тәэмин итүгә, укытучы кадрлар туплауга юнәлтә. Анда уку дәверендә үзләрен танытып өлгергән Н. Фешин, П. Беньков. К. Мюфке кебек осталарны эшкә җибәрә.

Болардан тыш, Казан 1894 елда передвижниклар тарафыннан үзгәртеп корылган академиянең игътибарын җәлеп итә, ул махсус академик мәктәп оештыруга башлап кушылган беренче шәһәрләр рәтенә кертелә, аерым өстенлекләргә ия була. Бу нәрсә белән бәйле була соң? Монда сер юк. Тикшеренүчеләрнең күбесе моның төп сәбәбен *Казанның Идел–Кама һәм Урал арты регионының үзәгендә урнашуы* белән аңлаталар. Мәктәпне оештыру буенча академик документларда аз санлы халыклар белән бәйле мәгълүматлар да теркәлгән [Журналы заседаний…, 1896, с. 47; Ключевская, 2009, с. 8]. Бу сәбәпләргә тирәнрәк тукталсаң, башка, тагын да кызыклырак үзара бәйләнешләр ачыклана.

Әлбәттә, үзгәртеп корылган «яңа» академия мөһим юнәлешләр буенча, илдәге бердәнбер сәнгать югары уку йорты буларак, үзенең элеккеге данын торгызу сәясәтен алып бара, ул аңа шул чорда Россиядә барлыкка килгән күпсанлы хосусый уку йортлары һәм рәсем студияләре арасында өстенлекле урында ныгып калу өчен дә кирәк була. Академиянең яңа җитәкчелегенең пропаганда өлкәсендәге үз эшчәнлеге стратегиясе ышанычлы һәм уңышлы башлангычларга (сәнгать мәктәпләре оештыру, сәнгать әсәрләрен җирле фондларга тапшыру, күргәзмәләр оештыру) нигезләнә һәм аларны тормышка ашыру өчен Россиянең мәдәният һәм фән буенча белем бирү традицияләре формалашкан эре үзәкләре сайлана. Монда эре университет үзәкләре булган шәһәрләр арасында Казан һич тә читтә кала алмый. Шунысы да мөһим: Казан университетында нәфис сәнгатьне укыту алып барыла, соңрак сәнгать тарихы кафедрасы һәм нәфис сәнгать музее оештырыла [Ключевская, 2008].

Казан Император университеты бу крайда бердәнбер югары уку йорты булмый. 1842 елда Казанда Император духовный академия (югары православие белеме бирү уку йорты) үз эшен торгыза; 1874 елда Казан ветеринария институты ачыла; 1906 елда Казанда хатын-кызлар өчен югары курслар (университет статусына ия дәүләттән тыш югары уку йорты) торгызыла.

Урта һөнәри белем бирү дә төрле юнәлешләрдә алып барыла: Россиядә химия буенча бердәнбер урта белем бирү уку йорты – сәнгать техник училищесы, Р.А. Гуммертның музыка мәктәбе, юнкерлар пехота училищесы, коммерция училищесы, укытучылар институты һәм шулар янәшәсендә сәнгать мәктәбе дә. Йөзьеллык ахырына Казанда ир балалар өчен – 4, кыз балалар өчен 3 гимназия; реальное училище, һөнәрчелек училищесы,

шулай ук Родионованың затлы нәселдән булган кызлар институты эшли [Образование…, 2008].

Болардан тыш, Казанда мөселманнар өчен дини белем бирүнең тарихи калыплашкан системасы була: башлангыч һәм урта белем бирү мәдрәсәләре һәм югары мөселман мәктәбе эшли. Шулай ук бишенче җәмигъ мәчете имамы Галимҗан Баруди һәм аның этисе сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Галиев тарафыннан 1882 елда оештырылган атаклы «Мөхәммәдия» (ул Г. Барудиның этисе хөрмәтенә шулай атала) мәдрәсәсендә, дини белемнәр белән беррәттән, дөньяви фәннәр дә укытыла. *Ягъни XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында Казанда, милләтенә, тоткан диненә, сословиесенә карамастан, хатын-кызлар өчен дә, ир-атлар өчен дә төрле юнәлештәге белем алу мөмкинлеге була.*

Шулай итеп, Казанда, гомуммәдәни күзлектән караганда, белем күтәрү өчен гаять уңайлы тирәлек барлыкка килә: профессор-укытучыларның киң катлавы һәм шәкертләр составы шәһәрдә демократик алгарыш атмосферасы тудыралар, киң җәмәгатьчелекнең укымышлылык дәрәҗәсенә, аларның мәдәни һәм фәнни кызыксынучанлыгына йогынты ясыйлар. Моннан тыш, шәһәрнең үзенең театры була, анда театр, музыка сөючеләр өчен түгәрәкләр оештырыла. әдәби салоннар эшли, шул ук 1895 елда Казанда нәфис сәнгать сөючеләр җәмгыяте берләшә, нәшриятчелек эше гөрләп бара. Даими рәвештә җирле рәссамнарның һәм бөтен илгә танылган «Иптәшлек» («Товарищество») җәмгыятенең күчмә күргәзмәләре һәм сәнгать академиясенең үзенең күргәзмәләре оештырыла. Бу яклар хәйриячеләргә һәм һәркемгә мәгълүм А.Ф. Лихачев, аның бертуганы И.Ф. Лихачев кебек коллекционерларга бай була. И.Ф. Лихачев, мәсәлән, бертуганы вафат булганнан соң, аның коллекциясен 1895 елда музей оештыру өчен шәһәргә бүләк итә.

Болар барысы да *үзгәртеп корылган академия рухына тәңгәл килгән демократик шартларда* эшләүче сәнгать мәктәбенә ышанычлы таяныч була һәм аның үсешенә уңай йогынты ясый, һәм моны академия үзе дә игътибар үзәгендә тота. Шуңа да сәнгать мәктәбе ачылу җәмгыятьтә зур резонанс тудыра, ул тарихи масштабтагы вакыйгага әйләнә. Мәктәп, шәһәрдә генә түгел, бөтен төбәкнең сәнгать үзәгенә әверелә, анда һөнәри әзерлекле рәссамнар әзерләнә, зур күләмле кургәзмәләр оештырыла башлый, һәм мәктәпнең эшчәнлеге, рекламаларсыз да, вакыт таләп иткәнчә, уңышлы үсеш ала.

Кискен тарихи үзгәрешләр, хәтәр инкыйлаплар, гражданнар сугышы, алардан соң Бөек Ватан сугышы кичергән елларда да мәктәп үзенең эшчәнлеген туктатмады һәм әле бүген дә дәвам иттерә. Бу – Казан сәнгать тормышының чыганагы, чишмә башы нинди зур куәткә ия булуын дәлилли. Мәктәпнең фәкать исемнәре генә үзгәрде. Менә ярты гасырдан артык инде ул «Сәнгать училищесы» дип атала. Ә 2006 елдан башлап, ул

күренекле якташыбыз, мәктәптә укыткανда яшь рәссамнар формалаштыруга зур йогынты ясаган «Н.И. Фешин исемендәге» дип йөртелә. Шуңа күрә аны рәссамнар даирәсендә «Фешин» мәктәбе дип кенә атыйлар.

Әлеге мәктәпнең тарихи якларына болай киң тукталу юктан гына түгел: күп кенә тарихи мизгелләр, вакыйгалар спиральсыман үрелеп бара, алар хәзер дә кабатланырга мөмкин.

Мәктәпнең тарихы хәзер ни рәвешле дәвам итә соң? Казанышлары, уңай яклары һәм югалтулары нидән гыйбарәт, Казанда югары дәрәҗәдәге сәнгать белеме бирүнең үсеше заман таләпләренә туры киләме?

Казан сәнгать мәктәбен сәнгать югары уку йортына үзгәртеп коруның билгеле бер тәҗрибәсе бар инде. Үз тарихының кыска бер дәверендә (фәкать берничә ел) мәктәп югары уку йорты статусында булып, Югары сәнгать-техник остаханәләре исемендә йөрде, 1920 елларның беренче яртысында – Казан сәнгать-техник институты, аннан соң Казан архитектура-сәнгать остаханәләре (АРХУМАС), статусы белән тагын урта белем бирүче сәнгать мәктәбенә әйләнде. Берничә ел аның ректоры архитектор, талантлы педагог, Казанда сәнгать белеме бирүдә фидакарьлеге белән танылган Ф.П. Гаврилов булды. Сәнгатьтә барлыкка килгән төрле агымнарның үз иҗади позицияләрен яклап иҗади көрәш алып барган ул чорда, мәктәп аларның һәркайсын үзенә сыйдыра. Кызганычка каршы, Гавриловның дөньядан вакытсыз китүе, финанс ягыннан килеп туган катлаулылыклар, югары органнар тарафыннан якланмау һәм башка сәбәпләр белән мәктәпкә яңадан махсус урта уку йорты статусы әйләнеп кайта, берара ул хәтта техникум дип тә атала. Шулар белән беррәттән, мәктәп үзенең бинасыннан башка урынга күчерелә.

Казан сәнгать мәктәбе (директоры – О.А. Гыйльметдинова) бүген дә шул статуста эшен уңышлы дәвам итә, һәм махсус сәнгать уку йортлары арасында әйдәүче урынны били, Идел буе методик зонасы сәнгать училищелары өчен үзәк база ролен үти. Шуңа игътибар итик, уку йортына «техникум» билгеләмәсе училище администрациясе тырышлыгы белән яңадан әйләнеп кайтты, ул аның төп исеме янәшәсендә куштырнаклар эчендә бирелә.

Казанда сәнгать институтын торгызу ихтыяҗы турында идеяләрнең, фикерләрнең тынганы юк, ул «мәктәп – училище – югары уку йорты» чылбырының югары буыны буларак таләп ителә. Бу хакта сүз 2000 елларга аяк баскач тагын да тирәнәйде. Чөнки социаль, икътисади һәм сәяси күренешләр белән катлауланган бүгенге тормышны мәгълүмати агым, күпсанлы техник яңалыклар, компьютер техникасы, интернет системасы яулап алды. Ә ул һәркемнән заман бергә атлауны, «формада булуны» таләп итә. *Югары белем зарурлыгы* бәхәссез, һәм бүгенге яшь рәссам шушы гомуми ритмга кушылырга омтыла, ә аның осталык дәрәҗәсен фәкать югары мәктәп кенә бирә ала.

2005 елда училище үз бинасына әйләнеп кайткач (аны кире үзенә бирү нигездә 2000 еллар башында ук башкарыла), Казанда сәнгать югары уку йорты булдыру мәсьәләсе тагын да көчлерәк яңгыраш ала. Ниһаять, Казан рәссамнары, училище җитәкчелеге һәм укытучылар составы күтәргән идея иң югары дәрәҗәдә – Россия масштабында танылган сәясәтче, ТРның ул чактагы президенты М.Ш. Шәймиев тарафыннан яклау таба, аннан соң аны ТР Мәдәният министрлыгы хуплый, һәм шуннан башлап аның тормышка ашуына өмет уяна.

Инициаторларның күбесе В.И. Суриков исемендәге сәнгать институтын тәмамлаучылар булганлыктан, Казан учредительләренең төп игътибары шушы югары уку йортына һәм Россия Сәнгать академиясенә (Петербургтагы И.Е. Репин исемендәге рәсем сәнгате, сынлы сәнгать һәм архитектура институты белән беррәттән безнең институт та шул системага керә) юнәлә. Бу мәсьәлә хакында Сәнгать академиясе президенты З.К. Церетели белән сөйләшкәннән соң, югары уку йортын ачуга әзерлек башлана. Шулай итеп, *тарих кабатлана: җирле рәссамнар инициативасы яклау таба һәм Сәнгать академиясенең турыдан-туры катнашы белән җирле хакимиятнең хуплавына ирешелә* (моннан йөз ел электәгечә).

Институтны рәсми ачу 2008 елның мартында уздырыла (директоры итеп ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Мәскәүдә В.И. Суриков исемендәге Сәнгать институтын тәмамлаган М.А. Ваһапов билгеләнә). 2008 ел ахырында Институтка кабул итү имтиханнары уздырыла, 2009 елдан уку-укыту процессы башлана. Беренче булып скульптура факультеты эшли башлый, аннан соң сынлы сәнгать һәм графика факультетлары ачыла.

Казанда В.И. Суриков исемендәге Мәскәү академия сәнгать институтының бердәнбер филиалы булган сәнгать югары уку йорты ачылу, Татарстан Республикасы өчен генә түгел, шушы регионга якын тирәлек өчен дә мәдәни тормышта инде күптән көтелгән мөһим вакыйга буларак кабул ителә. Чөнки Казан якын-тирә республикалар һәм регионнарның иҗади көчләрен туплау өчен җайлы булган, Европа белән Азия культурасы кисешкән, шул ук вакытта ил башкаласына якын торган җирдә урнашкан шәһәр. Шуңа күрә дә Татарстан башкаласына *Россиянең үзәгеннән ерак урнашкан, Мәскәү белән Петербург арасындагы төрле милләт халыклары мәдәни үсешенең арадашчысы, аны таратучы миссиясе йөкләнә.* Институтка кабул ителгән беренче төркемнәр үк моны раслый. Булачак рәссамнар Казан институтына Петрозаводск, Самара, Пенза, Ульяновск, Саратов, Краснодардан, шулай ук Идел буеның милли республикалары – Башкортстан, Удмуртия, Мари Эл, Чувашиядән килеп белем алалар.

Шунысы да мөһим, талантлы балаларның һәркайсының да финанс ягыннан Мәскәүгә китеп уку мөмкинлеге булмый,

ә Казанда ул арзангарак төшә. Сәләтле, әмма матди яктан мөмкинлеге булмаган яшь рәссамнарга биредә тулысынча ачылу өчен шартлар җитәрлек: Казан куәтле мәдәни мохиткә, күргәзмә эшчәнлеге төрлелегенә, көчле укытучылар составына, бай методик базага һәм, ниһаять, менә дигән махсус бинага ия.

Казанда сәнгать институты ачуның тагын бер мөһим ягы – ул да булса, соңгы дистә еллар дәвамында училищены тәмамлаучыларның күбесе башкаладан киткән иде һәм аларның бик азы генә кире кайта. Шуның нәҗитәсендә илнең мәдәни тормыш белән кайнап торган эйдәүче үзәге – Казанда сизелерлек сәнгати бушлык хасил булды, 1980–1990 еллар рәссамнары буыны белән хәзер аны тулыландыру авыр бара, һәм бу күренеш болай да катлаулы булган җирле сәнгати цехларның бөтенләй таралуына китерергә мөмкин. Соңгы елларда җәмгыятьне демократияләштерү шартларында рәссамнарның барлыкка килгән берничә берлекләре арасында бер-берсеннән ризасызлыклар китереп чыгаруга сәбәп булган, бездә болай да рәссамнар кирәгеннән артык күп, дип сөйләнүләр бөтенләй урынсыз. *Чөнки Казан сәнгать берләшмәсендә XX гасыр башындагыча сәнгатьтә принципиаль карашлар туу статус, сәнгати иерархия буенча берничә берлек рәвешендәге номенклатур бүлгәләнүне, Казан сәнгатенең тирән кризис кичерүен аңлата.* Моны күптән танырга вакыт, чөнки алар арасында бердәмлек юк, ә идеягә нигезләнмәгән бердәмлек исә хәзер нинди дә булса бер идеягә мәҗбүри буйсынуны күздә тотмый, ә иҗади, билгеле бер төркемгә хас, уртак конструктив һәм иҗади башлангыч булмау иҗади берләшмәләр оешуга этәрә. Хәер, мондый хәлләр хәзер яңалык түгел, илнең күп регионнары сәнгате өчен бу күренеш таркаулык дәвере белән аңлатыла. Шушындый шартларда сәнгать югары уку йорты барлыкка килү берләшмәләр өчен дә, формалашып килүче осталар һәм яшь буын өчен дә дәртләндереп җибәрә торган чыганак булыр иде, иҗади көчләрне берләштерергә, регионда рәссам статусын күтәрергә ярдәм итәр иде.

Сәнгати Казан мондый хәлләрне еш кичерә. Тарихка әйләнеп карасак, шул ук 1930–1940 еллардагы репрессияләр, сугыш һәм башка сәбәпләр белән бәйле рәвештә Казаннан күп кенә сәләтле рәссамнар китә, шәһәрдә әйтеп үтелгәннәргә охшаш вазгыять туа, җитди үзәк басмаларда алар киң яктыртыла. «Творчество» журналында сәнгать белгече Н.Г. Машковцевның «Художественная жизнь Казани» дигән мәкаләсе басыла. Анда автор болай ди: «Еще совсем недавно столица Татреспублики имела репутацию города, отличающегося развитой художественной культурой. В Казани постоянно устраивались выставки с участием художников Москвы и Ленинграда. Казанское художественное «сегодня» представляется бесконечно менее отрадным, чем «вчера»». Автор рәссамнар гына калуы, скульпторларның нигездә булмавы, кайчандыр

Казанда гөрләп үскән графиканың юкка чыгуы турында да басым ясап белдерә. Шулай ук ул үз мәкаләсендә графикларның станок рәсеме һәм эстамп өлкәләрендә эшләүләре хупланмавын һәм, әлбәттә инде, Казанда сәнгать белеме бирүнең элеккеге данын торгызу зарурлыгын да күтәрә [Машковцев, 1940, с. 14]. Болар хакында югары дәрәҗәдәге төрле утырышларда, аерым алганда, 1940 елда СССР Рәссамнары берлегенең Оештыру комитеты III пленумында сүз күтәрелә.

Казанда сәнгать югары уку йорты булдыру буенча Россия Сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы, 1951 елдан башлап 25 ел дәвамында ТР Рәссамнар берлеге рәисе, «Зур Идел» («Большая Волга») зона күргәзмәләр комитеты рәисе вазифаларын башкарган Х.А. Якупов та бик актив эш алып бара. Совет иленең сугыштан соңгы чорында татар тасвирый сәнгать өлкәсендә мөһим фигура буларак, ул Казанда Россия Сәнгать академиясенең иҗади остаханәсен оештыра, Татарстан сәнгать системасының җитешмәгән буыны саналган Казан сәнгать институтын оештыруның мөһимлеген даими искәртеп тора.

2000 елларда Казанда сәнгать югары уку йорты төзү турында сүз барганда, аның академик белем бирергә тиешлегенә төп басым ясала. Чөнки югары сәнгать белеме бирү төрле юнәлештәге уку йортларында (Мәдәният институты, КФУ, КДАТУ, КФТТУ һ.б.) алып барылган Казанда рәсем сәнгате, сынлы сәнгать буенча югары белем алу мөмкинлеге әлегә кадәр булмады. Төп академик белем бирү элек-электән уку һәм фәнни процессның фундаментын тәшкил итә, бу очракта сүз иҗади сәнгать процессы турында бара. Ә аннан тиз генә табыш алу мөмкин түгел (гәрчә чиновниклар һәрчак шуны кабатласалар да), моңа Мәктәпкә дәүләткүләм әһәмияткә ия озак вакытлы кертемнәр белән, аның дөньякүләм бәясен күтәреп, югары дәрәҗәдәге профессионализмга нигез салып кына ирешергә мөмкин.

Нәфис сәнгать сферасы өчен бу бигрәк тә мөһим. Бүгенге көндә дөньяда мондый югары мәктәпләр бик аз калды. Россия алар арасында академик сәнгать белеме бирүнең бөтенлеген, осталык үзләштерүнең традицион, классик системасын саклап калган ил, ә Европадагы сәнгать мәктәпләренең күпчелегендә моңа охшаш система юкка чыккан. Россия Сәнгать академиясе быел 260 еллыгын билгеләп үтә, төрле тарихи бәрелешләргә карамастан, үз мәктәбен саклап калу һәм киңәйтү өчен бу бик зур срок.

Татарстан Республикасының элеккеге президенты М. Шәймиев үзенең алдан күрүчәнлеге белән регионда мәдәни үсеш перспективасын дөрес күзаллады. Академик фәннәр өчен һәрьяклы терәк саналган университет, музыкаль сәнгатьнең югары академик мәктәбе исәпләнгән консерватория янәшәсендә Казанда сәнгать белеме бирүнең югары академик мәктәбе эшли башлады. Төрле белем бирү филиалларына каршы кампанияләр колач җәйгән бүгенге заманда бу уку йорты

*илдәге бердәнбер югары академик сәнгать мәктәбе филиалы* булып калды. Мәскәү дәүләт академик сәнгать институтының Казан филиалы шундый шарт белән ачыла: алга таба ныклап эшли башлагач, куәтле потенциалга ия бу уку йорты, 2013 елдан соң Идел буе белән Уралның мөстәкыйль академик югары белем бирү уку йортына әйләнергә, башкаланың Сәнгать академияләре системасындагы югары уку йортлары янәшәсендә үз урынын биләргә тиеш була. Монда тагын шундый чагыштыру урынлы булыр: үз вакытында Император сәнгать академиясе дә илдәге башка сәнгать мәктәпләренә эталон сыйфатында Казан сәнгать мәктәбен ачу позициясен яклады. Башкала дәрәҗәсен раслаучы факт түгелмени бу.

Соңгы елларда Татарстан башкаласы да шәһәргә килгән кунакларны, туристларны сокландырырлык борынгы архитектур күренешләре, заманча төзелгән шәһәр мохите, скульптуралар, фонтаннар, кызыклы сәнгати һәм техник чишелешләр ярдәмендә җанландырырлган парк һәм скверлары белән заманча югарылыкка омтыла. Ә бит шәһәрнең ирешелгән матурлыкларын, Татарстанның башка хәзинәләрен (Болгар, Зөя, Алабуга һ.б.ны) үз хәлендә саклау, аны тагын да үстерү өчен читтән китерелгән осталар гына җитми, монда сәнгати югарылыкта фикер йөртергә сәләтле, туган ягыбызның бай тарихын, этник үзенчәлекләрен, аның гаҗәеп толерантлыгын, кабатланмас матурлыкка ия су һәм тау ландшафтларын каерли, бәяли белгән үзебезнең белгечләребез кирәк. Төрле профильдә иҗат итүче югары класслы архитекторлар, рәсем осталары, скульпторлар, монументальчылар, пыяла һәм металл белән эшләүче белгечләр кирәк. Шәһәрне үзенең туган иле итеп тоя торган, аның ритмын һәм сулышын, характерын һәм рухын сиземләп, аларны үзенеке санап, шунда күп еллар яшәгән, үзенең шушы барлык хисләрен иҗатында кыю һәм тулы итеп гәүдәләндерергә сәләтле рәссамнар кирәк. Б. Урманче, П. Радимов, Х. Якупов һәм И. Зарипов, менә дигән монументалист В. Федоров һәм башка бик күпләр әнә шундыйлар иде, боларга өстәп әйтерлек үз шәһәренә гашыйк рәссамнар, скульпторлар, архитекторларыбыз күп безнең. Әмма әйтеп киткән осталарның берсе дә югары белемне Казанда алмый, Казан рәссамнары өчен бу һәрвакыт катлаулы була. Һәм менә, ниһаять, үзебезнең югары академик мәктәп!

Кайбер чигерешләр ясап, уйлап куясың: мондый башкалача аспектка түбәндәгеләрне өстәү урынлы булыр сыман. Шуны аңларга кирәк, бүген бик керемле һәм модный саналган спорт объектларына һәм спорт чараларына гына таяну, алар бик популяр булсалар да, шактый хәвефле юл. Вакытлар узу белән югары белемлелек, культуралылык, студентлар күплеге белән аерылып торган, үзенең тарихы, милли чагылышы белән гаять күп төрлеләккә ия бүгенге заман шәһәренең имиджы төссезләнергә һәм тар мәгънәдәге спорт үзәгенә,

спорт форумнары өчен төзелгән ниндидер олимпия авылына әйләнеп калуы да мөмкин. Элеккедән сакланып килгән традицияләргә бай Казанның җәлеп итү сыйфаты юкка чыгачак, ә бу күренеш үз тарихына, бай мәдәнияткә ия шәһәрнең башкала статусын һичшиксез түбәнәйтәчәк. Кайсы да булса бер юнәлешнең өстенлегенә омтылып, калганнарының җимерелүенә китергән очраклар тарихта аз түгел. Сәламәт кешегә шөгыльләнү өчен зур суммалар түгеп гаҗәеп зур стадионнар һәм комплекслар төзү әйбәт анысы, әмма бу гына аз. Антик чорларда зирәк греклар тәннең сәламәт, көчле булуы өчен спорт чараларына зур әһәмият бирү белән бергә, сәнгатьчә гәүдәләнеш, тән матурлыгының эстетик образлылыгына ирешү хакында да онытмаганнар, шуңа күрә сәнгать сыйфат ягыннан җитди алгарыш кичергән, нәтиҗәдә Греция Европа мәдәниятенең (Россиянең дә) бишегенә әверелгән. Мәдәни кыйммәтләрне булдыру, булганнарын саклау һәм үстерү – бу безнең рухи азыгыбыз, мәңгелекнең нигезе, халыкның бердәйлеге; аннан башка алга таба юл юк, үзен уникаль санаган, үзенең тарихы һәм заманча казанышлары булган милләтнең тулы чагылышы юк. Гамәлдәге, бар мәдәниятне югалту һич гафу ителми, чөнки аны бернәрсә дә – түбән дәрәҗәдә эшләнгән сувенир эшләнмәләр дә, чәкчәк яки матрёшка кебек символлаштырылган әйберләр дә алыштыра алмый. Бер үк тырмага кабат-кабат басуны туктырга һәм булганны гасырлар, дистә еллар дәвамында ирешелгәннәрне кадерен белеп сакларга вакыт түгелме?

Казан сәнгате җәмәгатьчелегенең күптән көтелгән җимеше барлыкка килү, ныгу процессы ничек бара соң? Ул әкренлек белән, динамик рәвештә ышанычлы үсеш темпы ала, һәм бу хәрәкәт көчәя бара. Барлык педагогларның беренче чираттагы бурычы уку процессын җайга салу була, ягъни академик программаны үзләштерү, рәсем, композиция һәм башка махсус фәннәрне укыту методикасы булдыру; төрле юнәлешләр буенча (станок рәсеме, басма графика, монументаль сәнгать, скульптура) уку-укыту базасын булдыру. Укытучылар коллективы үзе дә, рәссамнар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгына карамастан, берничә ел эчендә фикердәш коллектив булып формалаша, аның үзәген Петербург һәм Мәскәү сәнгать мәктәпләрен тәмамлаучылар тәшкил итә [Лобашёва, 2014. С. 64–70].

Институтка абитуриентлар җәлеп итү максатыннан, Казан сәнгать училищесы белән бергәләп Бөтенроссия масштабындагы фәнни-гамәли конференцияләр һәм илдәге барлык сәнгать училищеларының күргәзмәләре оештырыла. 2009 елда – Институт эшчәнлегенең башында ук, мәсәлән, конференцияләрнең берсенә туры китереп, Россиядәге рәсем сәнгате училищелары (15) һәм академик сәнгать училищесы шәкертләренең иҗади эшләреннән күргәзмә оештырыла [Лобашева, 2009, с. 67–73]. Аларның географиясе, Россия үзәген-

дәге Тверь һәм Орел шәһәрләреннән башлап, көньяктарак урнашкан Волгоград һәм Самара, шулай ук илнең төньяк-көнчыгыш регионындагы Чиләбе, Оренбург, Екатеринбург шәһәрләрен колачлый. Анда күршеләребез Чебоксар, Түбән Новгород, Ижевск, Йошкар-Оладан да катнашалар. Мәскәүдән, куратор буларак танылган педагоглар, В.И. Суриков исемендәге Дәүләт академия сәнгать институты профессорлары килә. Шуны ассызыклап әйтергә кирәк, күп кенә училищелар (мәсәлән: Екатеринбургтагы, Вятка, Волгоград, Орел, Пенза, Самарадагы) ул вакытта озак еллар тупланган нәтиҗәләрен Казанда беренче тапкыр тәкъдим итеЛә.

Киң колачлы бу очрашуда сәнгать белеме бирү процессындагы уртак проблемаларны бергәләп хәл итәргә сусаган белгечләр Казан сәнгать институты барлыкка килүне дә рухланып кабул итәләр. Күптән көтелгәнчә, якын-тирә регионнарның бу башлангычны хуплаулары Идел–Кама регионы сәнгать тормышында Казанның, эре сәнгать үзәге буларак, потенциалын һәм зур әһәмияткә ия булуын раслый.

Башта В.И. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академик сәнгать институты, үз студентларының Казан филиалына укыту өчен методик материал рәвешендә биргән эшләреннән, шушы филиалда күргәзмәләр оештыра. Андый материаллар Казанга берничә мәртәбә җибәрелә, һәм филиалда алардан шактый югары дәрәҗәдәге методфонд туплана. Бу югары уку йортының китапханәсе дә даими тулыланып тора. Сәнгать академиясенең Казан сәнгать мәктәбенә кураторлык итүенең нәтиҗәсе булып, мәктәп коллекциясендә академик дәрәҗәдәге сәнгать әсәрләре, И.Е. Репин, И.И. Шишкин, К.Е. Маковский һәм шул заманның башка күренекле рәссамнары картиналары, скульптур һәм гравюр эшләнмәләр коллекциясе туплана, алар XIX–XX гасырлар чигендә мәктәпнең тулы бер музеен тәшкил итәләр [Дары Императорской…, 2003].

Өйрәнләп студентларга белем бирү дәрәҗәсе күтәрелә, эшнең сыйфаты яхшыра. Бу югары уку йорты ачылып, бер ел узуга мәктәпнең үзендә аның укытучылары һәм студентлары эшләреннән күргәзмәләр оештырыла башлый. Ниһаять, анда укучылар да, үзләренең педагогларына ияреп, Бөтенроссия һәм региональ дәрәҗәдәге зур күргәзмәләрдә, «Зур Идел» («Большая Волга») кебек махсус проектларда, яки Бөек Ватан сугышына багышланган юбилей күргәзмәләрендә, я булмаса, Мәскәү, Ульяновск, Саранск, Волгоград һәм башка шәһәрләрдә оештырылган яшь рәссамнар күргәзмәләрендә үз әсәрләре белән катнаша башлыйлар. Шундый зур күргәзмәләрнең берсе Россия башкаласындагы югары уку йорты белән берлектә Казанда (2014 елда) уздырыла. Институтның биш ел дәвамындагы тынгысыз эшчәнлегенең нәтиҗәсен күрсәткән бу күргәзмәдә безнең студентларыбыз да, үзләренең Мәскәү сабакташларыннан калышмыйча, лаеклы иҗади әсәрләрен тәкъдим иттеләр.

Скульптура бүлеге уңышлы үсеп китә. 2014 елда филиалның беренче чыгарылышы була. Скульптура бүлегенең диплом комиссиясе составындагы илнең танылган скульпторлары – Суриков һәм Репин институтлары укытучылары – яшь иҗатчыларның әзерлек дәрәҗәләрен югары бәяләделәр [Лобашева, 2017, с. 146–152]. ТюркСОЙ форумнарында, скульптура буенча даими уздырыла торган (шул исәптән Казанда да) симпозиумнарда, төрле конкурсларда катнашу Казанда скульптура сәнгатенең, озакка сузылган кризистан соң торгызыла башлавын дәлилли, һәм безнең А.М. Миңнуллина җитәкчелегендәе скульптор егетләребез үзләрен тиешле югарылыкта күрсәтәләр. Әйтелгән чараларда катнашу нәтиҗәсендә безнең яшь иҗатчыларыбыз, катлаулы тематик скульптур композицияләр эшләп, Казан Кремле һәм шәһәребез парклары, Республиканың район үзәкләрендәге мәйданнар һәм скверлар, һәм хәтта Мәскәү бизәлешенә үз өлешләрен өстәделәр. Алда факультетның ике чыгарылышы, алар яңа проектлар әзерли.

Филиалның һәр чыгарылышында диплом яклау (барысы 4 чыгарылыш) Мәскәүдә зур вакыйга төсен ала. Диплом эшләренең күбесе иң яхшы билгесе белән бәяләнә, Мәскәүдәге коллегаларыбыз ул эшләрнең югары дәрәҗәдә үтәлүен, күп яктан хәтта башкала институтында белем алучыларнныкыннан да яхшырак эшләнүен билгеләп үтәләр.

Кемнәрдер тарафыннан һәм матбугат битләрендә филиалның имиджы һәм әһәмияте хакында түбәнсетеп, янәсе институтта укыту йомшак куелган, студентларның белем һәм күнекмәләре түбән дәрәҗәдә, дигән фикерләр белән очрашкач, аның чынбарлыктагы уңай нәтиҗәләренә тукталасы килә. Егетләребезнең төрле конкурслар һәм симпозиумнар лауреатлары булуы, халыкара пленэрларда һәм форумнарда катнашулары, Сәнгать академиясенең диплом һәм рәхмәтләрен яулаулары турында горурланып сөйлибез. Әле менә 2017 елның июлендә генә филиалның берничә студенты сайлау аша үтеп, Кырымда уздырылган Бөтенроссия яшьләр белем форумы «Таврида»да катнаштылар, анда безнең филиалны тәмамлаган А. Санникова үз проектын гамәлгә кертү өчен 200 мең сумлык сертификат отты. Мөгаен безнең филиалга мәгълүмати пиар-кампанияләр, аның үзе, казанышлары, уңышлары һәм, әлбәттә инде, төрле дәрәҗәдәге (Рәссамнар берлеге кебек якындагы сәнгати тирәлектән, җирле хакимият тарафыннан) ярдәм һәм яклау, институтның хәле белән тирәнтен кызыксыну җитми.

Институтның киң колачлы эшчәнлегенең логик нәтиҗәсен тагын бер мөһим вакыйга тәшкил итә, ул – *Рәссамнар берлеге каршында яшь рәссамнар бүлеге оештырылу* (анда филиалның 43 студенты керә). Менә алар бу уку йортының реаль казанышлары! Казан сәнгать мәктәбе традицияләрен дәвам итәргә сәләтле варислар – лаеклы алмаш әзерләү өчен күпме көч түгелгән, тырышлык, вакыт сарыф ителгән. Нәкъ

менә алар Республика сәнгать тормышының 1990 елларда барлыкка килгән бушлыгын тутыручы куәтле резервны тәшкил итәләр. Әмма бу яңа катламны якларга, аларга ярдәм итәргә. сәнгать киңлегенә юлны киң ачарга кирәк.

Гомумән алганда, илдә мәдәниятне һәм белем бирүне үстерү вазгыяте бик нык үзгәрде. Россиядә белем бирү, шулай ук Фәннәр академиясендә һәм Сәнгать академиясендә барган үзгәртеп корулар бик авыр кабул ителде, ул хакта күпсанлы фикер алышулар һәм дискуссияләр уздырылды, шуларның нәтиҗәләреннән чыгып бәяләгәндә, ул үзгәрешләрне яклаучыларга караганда, аңа каршылар күбрәктер мөгаен.

Институтның эшен дәвам иттерү мәсьәләсе 2014 елда күтәрелде, чөнки килешү нигезендә ул Федераль тәэмин ителүгә күчеп, Россия Сәнгать академиясе аша финансланырга тиеш иде. Әмма Академиянең үзендә үзгәртеп корулар башланды. Сәнгать уку йортларын аның составыннан чыгарырга карар кылынды. Нәҗитәдә филиал аккредитация үтмәде. Бу мәсьәлә 2014 елда матбугат битләрендә актив яктыртылды [Акчурина, 2014; Казанский филиал института…, 2014; Карабанова, Нигматуллин, 2014; Юхновская, Иванов, 2014]. Шулай итеп соңгы реформалар Казан филиалының үсешенә ярдәм итмәделәр, киресенчә, аның эшчәнлеген куркыныч астына куйдылар.

Бу хәл бик гади аңлатыла. Соңгы еллардагы яңалык кертүләрдән аермалы буларак, 120 ел элек Император академиясе үзендәге реформаны үзе уздыра, ул бу белем йортының кирәклеген тоеп, аны килеп туган кризистан коткару өчен эшли, шул ук вакытта провинциядә үз статусын һәм имиджын ныгыту буенча инициативаны үз кулына ала. Хәзер исә андый реформалар өстәгеләр тарафыннан уздырыла, шуңа күрә Академия эшчәнлеген киңәйтү файдасына түгел. киресенчә, аның йогынты сферасын оптимальләштерү төшенчәсенә төреп башкарыла, мондый үзгәртүләр безнең көннәрдә бюджеттан финанслауга бәйләп аңлатыла, һәм ул, оптимистик рухта яңгыраса да, фәкать бер нәтиҗәгә кайтып кала: кыскарту, киметү, кисү һ.б. Моннан аңлашылганча, Мәскәүдәге кураторларыбызда бүген Казан сәнгать югары уку йорты кайгысы түгел, алар үз проблемалары белән мәшгуль. Аның үсеше, барыннан да бигрәк, Казан өчен, Татарстан өчен кирәк.

Шулай итеп, башкала канаты астында яшәү Казанда сәнгать югары йорты төзелү этабында туктый. Җирле хакимиятнең яклавы, ярдәме нәрсәдән гыйбарәт соң? Ул бит әлегә кадәр булды. Ә хәзер, Татарстан хөкүмәте йөкләмәсе буенча, филиал чикләнгән күләмдә генә (хезмәт хакы һәм коммуналь түләүләр өчен генә) финанслана. Уку йортына студентлар кабул итү тукталды, ягъни соңгы елларда ул әкренләп ябылуга, һәр чыгарылыш саен үлемгә бара.

2017 елның сентябрендә башкала югары уку йорты агымдагы елның 5 октябреннән Казан филиалын ябу турында карар чыгар-

ды… Калган студентлар укуларын Мәскәүдә дәвам итәчәк, ә Казандагы филиал рәсми рәвештә ябылачак. Шулай итеп, Казандагы махсус сәнгать уку йорты үз тарихын шундый күңелсез вакыйга белән тәмамлый.

Филиалда белем бирү процессының беренче көннәреннән үк сәнгать тарихы укытучысы һәм башка махсус курслар алып баручы, музей практикасы кураторы булырак, миңа аның эшчәнлегенең тере шаһите булырга, билгеле бер дәрәҗәдә аның тарихының елъязмачысы вазифасын үтәргә, уку йортында уздырылган күргәзмәләр, башка чаралар турында күзәтүләр язарга туры килде. Шуңа күрә институтта килеп туган вазгыять турында аларны тирәнтен аңлап, ачыктан-ачык язарга алынуым табигый хәл, чөнки мин аларны турыдан-туры кичергән кеше, бу – закончалык.

2018 елда безнең филиал эшли башлауга 10 ел тулган булыр иде. Бу – Казанда югары академик сәнгать белеме бирү өлкәсендәге тарихның беренче тәҗрибәләре чоры, аны өзү-туктату һич тә уйланмаган гамәл, киләчәкне күрә белмәү нәтиҗәсе. Чөнки шундый зур көч, кыенлыклар белән төзелгән югары уку йорты эшчәнлеген акча җитмәүгә, керемле тармак булмауга бәйләп туктату – ул гамьсезлек нәтиҗәсе, үкенечле гамәл. Мәгълүм булганча, институтның бурычы – профессионаллар әзерләү, белем һәм күнекмәләр бирү, әгәр аның мөһимлеген, әһәмиятен аңлау булса, аны матди яктан тәэмин итү өчен мөмкинлек табылачак.

**Әдәбият**

*Акчурина А.* Потеряем ли мы филиал Суриковского института в Казани? // Вечерняя Казань. 2014. 29 октября. https://www.stihi.ru/2014/09/18/963.

Дары Императорской Академии художеств Казанской художественной школе: каталог выставки, посвященной 300-летию Санкт-Петербурга. ГМИИ РТ / составитель и автор вступительной статьи И.Ф. Лобашева. Казань: Казань, 2003. 48 с.

Журналы заседаний и отчет Собрания Императорской Академии художеств за 1895 год. СПб, 1896. С. 47–48.

Казанская художественная школа. 1895–1920-е: альбом-каталог в рамках проекта «Художественные сокровища Татарстана» в 7 томах – Из собрания ГМИИ РТ: 5 том / ввтор вступительных статей И.Ф. Лобашева. Казань: Заман, 2014. 128 с.

Казанский филиал института имени Сурикова получил 2,7 млн. рублей // http://old.sntat.ru/reportages/6249 – опубликовано 13/11/14.

*Карабанова А., Нигматуллин А.* Казанское детище Церетели и Шаймиева оказалось под угрозой закрытия // БИЗНЕС Online. https://www.business-gazeta.ru/article/118979 – опубликовано 13/11/14.

*Ключевская Е.П.* Казанская художественная школа. 1895–1917. СПб: Славия, 2009. 240 с.

*Ключевская Е. П.* Изящные искусства в Казанском университете. Казань: [Б. и.], 2008. 127 с.

*Лобашева И.Ф.* Открывая новую страницу летописи казанского художественного ВУЗа // Перспективы развития художественного образования в

России: сборник материалов Всероссийской научно-практической конференции (МГАХИ имени В.И.Сурикова в Казани, 7–9 апреля 2009). Казань: Слово, 2009. С. 67–73.

*Лобашева И.Ф.* Первые шаги высшей академической художественной школы в Казани (2008–2011) // Вторые Казанские искусствоведческие чтения: материалы международной научно-практической конференции. К 130-летию со дня рождения Н.И. Фешина. 2–3 ноября 2011 (ГМИИ РТ, Казань) / Мин-во культуры Республики Татарстан, ГМИИ РТ; редкол.: Р.М. Нургалеева, Д.Д. Хисамова, О.А. Хабриева. Казань: Центр инновационных технологий, 2014. С. 64–70.

*Лобашева И.Ф.* Первый выпуск филиала Московского государственного академического художественного института имени В.И.Сурикова в Казани: дипломники скульптурного факультета (2014) // Искусствоведение Татарстана. Вып. I. Теория, история, современная художественная практика, арт-рынок / автор-составитель Р.Р. Султанова. Казань, 2017, С. 146–152.

*Машковцев Н. Г.* Художественная жизнь Казани // Творчество. 1940. № 6. С. 15–21.

Образование и просвещение в губернской Казани: сб. ст. / ред. И.К. Загидуллин, Е.А. Вишленкова. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2008.

*Юхновская О., Иванов О.* Появится ли в Казани банк имени Фешина? // Казанский репортер. http://kazanreporter.ru/post/291 – опубликовано декабрь/2014.

***Лобашёва Ирина Фаековна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының тасвирый һәм дикоратив-гамәли*
*сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре,*
*В.И. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академик*
*сәнгать институты доценты,*
*Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы*
*сәнгать тарихы укытучысы*

УДК 791.43

***Д.Р. Фәрдиева***

# XIII ХАЛЫКАРА МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕНӘ КҮЗӘТҮ

В статье дается обзор XIII Казанского международного фестиваля мусульманского кино. Фестиваль проходит в Казани с 2005 года. В программу фестиваля отбираются фильмы, отражающие общечеловеческие духовно-нравственные ценности и культурные традиции, несущие идеи миротворчества, веротерпимости и гуманизма вне зависимости от вероисповедания автора.

**Ключевые слова:** фильм, режиссер, фестиваль, картина, номинация, автор.

2017 елның 5–11 сентябрь көннәрендә Казаныбызда XIII Халыкара мөселман киносы фестивале узды. Ел саен уздырыла торган әлеге фестиваль шәһәр мәдәни тормышының үзенчәлеге булып тора. Аның кысаларында бөтендөнья кинематографистлары үзләренең иҗат җимешләрен тәкъдим итә. Күркәм гадәткә әверелгән әлеге чара бу елны унөченче тапкыр үткәрелде. Гадәттәгечә, фестиваль кысаларында Казанга танылган артистлар, режиссерлар, тәнкыйтьчеләр җыелды. Мөселман киносы фестиваленең төп максаты – гармониянe эзләү, кешеләрнең бер-берсенә итагатьле, мәрхәмәтле булуына ирешү, туган йортыңны, нигезеңне кадерли белергә өндәү. Фестивальнең бурычы исә – традицион исламның тынычлык сөя торган сыйфатын күрсәтү.

Быелгы бәйге программасында 27 илдән 60 кинофильм ярышты. Ә гомумән алганда, фестивальдә катнашу өчен 61 илдән 782 гариза килгән. Тәкъдим ителгән фильмнарның географиясе шактый киң: Азәрбайҗан, Албания, Һиндстан, Иран, Непал, Россия, Таҗикстан, Италия, Канада, Катар, Төркия, Марокко, Нигерия, Франция, Кыргызстан, Мальта, Үзбәкстан, Эстония, Швеция, Венгрия, Бельгия, Бангладеш, Әфганстан, Венгрия, Америка Кушма Штатлары, Дания... Фильмнарны «Мир», «Родина», «Киномакс», «Корстон» кинотеатрлары залларында тәкъдим иттеләр. Биредә, яшь режиссерлар белән бергә, инде дөнья күләмендә танылган режиссерларның исемнәрен күрергә дә мөмкинлек булды. Алдагы еллардан аермалы буларак, быелгы конкурс программасы кысаларында төп номинациягә нигездә Азия һәм Африка илләреннән тәкъдим ителгән картиналар ия булды.

Мисыр режиссеры Мәхди Әхмәд Алиның «Безнең пәйгамбәр» дигән фильмы әлеге чарага символик старт бирде. Фильм конкурстан тыш программада күрсәтелде һәм моны фестивальнең ачышы дип бәяләргә кирәк. Сценарий авторы – Мисыр телевидениесының күренекле алып баручысы, язучы Эбрахим Эсса.

Әлеге фильм бик нечкә темага кагыла – ул рухани турында. Бу картина дин һәм дәүләт, ислам һәм җәмгыять мәсьәләләрен күтәрә. «Безнең пәйгамбәр» – тирән мәгънәле һәм күңелне дулкынландыра торган фильм. Монда диннең сәясәт белән тыгыз мөнәсәбәте ачык күрсәтелә. Картина авторлары төп басымны дини бәрелешләргә ясаган. Төп герой Шәйх Хәтем – сәясәт һәм дин арасындагы тозакка эләккән дин әһеле. Дан казанган дин әһеле төрледән-төрле сынауларга дучар була. «Безнең пәйгамбәр» фильмы авторының әйтергә теләгән төп фикере – дини сабырлык. Төп рольне уйнаган актер Амр Саад үзенең эчкерсезлеге, кыюлыгы һәм осталыгы белән тамашачыларның күңелен яулап ала.

Бәйгенең «тулы метражлы уен фильмы» номинациясендә беренче тапкыр моңа кадәр аз гариза биргән яки бөтенләй катнашмаган илләр һәм төбәкләр керде (Банладеш, Нигерия һ.б.). Һәм шуны да искәртеп үтәргә кирәк: режиссерлар арасында хатын-кызлар да активлашта бара.

Мөселман киносы фестивале символы булган статуэткалар «иң-иңнәргә» каралган иде. Иң яхшы фильм булып Төркия белән Венгрия бергәләп төшергән «Каландар салкыны» (режиссеры Мостафа Кара) картинасы танылды. Вакыйгалар таулар арасында яшеренгән кечкенә генә авылда бара. Фильмның төп герое, Мәхмәт, бурычларын түләү өчен, таулар арасында көмеш табарга хыяллана. Психологик яктан бу авыр һәм бик тирән, тамашачыны уйландыра торган фильм. Актер Хәйдәр Шишман төп геройның тулы бер дөньясын гәүдәләндерә алган.

Тулы метражлы нәфис фильмның иң яхшы операторы булып Айрат Ямилов билгеләнде («Софичка» фильмы, Россия). Тулы метражлы нәфис фильмның иң яхшы сценарие – «Амун» фильмы (Россия), сценаристлары – Иван Заваруев һәм Анар Аббасов. Тулы метражлы нәфис фильмның иң яхшы актрисалары итеп Нахед Эль Себа, Илһам Шахин, Нелли Кәрим танылды («Хатын-кызлар көне», Мисыр). Ә иң яхшы ир-ат ролен башкаручы итеп Дулига Акмолда игълан итәлде («Оралман» фильмы, Казакстан). Тулы метражлы уен фильмының иң яхшы режиссеры – Мангеш Джоши («Токарь Джоши» фильмы, Һиндстан).

Шулай ук фестивальдә махсус бүләкләр дә каралган иде. Мәсәлән, жюриның махсус бүләгенә «Никахлашу балдагы» («Обручальное кольцо») фильмы лаек булды (режиссер Рахмату Кейта, Нигерия). Нигерия халкының туй йолаларын күрсәтүче бу матур һәм психологик яктан тирән кичерешле кинокартина Канаданың Торонто шәһәрендә, Лондон, Стокгольм, Буэнос-Айрес, Роттердам фестивальләрендә күрсәтелгән булган инде. Актриса Магаджая Сильберфельд үз героинясының эчке дөньясын, күңел кичерешләрен оста ача, аның төрле якларын хәтта күз карашы белән дә күрсәтә ала. Аның героинясы Тия күркәм холыклы, фикеренә, мәхәббәтенә тугры.

Быел «Милли кино секциясе» дигән яңа номинация

кертелде. Болар: «Тапшырылмаган хатлар», «Мирас угы» («Стрела наследия»), «Җәннәт», «Нәҗибә», «Хәбиб Аллаһ Мөхәммәд. Пәйгамбәрлек итүе һәм нәсел шәҗәрәсе», «Соңгы романтиклар вакыты» («Время последних романтиков»), «Диагноз», «Юлдан язган ул» («Блудный сын») һ.б. Гомумән, быел мөселман киносы фестивалендә Татарстаннан 13 фильм катнашты. «Секциянең максаты – үзебезнең фильмнарны зур экранга чыгару, милли кинематограф үсеше өчен мәйдан булдыру. Премия яхшы фильм эшләгән режиссер, продюсер яки компаниягә биреләчәк. Аны чираттагы проектлар яңа фильм төшерү, аерым төшерү этабында яки пост-продакшнда куллану өчен инвестицияләп була. Мондый чыгымнар әлеге тармакка стимул бирә, регионда яхшы көндәшлек булдыра, белгечләрне мотивацияли», – ди XIII Казан Халыкара мөселман киносы фестиваленең арт-директоры Альбина Нәфыйгова [http://idel-tat.ru/kazan-kinofestivale/]. Һәм шуны да билгеләп үтәргә кирәк: «Тапшырылмаган хатлар» фильмы режиссеры Рөстәм Рәшитов «Милли кинематографта татар классикасы чагылышы өчен» искәрмәсе белән Казан мэрының махсус бүләгенә ия булды.

Татарстан кинофильмнары, «Милли кино секциясе» номинациясеннән тыш, башка номинацияләрдә дә катнашты: «Кыска метражлы нәфис фильм» («Күзалла» – «Представь»), «Кыска метражлы документаль фильм» («Велохаҗ. Гадәти булмаган сәяхәт») һәм «Яшь Россия» («Кыскарту» – «Сокращение»). «Күзалла» картинасы режиссеры Илшат Рәхимбайга ТР Президентының «Сәнгатьтә гуманизм өчен» дигән махсус бүләге бирелде. Фильмның эчтәлеге болайрак: абыйлы-энеле ике бертуганның берсе мулла, икенчесе – атакай. Катнаш гаиләдә үскән ике туганны язмыш төрле якларга һәм төрле диннәргә аера. «„Күзалла“ фильмында мин фикеремне вуальләштереп кенә, метафора белән генә әйткән идем, ә фестиваль кысаларында күрсәтелгән «Безнең пәйгамбәр» (Мисыр) фильмында ул ачыктан-ачык яңгырады. Бигрәк тә ике дин янәшә яшәгән җирләр өчен бу – актуаль тема», – ди режиссер үзе [http://shahrikazan.com/news/kyiskacha-yaңalyiklar/bgen-ilshat-rhimbaynyi-kzalla-filmyi-tkdim-itel].

Россия кино белгечләре һәм кино тәнкыйтьчеләре гильдиясенең махсус бүләген «Хәлимә» картинасы өчен режиссер Юлия Захарова алды. Ул моңа теманы кыю сайлавы һәм фильмының фестиваль тематикасына идеаль туры килүе өчен лаек булды. Тагын бер яшь режиссер Ксения Охапкина «Ирекле көе кил» («Приходи свободным») картинасы өчен (фильмның актуаль тематикасы һәм гадәти булмаган чишелеше өчен) Россия кино белгечләре һәм кино тәнкыйтьчеләре гильдиясенең дипломын алды.

Узган ел старт алган «Яшь Россия» номинациясе дә уңышлы гына эшләп килде. Монда, гадәттәгечә, Россия авторларының төрле жанрдагы тасмалары һәм альманахлары кергән. Әлеге

номинациядә, Татарстаннан тыш, Свердловск, Ростов, Мәскәү өлкәләре, Башкортстан, Хакасия, Мари Эл республикалары, Красноярск крае кинорежиссерлары эшләре күрсәтелде.

Фестивальнең конкурс программасын Россиянең халык артисты, режиссер һәм сценарийлар авторы Николай Досталь рәислегендә булган абруйлы жюри бәяләде (жюри составына 11 илдән кинематографистлар һәм кино тәнкыйтьчеләре кергән).

Тамашачылар өчен, конкурстан тыш, параллель программалар да күрсәтелде. Мәсәлән, «Европа киносы», «Иран: чынбарлыкта һәм кинода», «Европага сәяхәт», «Нигерия экзотикасы», «Индонезия киносы», «Мисыр төннәре», «Кыргызстан – кыска метр иле», «Казакстан: кичә, бүген, иртәгә» дигән шәлкемнәр кысаларында фильмнар тәкъдим ителде. Моннан тыш, тамашачыларга «Андрей Кончаловский ретроспективасы», «Николай Досталь ретроспективасы» кысаларында әлеге режиссерларның фильмнары «Гашыйклар турында романс» («Романс о влюбленных»), «Җәннәт» («Рай»), «Петя – күкләр патшалыгына юл буйлап» (Петя по дороге в царствие небесное»), «Монах һәм шайтан» һ.б. күрсәтелде.

Фестиваль барышында атаклы кино сәнгате әһелләре, фестивальнең хөрмәтле кунаклары (танылган актерлар Наталья Варлей, Марат Башаров, Светлана Светличная, Анна Снаткина, Владимир Конкин, Сергей Маховиков, Кирилл Плетнев, продюсер Рубен Дишдишян, кино белгече Кирилл Разлогов һ.б.) катнашында кызыклы иҗади очрашулар да оештырылды.

Мөселман киносы фестивале кысаларында «Кино заманы» дигән белем бирү форумы да уңышлы эшләде. Фестивальнең тантаналы ябылышы М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында узды. Төрле артистлар чыгышлары, җыр һәм биюләр үрелеп барган тантана Татарстан Республикасының гимны белән тәмамланды. Гомумән алганда, Халыкара мөселман киносы фестивале көтеп алган бәйрәмгә әверелде. Ул үз урынын тапты һәм елдан-ел яңа сәхифәләрен ача һәм биегрәк баскычка күтәрелә бара.

***Фәрдиева Динара Радий кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 74

***К.Б. Касенова***

# КАЗАК КЕЛӘМНӘРЕ ОРНАМЕНТЫНЫҢ ТАРИХИ ҮСЕШЕНДӘ ГАРӘП-МӨСЕЛМАН МӘДӘНИЯТЕ РОЛЕ

В статье раскрывается влияние и роль арабо-мусульманской культуры в орнаментике казахского ковра.

**Ключевые слова:** арабо-мусульманская культура, ислам, орнамент, казахский ковер.

Казак орнаментларының килеп чыгышы һәм тарихы хакында әдәбиятта берничә гипотеза бирелә. Шуларның берсендә казак сәнгате чыганаклары кайдандыр читтән, ягъни башка халыклар мәдәниятеннән алынган диелә. Бу гипотеза Е. Шнейдер тарафыннан ачыграк аңлатыла. «Орнаментика является прекрасным материалом для выявления происхождения или культурных взаимоотношений этнических групп…» дип, Е. Шнейдер бик дөрес әйтә, әмма ул казак орнаментикасының тамырларын «вышли из иранского мира» дигән фикере белән ялгышлык җибәрә һәм казакларның геометрик бизәкләре иранлыларның (фарсыларның) традицион «агач һәм кош» мотивыннан алынуын расларга тырыша [Шнейдер, с. 135]. Казакларның *қошқар мүйіз* («тәкә мөгезе») бизәгенең асылы хакында ул: «тәкә мөгезе»нең ромбны хәтерләткән очлары, бормалары һәм конуссыман фигурасы агач кәүсәсен хәтерләтә, дигән фикер тудыра. А. Бобринский да шуңа охшаш нәтиҗә чыгара [Бобринский].

Әмма борынгы Иран сәнгате өчен үз халкына хас милли традицияләр генә характерлы түгел. Гаҗәеп хозур сарайларны, гыйбадәтханәләрне, кабатланмас бизәкләр төшерелгән тукымаларны, келәм һәм башка эшләнмәләрне меңләгән osталар (төрле илләрдән куып китерелгән коллар) иҗат иткән. Аларның һәркайсы үз халкына хас иҗади үрнәкләр белән борынгы фарсы сәнгатен баетканнар.

Д. Уилберг болай дип яза: «В архитектуре Персеполя переплелись различные стили, заимствованные его созидателями из нескольких стран. Значительный интерес представляют рельефы ападаны (зала приемов) дворца Дария I с изображением данников древней Персии из двадцати трех сатрапий. Среди прочих данников изображены арейи, армяне, согдийцы, парфяне, бактрийцы, хорезмийцы и, что особенно для нас интересно, «одиннадцатая группа – саки-тиграхауда, или скифы, с остроконечными шапками. Изображены вооруженными и в соответствующих их названию головных

уборах. За собою они ведут лошадь и несут кафтаны и штаны (очевидно, такую же одежду они носили и сами)» [Уилберг, с. 70].

Югарыда әйтеп киткән мәгълүматлардан аңлашылганча, борынгы Персепольне төзүдә күп илләрнең осталары катнашкан, шул исәптән безнең илебезнең борынгы кабилә-ыру вәкилләре дә борынгы Иран сәнгатендә билгеле бер дәрәҗәдә үз эзләрен калдырганнар. Шуңа күрә үз сәнгатен әйләнә-тирә дөньяга тараткан нинди дә булса мәдәни үзәк булган дип кистереп әйтә алмыйбыз.

Орнаментлар үсешенә гарәп-мөселманнарның һәм ислам мәдәниятенең йогынтысы зур була. Монда тасвирый сәнгатькә Коръәннең карашын һәм сөнниләрнең фикерләрен дә читтә калдырырга ярамый.

Ислам тасвирый сәнгатендә орнаментларның киң таралуы фундаменталь дини төшенчә – ширек (ягъни күп Аллага табыну) белән бәйле. Ширеклек исламда тыела. Ислам тәүхидне – бер Аллага ышануны, Алланың бердәнбер булуын алга куя. Күпаллалык үз эченә күп нәрсәне туплый: нәфеслелек, көйсезлекнең «кечкенә аллачыгыннан (илаһтан)» һәм Аллага ышанмаудан башлап политеизмга кадәр. Ислам формалашкач, аларның барысы да кире кагыла [Джек Банс].

Төрле фикер каршылыкларына карамастан, Коръәндә тереңе сурәтләүнең тыелуы турында искә алынмый. Бу ни өчен мөселман дөньясында җан ияләрен сурәтләргә ярыймы-юкмы икәнлеге хакында ачык кына бер фикер булмауны аңлата. Аның каравы, күпсанлы хәдисләрдә андый тыю хакында катгый әйтелә. Мөселманнарның сурәт төшерүгә мондый четрекле карашының төп ике сәбәбе бар:

1. *Алланың һәрнәрсәдән абсолют өстенлеге.*

2. *Мәҗүсилек (потка-сынга табыну) проблемасы.*

Ислам нигезендә Алла урын, үлчәм, төс һәм форма төшенчәләре белән билгеләнми. Аны сурәтләү мөмкин түгел һәм ул ярамый да. Яһүдләр динендә дә Алланы сурәтләү тыела. Ә менә христианнарда алай түгел. Чөнки алар, Алла бу дөньяга кеше кыяфәтендә иңгән (богоявление), үзен сурәтләргә рөхсәт иткән, дип саныйлар.

Потларга табыну һәм күпаллалык исламда катгый тыела һәм ул бик зур гөнаһ санала. Христианнарда иконалар (тасвирлар) һәм изгеләрнең сурәтләре бик күп, һәм кешеләр аларга табыналар, ислам моның белән килешми, чөнки ул күпаллалылык булып санала.

Хәзер исә тере җан ияләрен сурәтләү, аеруча сыннар (статуялар) һәм потлар (балбаллар) эшләү генә тыела. Шуны да онытырга ярамый, дәверләргә һәм мәдәни үсеш дәрәҗәсенә бәйле рәвештә тере җан ияләрен сурәтләү төрлечә кабул ителә. Хәтта иң таләпчән мөселманнар да кечкенә күләмле (акчадагы) яки ил-дәүләт таләпләренә җавап йөзеннән эшләнгән сурәтләргә (шәхесне раслаучы документлардагы фотографияләргә) каршы килмиләр.

Сәнгать турындагы кайбер хәдисләрдә Пәйгамбәр үз хатыннарыннан берсенең өстендә

җәнлек рәсемнәре белән бизәлгән кием күргәч, аны кисеп алырга куша. Аннан соң шул кисеп алынган тукымадан мендәр ясыйлар. Шуннан башлап тере җан ияләренең сурәтен стенага, пәрдәләргә төшерү тыела, мендәр һәм келәмнәргә рөхсәт ителә.

Икенче бер хәдистә, Кыямәт көнендә Алла рәссамнардан үз сурәтләрен җанландыруны таләп итә, диелгән. Табигый ки, алар моны эшли алмыйлар һәм җәһәннәмгә җибәреләләр. «Того, кто создает изображение (живого существа), Аллах будет наказывать до тех пор, пока он не вдохнет в него жизнь, и этого он не сможет сделать никогда» [Сахих аль-Бухари, с. 846].

Келәмнәр илендә – эссе Иранда XIX гасыр ахырына кадәр келәмнәрне мөселман традицияләре буенча тукыганнар. Аларга Аллаһның тере җан ияләре сурәтләрен төшерү тыелган. Шуңа күрә Иран келәмнәренең берничә гасырны эченә алган тарихында символлар һәм орнамент детальләре рәвешендәге образлар системасы формалашкан, ул катгый бер мәгънәгә ия булган. Ромбны хәтерләткән, читләре кайтарылып тукылган чәчәк һәм яфрак рәсемнәре, нәфис эшләнгән кушма хәрефләр, мозаик бизәкләр фонында Коръәннән аерым юлларны, әйтем, риваять, сатып алучыга юлланган теләкләрне укырга була. Келәмне бизәү өчен үсемлекләрдән лалә, канәфер, сөмбел, амариллис чәчәкләрен, үрмә гөл ботакларын табигый хәлендәгечә яки стильләштереп төшергәннәр. Оҗмах тормышын символлаштырган роза чәчәге һәм анар җимеше рәсемен туку аеруча күп таралган.

Дулкынсыман яки өзек-өзек сызыклар яшәү символы – суны, түгәрәкләр дөньяның, галәмнең мәңгелек булуын белдерәләр. Ә кайбер катлаулы итеп төшерелгән өчпочмаклар киселеше һәм квадратлар кояшны, айны, йолдызларны аңлаталар. Келәм бизәлешендә төсләр гаммасы мөһим урынны били. Иран келәмнәре үзләренә җирдәге барлык төсләрне туплый, алар әйләнә-тирә дөньяның күпкырлылыгын чагылдыра.

Византиялеләр, коптлар, эллин-римлылар орнаментларының иң нәфис үрнәкләре белән баетылган гарәп-мөселман бизәкләре гаҗәеп матур, кабатланмас үзенчәлеккә ия сәнгати орнамент һәм эпиграфик орнаментлар җыелмасын тәшкил итә. Аларда борынгы куфи (почмакланган туры хәрефләр белән язу) почеркы, икенче төрле әйткәндә «чәчәкле куфи» еш кулланыла. Нәсех (хәрефләрне түгәрәкләбрәк язу) почеркы да киң таралган.

Мөселмант орнаментлары төрле вариантлардан торган төп ике төрдән гыйбарәт. Аларның берсе – үсемлекләр ислимие (үрмә үсемлек сабаклары, чәчәкле һәм яфраклы ботаклар белән бизәү); икенчесе – геометрик гирих (кискен турыпочмаклыклар һәм полигональ фигураҗәтмәләр, төеннәр рәвешендәге тоташ бизәкләр). Ислими һәм гирих һәрвакыт математик төгәллек белән эшләнә. Аларның вариантлары һәм композицияләре гаять күп төрле.

Гарәп бизәкләренең тагын бер үзенчәлеге – «келәм»

орнаментлары системасы, ул – әйбернең яки корылманың өслеген «horreur vacui» (бушлыктан курку) принцибы буенча тоташ бизәкләүдән гыйбарәт.

Шулай итеп, рәссамнарга стильләштерелгән орнаментлар һәм абстракт рәсемнәр белән бизәү тәкъдим ителә. Башкача әйткәндә, гарәп-мөселман мәдәниятенең пластик сәнгате эквивалентын матур каллиграфия белән нәфис сурәтләр тәшкил итә.

Шуны да истә тоту мөһим: борынгы гарәп-мөселман сәнгатендәге абстрактлылык бүгенгесеннән бик күпкә аерыла. Хәзерге заман рәссамнары абстракциядән инстинктив иррациональ импульсларга җавап табалар; мөселман рәссамнары өчен абстракция күптөрлелекнең бердәмлеген чагылдыра. Мөселман сәнгате әйберләрне аларның табигате белән тәңгәллектә гәүдәләндерүдә чагыла, һәм ул Алладан килгән гүзәллек белән баетыла (монда инде матурлыкны җентекләп сурәтләү таләп ителә). Сәнгатьнең ислам концепциясе материалны чын мәгънәсендә матурлап, нәфис итеп сурәтләүгә нигезләнә. Мөселман сәнгате (келәм тукучылык, архитектура, рәсем сәнгате, каллиграфия) өчен нәфис геометрик мотивларны кабатлау, көтелмәгәндә ритмны алмаштыру һәм диагональ симметрия хас. Исламча фикер йөртү – ул дөньяның тотрыксызлыгын, уй-гамәлләренең чиксезлеген, ритмны бик тиз тою.

Гарәп-мөселман мәдәнияте үзенчәлегенә мисал итеп гарәп нәкышы – арабесканы китерергә кирәк, мөселманнар өчен генә хас бу орнамент логика белән тере бөтенлек ритмын берләштерә. Мөселман декоратив сәнгате Азия, Якын Көнчыгыш һәм Көньяк Европа халыклары өчен уртак, тарихи борынгы сәнгать элементлары белән баетылган. Ислам бу борынгы элементларны тагын да абстрактлырак һәм саф билгеләмәләргә туры китереп үзләштерә, һәм аларны беркадәр үзгәртеп, магик үзлекләреннән арындыра. Шушындый синтезлау нәтиҗәсендә гарәп нәкыше (арабеска) гарәп риторикасында һәм поэзиядә дә урын ала, аңа нигезләнгән әсәрләр үзара бәйләнешле параллельләр һәм инверсияләр белән баетылган фикерләрнең ритмик агымы ягыннан аерылып торалар. Гарәп-мөселманнар өчен гарәп нәкыше (арабеска), сәнгатьне картиналарсыз гына үстерү мөмкинлегеннән тыш, картиналарны, күтәргән тема идеясенә туры китереп, киңәйтү мөмкинлеге бирә, әмма вакытта, полотноның (рәсемнең) чиксезлеге нәтиҗәсендә, гарәп нәкыше (арабеска) индивидуаль форма кучермәсе барлыкка китерә алмый.

Чыгышлары белән төрле, әмма орнаментикада охшаш яклары булган халыкларның орнаменталь мотивлары генезисын билгеләүдә кыенлыклар да очрый. Мәсәлән, казаклар, монголлар, кытайлылар, Себер халыклары орнаментикасында охшаш яки үзара якын мотивлар да бар. Буржуаз галимнәр мондый якынлык яки охшашлыкны мотивның кайсы да булса мәдәни үзәктән күчкән булуы белән аңлаталар.

Келәм орнаментациясенең үсеш процессы озак дәверләрне

колачлый, һәм аңа, аеруча аның символикасына һәр халык үзенең кабатланмас бизәкләрен, композицион төзелешләрен өсти бара.

Казак орнаменты тирән реализм белән сугарылган: анда әйләнә-тирәлекне чолгап алган чынбарлык образлары, халыкның тормышы һәм көнкүреше стильләштереп сурәтләнә. Казак орнаментының барлыкка килү һәм үсеше турындагы мәсьәләгә шушы яктан якын килү дөрес булачак.

Казак орнаменты күчмә терлекчелек хуҗалыгы шартларында формалаша. Мондый тормыш күчмә халыкны туендыра да, киендерә дә. Көтүлекнең баш санын арттыруда алар үзләренең иркенлеген, мул тормышны күрәләр, шуңа күрә дә аларның көнкүреш әйберләре күтәренке рухтагы зооморф мотивлар, нигездә хайваннарга хас билгеләр белән бизәлгән. Алар арасында үзәк урынны казак орнаментикасында киң таралган *қошқар мүйіз*нең – тәкә мөгезенең стильләштерелгән сурәте били.

Орнаменталь стильнең үсешенә, әлбәттә инде, кешене әйләндереп алган табигать, географик тирәлек зур йогынты ясый.

Табигать шартлары бай һәм матур булган якларда яшәүчеләрнең төп бизәү мотивлары да үсемлекләре дөньясы белән бәйле. Мәсәлән, Воронеж келәмнәрен белгечләр башка җирлекләрдә тукылган келәмнәрдән аерып бәялиләр. Алар чәчәк орнаментына өстенлек бирәләр: келәмнәрне розалар, лилия һәм төрледән төрле кыр чәчәкләре бизи [Ковры РСФСР, с. 73]. Алар орнаментикасының төп стиле, чыннан да, флораның күп төрле чагылышын тәшкил итә.

Казак орнаментикасында да үсемлекләр дөньясы киң кулланыла, әмма аларның төп мотивы барыбер зооморф һәм аеруча мөгез – *қошқар мүйіз* – рәвешендәге бизәкләргә барып тоташа. Һәм шуңа күрә орнаментлар белән бизәлгән барлык эшләнмәләрдә дә төрле вариацияләрдә һәм композицияләрдә урнаштырылган шушы бизәк өстенлек ала.

Композицион төзелеше ягыннан бизәкне катлауландырып бирү симметрия һәм аның символлары закончалыгы белән бәйле. Аларны өйрәнеп тикшерү өлкәсендә А.В. Шубников белән С.В. Иванов зур өлеш кертәләр [Шубников, с. 52].

Казак орнаментикасына, симметриядән тыш, характерлы сыйфатларның тагын берсе – гомуми фондагы (негативтагы) аерым өлешләрнең мөстәкыйль бизәккә (позитивка) әверелүе. Бу үзенчәлек киез әйберләр өчен дә, тукымалар өчен дә хас.

Келәм орнаментациясе эволюциясе озак дәвамлы процесс, һәм һәр халык аңа үзенең кабатланмас бизәкләрен өстәгән.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: казак орнаментикасы үзеннән алдагы буыннар мәдәниятенең үзенчәлекле өлгеләре белән баетыла барган. Казакларның бизәкләү иҗатында симметрия, үзәк фон һәм каймалап эшләү, бизәкләрнең күзгедәге чагылышы һәм фон өлешләренең мөстәкыйль бизәккә күчеше кебек аерымлыклар чагылыш таба.

**Әдәбият**

*Шнейдер Е.Р.* Казахская орнаментика // Материалы особого комитета по исследованию союзных автономных республик. Вып. 11. Серия казахстанская. Л., 1927.

*Бобринский А.* О некоторых символических знаках, общих первобытной орнаментике всех народов Европы и Азии // Труды Ярославского областного съезда исследователей истории и древностей Ростово-Суздальской области. М., 1902.

*Уилберг Д.* Персеполь. Археологические раскопки резиденции персидских царей. М., 1977.

*Джек Бане.* Религиозное, историческое и культурное развитие исламской каллиграфии // Новые грани (Алматы). 2014. № 4 (32). С. 22.

Сахих аль-Бухари. Т. 3.

Ковры РСФСР. М., 1952.

*Левин Л.М., Леошкевич И.С., Саруханов С.Е.* Художественные ковры СССР. М., 1975. С. 73.

*Шубников А.В.* Симметрия. (Законы симметрии и их применение в науке и прикладном искусстве). М. – Л., 1940.

***Касенова Кыздаркүл Бахрадин кызы,***
*Казакстан Республикасы Коркыт Ата исемендәге*
*Кызылорда дәүләт университетының һөнәри белем һәм сынлы сәнгать*
*кафедрасының өлкән укытучысы*

**2017 елның 4 октябрендә** «Төрки дөньяда агач бизәкләр эшләү сәнгате: тарихы һәм бүгенгесе» дигән Халыкара симпозиумга әзерлек йөзеннән ТР ФА галимнәре Алексеев районына бер көнлек экспедиция оештырдылар. ТӘһСИның тасвирый һәм декоратив гамәли сәнгать бүлеге хезмәткәрләре, рәссамнар Р. Әхмәтев белән Г. Исмәгыйлев, тарих фәннәре докторы, профессор К. Руденко, журналист Р. Фәезова районның В.И. Абрамов исем. Туган як музеенда, сәнгатьле туку фабрикасында, борынгы (XI–XII гас.) Остолоп авылы урынында, Биләр дәүләт тарихи-археологик һәм табигый музей-тыюлыгында булдылар. Экспедициянең максаты Идел буе болгарларының монголларга кадәрге чордагы матди мәдәнияте истәлекләрен өйрәнеп тикшерү һәм борынгы Остолоп авылы җирлегендә табылган казылма әйберләрдән болгар бабаларыбыз яшәгән өйнең тышкы күренешен реконструкцияләү иде.

**2017 елның 18–20 октябрендә** ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «XXI гасырда филология һәм сәнгать белеме» дигән I Халыкара яшьләр фәнни мәктәбе эшләде.

Мәктәп эшчәнлегендә ТР Фәннәр академиясе, республиканың фәнни һәм фәнни-белем бирү оешмалары галимнәре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, шулай ук Алматы (Казакстан Республикасы), Новосибирск, Санкт-Петербург, Махачкала шәһәрләренең фәнни-тикшеренү үзәкләреннән белгечләр катнашты.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының киңәшмәләр залында башланып киткән бу чарада филология фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академиясе Себер бүлеге филология институтының өлкән фәнни хезмәткәре Н.С. Уртегешев «Себер халыклары телләренең фонетикасы», «Тикшерүнең заманча экспериментал̧ь-фонетик методлары: МРТ, ларингоскопия, ультратавыш», Казакстан Республикасы Коркыт Ата исемендәге Кызылорда дәүләт университетының һөнәри белем һәм сынлы сәнгать кафедрасының өлкән укытучысы К.Б. Касенова «Казак келәм сугу һөнәрчелеген формалаштыруга һәм үстерүгә төрки телле халыкларның тәэсире» дигән темаларга лекцияләр укыдылар.

**2017 елның 19 октябрьдә** Казан Кремленең «Манеж» күргәзмәләр залында күренекле татар галиме, тарихчы, археограф Сәет Вахидинең (1887–1938) тууына 130 ел тулуга багышланган «Татар кульъязма мирасы: өйрәнү һәм саклау мәсьәләләре» дигән бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды.

Конференциядә, Татарстан галимнәре һәм язучылары белән берлектә, Санкт-Петербургтагы Европа университетыннан тарих фәннәре буенча PhD, Россиядә ислам халыклары тарихы буенча ТАИФ профессоры Ә.К. Бустанов, Россия Фәннәр академиясе Дагстан фәнни үзәге Тарих,

археология һәм этнография институтының археография һәм чыганакчылык фәнни төркеме җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Ш.Ш. Шихалиев, Казакстан Республикасы Р. Сөләйманов исем. Көнчыгышны өйрәнү институтының өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Б.Д. Дюсенов һ.б. катнашты.

Конференция кысаларында Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә С. Вахидинең тормыш һәм хезмәт юлын яктырткан күргәзмә эшләде. «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең дүртенче китабы – С. Вахиди эшчәнлегенә мөнәсәбәтле архив документларын туплаган җыентык нәшер ителде.

20 октябрьдә Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында «Эпитафик ядкәрләрне өйрәнүнең актуаль һәм перспектив мәсьәләләре» темасына түгәрәк өстәл оештырылды. Анда кабер ташъязмаларын өйрәнүдә заманча технологияләр куллану турында фикер алышынды. Чара Болгар музей-тыюлыгында үткәрелгән экскурсия белән тәмамланды.

**2017 елның 25 октябрендә** ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли сәнгать галереясында Бакый Урманче исемендәге премияләрне тапшыру тантанасы булды.

Сәгать белеме номинациясендә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Динә Әхмәт кызы Әхмәтова җиңүче булып танылды.

**2017 елның 25 октябрендә** ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге «Театр тәнкыйтенең һәм театр белеменең көнүзәк мәсьәләләре» дигән тема буенча түгәрәк өстәл артында фикер алышу уздырды. Бу чара күренекле театр белгече һәм театр тәнкыйтьчесе Дания Әхәт кызы Гыймранова истәлегенә багышланган иде. Д. Гыйммранова Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИның театр һәм музыка бүлегенә гомеренең 45 елын багышлаган шәхес.

Түгәрәк өстәлне аның модераторы, Институтның театр һәм музыка бүлеге мөдире, сәнгать фәннәре кандидаты Эльмира Галимова оештырды. Фикер алышуда Казан дәүләт мәдәният институтының театр факультеты деканы, фәлсәфә фәннәре докторы Р.Р. Таҗетдинова, театр белгече, театр тәнкыйтьчесе, Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИның театр һәм музыка бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре А.Р. Габәши, КФУ доценты, филология фәннәре кандидаты М.М. Хөбетдинова, Әлмәт дәүләт драма театры директоры Ф.Б. Исмәгыйлева, ТР театр эшлеклеләренең иҗади бүлеге баш белгече, Казан театр көллияте педагогы А.И. Хәйбуллина, Г. Камал исем. Татар дәүләт академия театры артистлары Әзһәр Шакиров, Наил Дунаев, Наилә Гәрәева, Г. Камал исем. Татар дәүләт академия театры музее мөдире Л.Г. Шакирҗанова,

К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты Әнәс Галиуллин, драматург Юныс Сафиуллин, ТӘһСИның әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Ә.М. Закирҗанов, ТӘһСИның тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире Р.Р. Солтанова катнаштылар.

**2017 елның 16 ноябрендә** Томск шәһәренең «Татар мәдәни үзәге»ндә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән «Милли-мәдәни мирасыбыз: Томск өлкәсе татарлары» җыентыгын презентацияләү чарасы булды. Томск татарларына әлеге хезмәтне Институтның фән эшләре буенча директор урынбасары Олег Хисамов һәм Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире Илһам Гомәрев тәкъдим иттеләр.

Әлеге җыентык Томск өлкәсендә гомер кичерүче милләттәшләребезнең милли-мәдәни мирасын барлау, анализлау һәм аны тулы итеп чагылдыру, киләсе буыннарга мирас итеп калдыру максатыннан чыгып эшләнде. Җыентык Томск өлкәсенең Әүштә, Абытай, Кызылкаш (Тахтамыш), Умавыл, Казанавыл, Калтай авылларында һәм Томск шәһәрендә берәмтекләп җыелган тел, сәнгать һәм фольклор материалларының тупланмасын тәшкил итә. Китапта галимнәребезнең 2015 елда оештырылган экспедиция материаллары зур урын били.

Җыентык экспедиция җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Олег Хисамовның Томск өлкәсе татарларының тарихына һәм топонимиясенә күзәтү ясаган мәкаләсе белән башланып китә. Җирле тарихчы В.Г. Волков мәкаләсендә төркиләрнең XVII–XVIII гасырларда Том буйларына килеп урнашулары археология, антропология һәм генетика мәгълүматларына нигезләнеп аңлатыла. Филология фәннәре докторлары Д. Рамазанова Себер татарларының том диалектын җентекләп анализласа, Ф. Баязитова том сөйләшен этнолингвистик аспектта, халык традицияләренә нигезләнеп тикшерә. Миңнира Булатованың җирле сөйләш үзенчәлекләрен яктыртуга багышланган мәкаләсендә исә авыллар тарихы, гореф-гадәт, йолаларга караган этнолингвистик материалларны һәм кызыклы, үзенчәлекле лексик берәмлекләрне табарга мөмкин. Филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова мәкаләсендә җирле халыкның мифологик ышанулары, гореф-гадәтләре буенча мәгълүматлар бирелә, фольклор үрнәкләре китерелә. Гүзәлия Хаҗиева-Демирбаш мәкаләсендә Себер татарларының исем кушу традицияләре, Том татарларының кеше исемнәре XVIII гасыр башыннан алып җентекләп анализлана. «Халык моңнары» коллективының йөзек кашы, шигырьләр иҗат итү, милли киемнәр тегү, калфаклар чигү белән дә шөгыльләнүче милли җанлы Шәрфүк Әгъләмова һәм аннан язып алынган җырлар турында Гөлнара Яхшисарова мәкаләсендә яктыртыла.

**2017 елның 22 ноябрендә** ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге һәм ТР Язучылар берлеге әдәби тәнкыйть секциясе, язучы, әдәбиятчы Гали Рәхимнең (1892–1943) тууына 125 ел, әдәбият галиме, профессор Галимҗан Нигъмәтинең тууына 120 ел тулу уңаеннан, «Татар әдәбият белеменең хәзерге торышы һәм актуаль проблемалары» дигән темага түгәрәк өстәл үткәрделәр.

Фикер алышуга түбәндәге мәсьәләләр чыгарылды: Г. Нигъмәти, Г. Рәхим эшчәнлеге һәм хәзерге татар әдәбият фәне; әдәбият фәненең теоретик проблемалары: иҗат методы; әдәби юнәлешләр һәм агымнар; чагыштырма әдәбият белеме, терминнар һ.б.; әдәбият тарихы һәм хәзерге әдәби барыш; әдәби әсәрне шәрехләү мәсьәләләре; хәзерге әдәби барышта тәнкыйтьнең урыны; әдәби журналларда тәнкыйть һ.б.

Әлеге чарада ТР Язучылар берлеге рәисе Д. Салихов, КФУ галимнәре Ф. Галимуллин, Т. Галиуллин, В. Әминева, Җ. Сафиуллин, Институтның бүлек мөдирләре Ф. Яхин, Ә. Закирҗанов, фән кандидатлары Р. Харрасова, Г. Хөснетдинова, Р. Рахмани һ.б. чыгыш ясады.

Фикер алышу максатында хәзерге татар әдәбият белеменең торышы, аерым алганда татар әдәбиятын өйрәнү, хәзерге әдәби тәнкыйтькә куелган таләпләр, аны җанландыру, шулай ук әдәбият теориясенең актуаль мәсьәләләре һәм аларны хәл итү юллары буенча җитди тәкъдимнәр ясалды.

**2017 елның 23–28 ноябрь** көннәрендә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин һәм Институтның язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире И.Г. Гомәров Татарстан Республикасы делегациясе вәкиллеге составында эш сәфәре белән Үзбәкстан Республикасында булдылар. ТР ФА вәкилләре визит кысаларында Сәмәрканд һәм Бохарадагы дәүләт университетларында булып, әлеге уку йортларының профессор-укытучылары, Үзбәкстанның фәнни бергәлек вәкилләре арасыннан Бохара дәүләт университеты профессоры, тарих фәннәре докторы Р.В. Алиев, Үзбәкстан Республикасы Фәннәр академиясе Көнчыгыш белеме институты профессоры, филология фәннәре докторы А.С. Эркинов һәм башка фәнни һәм дини эшлеклеләр белән очрашып фикер алыштылар.

Сөйләшүләр барышында Үзәк Азия татарларының кульязма мирасын өйрәнү өлкәсендә үзара хезмәттәшлекне үстерү һәм уртак фәнни чаралар оештыру мәсьәләләре күтәрелде.

**2017 елның 11 декабрендә** ТР Фәннәр академиясенең Кече залында ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге «Халык биюе һәм хореографик сәнгать: традицияләр һәм заман сулышы» дигән темага Халыкара фәнни-гамәли конференция уздырды. Г.Х. Таһировның тууына 110 ел тулуга багышланган бу

фәнни чара ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле һәм Казан дәүләт мәдәният институтының хореографик сәнгать факультеты халык биюләре кафедрасы белән берлектә оештырылды.

Тикшеренүче һәм новатор Гай Таһиров фольклор материалларын туплау, эшкәртү өлкәсендәге беренче адымнарны башлап җибәрүче. Татар халык биюләрен өйрәнү буенча экспедицияләр оештырган һәм аларда үзе катнашкан Гай Таһиров, беренче татар балетмейстеры буларак, экспедиция материалларын җәмгыятьнең мәдәни даирәсенә кертүгә зур көч куя. Татар академия театрында (1928–1933 елларда), М. Җәлил исем. Татар опера һәм балет театрында (1938–1972 елларда), Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе каршындагы Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә (1952–1970 елларда) эшләү дәверендә ул музыкаль-драматик хореография, балет һәм опера спектакльләре кую белән шөгыльләнә. Аның сәхнә иҗатында «Зәңгәр шәл», «Наемщик», «Шүрәле», дөнья-күләм классик сәнгать үрнәкләре «Фауст», «Кармен» операларына куйган биюләре һәм тагын күптөрле хезмәтләре мәгълүм. Гай Таһировның төрле елларда һәм төрле сәхнә мәйданнарында тәкъдим ителгән 365 хореографик эше арасында төп урынны татар биюләре алып тора.

Конференциядә Л.А. Касиманова (Санкт-Петербург), Е.А. Кузнецов (Мәскәү), И.К. Ногманова (Уфа), Арман Нурмахаматулы (Анкара, Төркия), Г.Ю. Саитова (Астана, Казакстан) кебек әйдәүче хореографлар, балетмейстер, тикшеренүләр алып баручылар катнашты.

«Халык биюе һәм хореографик сәнгать: традицияләр һәм заман сулышы» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция эше 2 юнәлештә барды: «Хореография өлкәсендә фән һәм белем бирү интеграциясе»; «Хореографик фольклор һәм аның сәхнәдә гәүдәләнеше». Программаның тематикасы Гай Таһиров мирасына кагылышлы мәсьәләләрне һәм аларның балет күренешләрендә, халык биюләрендә, бүгенге заман белеме һәм мәдәнияте контекстындагы профессиональ хореографиядә чагылышын, халык биюләренең этник үзенчәлеген, фольклор биюләрне өйрәнеп тикшерүнең нәзари аспектлары һәм аларны практик куллану формаларын колачлады.

Кече зал фойесында Гай Таһиров тормышы һәм иҗатының мөһим этапларын яктырткан фәнни һәм басма хезмәтләрдән күргәзмә тәкъдим ителде.

**2017 елның 14 декабрендә** Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан шәһәре мәгариф идарәсе һәм Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче гимназия белән берлектә, Галимҗан Ибраһимовның тууына 130 ел тулу уңае белән «Татарстанның яңа тарихында Галимҗан Ибраһимов мирасы» дип аталган түгәрәк өстәл уздырды. Мәгълүм булганча, әдип юбилеена бәйле чаралар март аенда аның исемен йөрткән мәктәптә ачылып киткән иде, апрельдә

Институт «Мәдәниятләр төрлелеге контекстында Г. Ибраһимов мирасы» дип аталган халыкара фәнни конференция оештырды, июньдә исә Институт галимнәре катнашында әдипнең туганягы Солтанморат авылында түгәрәк өстәл үткәрелде.

Фәнни чарада Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИ директоры К.М. Миңнуллин, гыйльми сәркәтип Р.Г. Галиуллин, текстология бүлеге мөдире Ф.З. Яхин һәм институтның башка фәнни хезмәткәрләре катнашты һәм чыгыш ясады. 17 нче гимназия директоры Ә.Ә. Галиева түгәрәк өстәл кунакларын сәламләде, шушы мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Л.Ф. Сәмигуллина Г. Ибраһимов иҗатын мәктәптә укыту тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Түгәрәк өстәлдә Казан шәһәренең барлык районнарыннан килгән татар әдәбияты укытучыларына, методик берләшмә җитәкчеләренә Г. Ибраһимовка багышланган татар һәм рус телләрендәге буклет, әдипнең барлык әдәби әсәрләрен һәм институт тарафыннан аңа багышлап соңгы елларда чыгарылган фәнни хезмәтләрне, конференция җыентыкларын үз эченә алган электрон басма, шулай ук апрель аенда булып узган халыкара фәнни конференция җыентыгы, «Г. Ибраһимов фотографияләрдә» китабы бүләк ителде.

**2017 елның 19–20 декабрендә,** ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге тарафыннан оештырыла торган «Төрки дөнья сәнгате» циклын дәвам итеп, «Төрки дөньяда агач бизәкләр сәнгате: тарихы һәм бүгенгесе» дигән халыкара симпозиум уздырылды.

Төрки халыкларның матди һәм рухи мәдәниятен өйрәнү һәм аның үсешенә йогынты ясау максаты белән 2008 елдан бирле үткәрелеп килә торган әлеге чарада төрки халыкларның (татарлар, башкортлар, азәрбайҗаннар, казаклар һ.б.ның) агачтан кисеп бизәкләр эшләү сәнгатенең үзенчәлекле юнәлеше, аның үсеш юллары һәм бүгенге торышы хакында фәнни дәрәҗәдә сөйләшү оештырылды. Урта Идел буйларындагы авылларда XVI гасыр урталарыннан башлап бүгенгә кадәр дәвам иткән агач архитектур бизәкләр-эшләнмәләргә карата җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү татарларга хас булган декоратив-гамәли сәнгать традицияләрен киләчәктә дә актив үстерүгә йогынты ясаячак. Россиянең төрле регионнарында яшәүче һәм башка төрки илләрнең агачтан кисеп бизәкләр эшләү осталарын болай җыеп очраштыру үзара тәҗрибә уртаклашып, нәфис сәнгать эшләнмәләрнең киң арсеналын тагын да баетырга, кисеп эшләүдәге яңа алымнарны ачыкларга, осталык серләренә төшенергә, агачны сәнгатьле эшкәртүнең яңа технологияләрен үзләштереп кулланырга ярдәм итәчәк. Ә инде гомуми белем һәм сәнгать мәктәпләрендә, урта һәм югары һөнәри уку йортларында укучылар өчен остаханәләр оештыру белем бирү программаларын

камилләштерергә, яңа буын осталар әзерләргә хезмәт итәчәк.

Симпозиум эшендә Азәрбайҗан, Казакстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Төркиядән, шулай ук Россиянең эре үзәкләре Мәскәү белән Санкт-Петербургтан, Башкортстан һ.б. регионнардан галимнәр катнашу бу өлкәдәге нәзари тикшеренүләрне гомумиләштерергә һәм билгеле бер системага салырга, сәнгатьнең әлеге борынгы төрен өйрәнүнең төрле аспектларын (тарихи, сәнгать белеме, лингвистик, педагогик һ.б.ны) ачыкларга мөмкинлек тудырды.

Симпозиумда катнашучыларга Л.М. Шкляеваның «XX–XXI гасыр Урта Идел татарларында йортларны бизәүнең халык сәнгате: семантикасы һәм стиль үзенчәлекләре» дигән монографиясе тәкъдим ителде.

Халыкара симпозиумның беренче көнендә «Төрки дөньяда агач бизәкләр сәнгате: тарихы һәм бүгенгесе» дигән тема буенча фәнни-гамәли конференция булды; «Агачтан кисеп эшләү буенча халык сәнгате» дигән халыкара фотокүргәзмә эшләде.

Икенче көнендә агачны нәфис эшкәртү буенча остаханәләр уздырылды, аларны халык кәсепчелегенең Казан техникумында Татарстан (Р. Әхмәтов, Х. Латыйпов), Кырым (А. Бәкеров) һәм Үзбәкстан Республикасы (Ш. Жумаев) осталары алып бардылар.